PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2017 ГЫЙНВАР № 1

сөембикә

ISSN 0869-1398

ПИРАМИДАЛАР ИШЕЛӘ
хирыслыкмы, чарасызлыкмы

САГЫНУГА ДӘВА ЮК ИКӘН...
без белмәгән Зөлфәт

ЛӘЙСӘН МӘХМҮТОВА СЫЙЛЫЙ:
«Альтернатива» салаты

Айгөл БАРИЕВА:

ХАТЫН-КЫЗ ЯРАТКАНДА, ЯРАТЫЛГАНДА ГЫНА МАТУР!



PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!

И-и ямьле туган ягым!
И-и ямьле туган ягым!



Зөһрә ГАРИФУЛЛИНА,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы.

Биектау районы Алан-Бәксәр авылы табигатьнең искиткеч гүзәл почмагына урнашкан. Авылыбызга сыенып Ашыт елгасы ага. Урманнарга, чишмәләргә дә бай без! Чишмәләрнең берсен халыктан җыелган үзара салым акчасына төзекләндердек. Ул хәзер тирә-як халкы яратып йөри торган урынга әйләнде. Баскычларына култыксалар куеп эшләгәч, суны кыш көне дә алып була. Яшьләр дә үз итте чишмәбезне: никахтан соң яшь парлар бирегә фотосурәткә төшәргә килә...

Рафис КОРБАН

Туган як үрләренә

Биектауның биек таулары юк,
Калкулык та монда, үр генә.
Юллар монда һәрчак сикәлтәле –
Үр төшә дә, янә үр менә.

Бормаланып Ашыт агып төшә,
Урый-урый үрләр арасын.
Әй, Ашытым, үрләр кичә-кичә,
Син диңгезгә агып барасың!

Күпме кичтем мин дә гомеремдә
Туган якның шушы үрләрен.
Үргә менеп, үрдән төшкәнемне
Төшләремдә хәтта күрәмен.

Мин гашыйкмын якташ Ашытыма,
Үрләренә туган якларның!
Үлгәч тә мин шушы үр өстеннән
Ашытымны тыңлап ятармын.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

2’2017



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Тәхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны	222-09-77
Директор урынбасары Рәмзия Кашапова	222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары Гөлнур Хәсәншина	222-09-78

Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Айгөл Бариева
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 16.01.2017 ел.
Заказ А-79.
Тираж 5720.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU





Фото: Андрей Титов

Роберт МИҢНУЛЛИН

Карлар ява

Язам менә тагын кыш турында.
Тынгы бирми карлар һаман да.
Бөтерелә-бөтерелә әнә
Бөдрә карлар ява Кабанга.

Карлар ява кышкы Казанкага,
Иделемә ява,
Илемә.
Яфрак булып каеннарга ява,
Ак өметләр булып – иңемә.

Карлар ява безгә...
Онытылып
Карап торам шәһәр карына.
Ышанасы килми
Бу дөньяда
Актан башка төсләр барына.

Җир сөенгән,
Җир тиенгән бүген
Табигатьнең шушы сыена...
Гомер буе без сыенган кебек,
Казаныма карлар сыена.

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



12





МӘХӘББӘТ = АЙГӨЛ

Э. Җәлилова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8

ПИРАМИДАЛАР ИШЕЛӘ...

М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





20

«АЛТЫН ТАУЛАР ВӘГЪДӘ ИТМИМ...»

16



ҺАВА, ОЧКЫЧ, КҮК ФӘРЕШТӘСЕ...

Э. Закирова

24



МӘХӘББӘТ, СИН МИНЕ НИШЛӘТТЕҢ?!

Г. Сафиуллина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36 ОФЫК АРЪЯГЫ БОЛЫТЛЫ...
Ф. Җамалетдинова

ЯШӘЕШ 

42 

САГЫНУГА ДӘВА ЮК ИКӘН...
Л. Маликова



50 ТАУЛАР ИЛЕНДӘ
Ф. Җиһанша

ШУЛАЙ УК: 

28 РАЗИЛ ВӘЛИЕВ: «МИН ЙӨРӘГЕМ ЯКЛЫ»
А. Юнысова

46 КЫШКЫ РОМАНС
А. Юнысова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60 

МЕХТАН «БӘЙЛӘНГӘН» БАШЛЫК

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ИСКЕ КОРМАШ БРЕНДЫ. ОСТА СЕРЛӘРЕН АЧА.

ИРЕМӘ 30 РӘХМӘТ. ТОРМЫШ КЫЙММӘТЛӘРЕ.

СОЛТАН ШӘМСИ. «ЧАТНАГАН ЧӘРКӘ». ХИКӘЯ.

23 ФЕВРАЛЬГӘ БҮЛӘК. ИКЕ СӘГАТЬТӘ СВИТШОТ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Минем бианам – мари милләтеннән. Һәр хатын-кызга өлге булырлык, эшчән, зирәк ана иде ул. Алар гаиләсенә килен булып төшкән беренче көнемнән үк мин аңа «Әни» дидем. Үз әниебезне без «Инәй» дип йөрттек.

Тату яшәгәндә тормышның яме, тәме бар, дигән халык мәкаленә тугры көн иттек, Аллага мең рәхмәт. Ләйлә Дәүләтованың: «Берсен-берсе сайламыйлар килен белән кайнана. Тату-тыныч яшәсәләр, бар эшләр дә җайлана», – дигән юлларын яшьләргә мәкаль итеп өйрәтәм.

Кайнанам – Сәбирә әни дөнья бәясе торырлык кеше, бик оста хуҗабикә иде. Урак, печән өсләрендә колхозчыларга аш пешерә, көнгә өчәр тапкыр мичкә ягып, алтышар-сигезәр ипи сала, барысына да җитешә иде. Аның өлгерлегенә, уңганлыгына сокланып, үрнәк алып яшәдем. Аңардан белмәгән эшемә өйрәндем. Теләк булса, барып чыкмаган эш юк ул, тормыш үзе барысына да өйрәтә.

Авылда мал асрамыйча торып булмый. Таң әтәчләре белән уянып, соң гына йокларга ятканда: «Әни, сыер саварга уят. Көтүне үзем куармын», – дисәм, «Яшь чакта йокы бик тәмле була. Миңа дүрт-биш сәгать дә җитә», – дип әйтә торган иде. Иркәләнеп ятарга ярамаганын үзем дә беләм бит инде, көтү куарга соңга калсаң, оятын кая куярсың!

Гаиләдә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең нинди булырга тиешлеген дә әнидән өйрәндем. Ирем аның белән киңәшләшә башласа, әни үз сүзен әйтер, әмма гел: «Хатының ни дип әйтер, аның белән дә киңәшләш әле», – дип тәмамлар иде. Йортыбызның өрлеге бианам булды. Кайната ул вакытта эшли иде, колхоз өчен кирәкле материаллар юллап, күп вакытын юлда үткәрде. Кызларыбызны үстерешергә бик ярдәм итте алар. Гаиләдә үзара гел татарча сөйләшә идек. (Мариларның балалары тәпи йөреп киткәннән татарча сөйләшә. Үзем дә бер ел эчендә аларның телен үзләштердем.)

Кызларыбыз дүрт һәм биш яшьлек булгач, әле әти-әни үзләре дөнья көтәрлек, дип, киңәшләштек дә, без Ижау шәһәренә килеп төпләндек. Абыемнар инәй белән ике бүлмәле фатирда яшиләр иде. Үз куышыбызны булдырганчы, без, тагын дүрт җан, абыйларның шул 26 квадрат метрлы фатирында өч ел тату-дус яшәдек. Хәзерге яшьләргә кияүгә чыгу белән фатир, машина булсын – тормышны бик җиңел күзаллыйлар.

Биатам яман шеш авыруы белән китеп баргач та, кайнанам әле мал-туар асрап, алты ел берүзе яшәде. Аннан инде ялгызлык та туйдырдымы, яше дә сиксәнгә якынлашканда безнең янга килеп, 8 ел шәһәрдә яшәде. Үз нигезен бик сагынды, билгеле.

Игелекле гомер иткәч, үлеме дә җиңел булды аның. Бер көн дә авырып ятмыйча, гел хәрәкәттә булды, 86 яшендә, язгы таң атканда йокысыннан уянып тышка чыккан да, баскычка утырган килеш йөрәге тибүдән туктаган.

Әйтәсе килгәнем шул: өлкәннәр яшь буынга үрнәк тә, терәк тә булса, яшьләр үз чиратында үзара яхшы мөнәсәбәттә яшәсә, тормышлары тату, тыныч, бәхетле булачак.

Дания БОРҺАНОВА.
Ижау шәһәре.

Мин кыңгыр эшләрем өчен төзәтү колонияләрнең берсендә хөкем җәзасы үтәм. Монда барыбызның да исеме бер – тоткыннар. Аларга карата караш та бер – җинаятьчеләр. Ләкин һәркемнең аерым-аерым булуын, һәркемнең үз күңел дөньясы булуын искәртәсем килә.

Колония тәртипләренә буйсынып яшәүчеләрнең үзләре генә белгән серләре, хыяллары юктыр, дисезме? Бар, әлбәттә! Сөю-сөелү, гаилә кору, бәхетле булу кебек теләкләрне бернинди чәнечкеле тимер чыбыклар да чикли алмый.

Матурлыкка ни җитә, дибез. Кешеләрдә булган иң көчле хис – мәхәббәтне дә матурлык, чибәрлек уята бит. Без шулай яратылган инде: башта күрәбез, аннан соң гына күргәннәргә нәтиҗә ясыйбыз. «Кара әле, нинди чибәр кыз, чибәр хатын!» – дибез. Шул ук вакытта һәрберебез матурлыкны үзенчә күрә. Кайчагында гади генә самимилек тә (чибәрлек түгел!) йөрәкне яндырырлык сөю уты кабыза.

Шулай бервакыт, кичкырын, без яши торган бүлмәгә күрше баракта яшәүче Николай абый – дядя Коля килеп керде. Алтмышның өстендә булуына карамастан, «ловелас» кушаматлы бу мәзәк карт зонада «хатын-кыз белгече» исемен йөртә иде. Шаяртып кына, аның белән сүз башладык: «Дядя Коля, ир кешегә матурлык кирәкми инде, менә хатын-кызга ул булмаса бик кыендыр инде, әйеме?» Дядя Коля кеткелдәп көлеп куйды: «Чибәр булмаган хатын-кыз юк ул. Күпләр үзләренең чибәрлекләренә ышанмыйлар гына», – дип, безгә бер риваять сөйләде.

Бервакыт ике дус, көймәгә утырып, ерак илләр гизәргә чыгып китә. Күпмедер йөзгәннән соң, болар бер утрауга килеп чыга. Утрауда яшәүче кабилә башлыгының ике кызы була. Олысы – чибәрләрнең чибәре, тик менә кечесе генә ничектер шыксызрак кебек. Бераз бу утрауда ял итеп, кабат юлга кузгалыр вакыт җиткәч, егетләрнең берсе шушында яшәп калырга була, кабилә башлыгының кызына өйләнергә ниятли. «Әйе шул, аның олы кызы бик чибәр!» – дип, дустын куәтли егетләрнең икенчесе дә. «Миңа кече кызы ошый», – дип шаккаттыра аны тегесе.

Дусларның берсе сәяхәтен дәвам итә, икенчесе кызның әтисе янына бара. Бу утрауда кәләш өчен 10 сыер белән мәһәр түләргә кирәк була. Егет тә 10 сыер алып килә. Кызның әтисе егетне олы кызына өйләнергә тели дип уйлый, олы кызын үтереп мактый. Егетнең: «Мин кече кызыңа өйләнергә телим», – дигәне аны сүзсез калдыра. Ата кеше бигүк чибәр булмаган кызы өчен 10 баш сыер күбрәк дип, 3 сыерга гына да риза булуын әйтә. «Юк, – ди егет. – Ул кыз 10 сыер торырлык, мин аның өчен 10 сыер бирәм».

Берничә ел үтә. Сәяхәтен дәвам иткән теге дусты иптәшенең хәлен белергә килә. Яр буенча ул гаҗәеп гүзәл бер хатын-кызны очратып, иптәшенең кайда яшәвен белешә. Эзләп табып, аның өенә барып керә, кочаклашып күрешәләр. Шулчак ишектән яр буенда очраган теге гүзәл хатын кереп килә. «Минем хатыным», – дип таныштыра дусты иптәшен. Монысы, аптыраудан, ачкан авызын да ябарга оныта: «Син икенче хатынга өйләндеңмени?» Аннары, уңайсызланып кына, иптәшенең хатынына мөрәҗәгать итә: «Сез бик чибәрләнгәнсез. Моның сере нидә?» «Бернинди дә сере юк, – дип елмая ханым. – мин фәкать үземнең 10 сыер бәясенә торуыма гына ышандым».

Сөйләп бетергәч, Николай абый, шелтәләгәндәй итеп, миңа карады да: «Ә сез, яшьләр, чибәрлекне башкадан эзлисез! Чын матурлыкны тапкан очракта да күпләрегез аны күрә белми», – дип, ишеккә юнәлде. Инде артыннан ишек ябыла дигәндә, ялт кына борылды да, соңгы җөмләсен «ыргытты»: «Чибәр булмаган хатын-кыз юк ул бу дөньяда!»

Габделхәй БИКТИМЕРОВ.
Казан. ИК-2.

Чабаксарда яшәп, военком булып эшләүче абыем янына барганда, *юлым һәрчак Казан аша уза торган иде. Сәфәремнең берсендә «Сөембикә» журналына да сугылдым.*

Бик җылы каршылап, чәйләр эчертеп җибәргән иделәр. Соңыннан минем хакта журналда күләмле генә мәкалә дә басылып чыкты. Ул санны бик кадерләп саклап, кая барсам да үземнән калдырмый йөрткән идем, әмма бер очрашуга баргач, онытып калдырганмын.

«Сөембикә»дә кунак булганнан соңгы вакыйгаларны язайым әле. Шулай сезнең бүлмәдән саубуллашып чыктым да, лифтка кереп бастым. Артымнан бер ир заты да керде. Аскы катка төшеп җиткәнче, икебез дә лим-мим. Бу кеше мине күзәтәдер, тикшереп карыйдыр кебек тоелды. Аска төшүгә, автобус тукталышына чаптым. Ә үзем нинди автобуска утырырга кирәклеген дә белмим, сорар кеше дә юк. Ниһаять, бер кеше килеп басты. Карасам, лифтта бергә төшкән кеше икән. Ул да шул якка бара булып чыкты. Сөйләшеп киттек. Бу кеше Рәдиф Гаташ үзе икән бит! (Ул вакытта минем дә шигырь китабым чыгып килә иде. Әмма шундый мәшһүр кеше алдында аны әйтергә оялдым.) Шулай уртак тел табып, сөйләшә торгач, кирәкле җиргә килеп җиткәнне дә сизмәгәнбез.

Мин Казанда җиңгәмнең апасы Валентина Владимировнада тукталган идем. Ул – хирург, «Татарстанның атказанган табибы». Бик итагатьле, зыялы кеше иде. Без аның белән бик тату идек, ул мине үз кызыдай күтәреп алып, озатып калыр иде. Өе зур. Фортепьянода классик көйләрне генә түгел, мин яраткан татар көйләрен дә бик матур итеп уйный торган иде. Мәгәр бу апамның бер ягы бар иде – ул бик тә төгәллекне яратты. Миңа шәһәргә чыгып киткәндә, күпме йөрсәң дә йөр, әмма кичке биштә өйдә бул, ди торган иде. Һәм тагын бер нәрсә – кайтып җитәр алдыннан телефоннан белгертергә кирәк иде. Ул чакта кесә телефоннары юк. Болар яшәгән йортның подъезд ишеген алдан шалтыратып ачтырасы иде.

Шулай Гаташ белән апа яшәгән йортның аскы катындагы кибет янында басып торабыз. Дөресрәге, почмакка эленгән телефон янында. Сөйләшеп сүзебез бетми. Әле бишкә кадәр вакыт бар. Хәзер бу кеше инде якын да булып китте. Якташ та икән бит әле. Адәм баласы кызык бит ул: әгәр рухи яктан пар килгән кешене тапса, мөкиббән була да куя. Бермәлне бу миңа әйтә: «Муеның озын икән, җырлый беләсеңдер?» «О-о! – минәйтәм. – Еще как! Мин җырлый башласам, бөтен тараканнар качып бетә, күршеләр форточкаларын яба, ирем белән кызым, аларга ияреп песи дә эчтәге бүлмәгә кереп качалар». Бу көлде дә: «Кәефем күтәрелгән чакта мин менә бу җырны җырлыйм», – дип, «Ал Зәйнәбем» җырын сузып җибәрде. Шулкадәр матур итеп җырлый! Мин дә җырларга бик яратам, түзмәдем, аңа кушылдым. Үткән-сүткән гаҗәпләнеп карап китә. Ә безгә диңгез тубыктан. Казан уртасында ике «ахмак» татарча «сайрый» гына! Аннары мин Гаташның үтенече белән үземнең «коронный» «Сибелә чәчем»не башкардым. Начар җырладым, өйдәгечә матур килеп чыкмады, оялдыммы, белмим...

Ул очрашу әле дә якты хатирә булып күңелемдә саклана. Гаташны укыгач, истәлекләр тагын яңарып киткәндәй була. Сездә мәхәббәт шагыйре Рәдиф Гаташ булса, безнең Башкортстанда – Равиль Бикбай.

Шәүлия ЗӘЛКАРНАЕВА.
Башкортстан, Учалы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

ТӨП ТЕМА

ФИНАНС МӘСЬӘЛӘЛӘРЕНДӘ НАДАНЛЫК, АКЧАГА ХИРЫСЛЫК, ЕШ КЫНА ЧАРАСЫЗЛЫК ТА КЕШЕНЕ ЕЛЛАР БУЕ ТУПЛАП КИЛГӘН СОҢГЫ АКЧАСЫННАН ДА МӘХРҮМ КАЛДЫРЫРГА МӨМКИН.





Мәдинә АВЗАЛОВА

ПИРАМИДАЛАР ИШЕЛӘ...

«Пирамида» дигәндә, күз алдыма Мисыр, зәңгәр күк гөмбәзенә терәлгән серле-гүзәл пирамида килеп баса. Ул моннан меңнәрчә ел элек тә булган һәм моннан ары да килгән-киткәннәрне үзенең мәгъруур кыяфәте белән каршы алып, озатып калачак әле. Анда шундый ырым да бар, имеш: пирамидага кулыңны куеп, теләк теләсәң, барысы да тормышка аша... Без дә, барган саен, аның гасырлар кичкән җылы ташына учыбызны тидереп, озак кына басып торабыз. Әллә кайнарлыгы шулай итә, әллә аның чыннан да серле бер көче бар, яныннан бер дә китәсе килми.

Минемчә, финанс махинацияләре белән шөгыльләнүче атаклы алдакчылар беркатлы халыкның акчасын талау юлына басканда, бу исемне тиктомалдан кулланмаган. Финанс пирамидасы... үзе үк – сүзе үк тартып тора. Кайсын бу пәрәвез оясына акчасызлык – чарасызлык, кайсын җиңел генә акча эшләү максаты, ягъни комсызлык, кайсын финанс яктан дөм наданлык тартып китерә. Югыйсә кеше тиенләп җыйган соңгы акчасын төрле шикле кооперативларга, банкларга илтеп биргәнче, башта ул оешмалар турында җентекле мәгълүмат җыярга, кемгә биргәнен белергә тиеш тә бит.

Аннан килеп... пирамида төзеп, төп башына утыртучылар да булмады түгел, булды. Кайчандыр бөтен ил халкын талап, чит илгә чыгып качкан Сергей Мавроди турында исегезгә төшерәбез. Аның елгырлыгыннан зыян күрүчеләр Татарстанда да бихисап. Ләкин, шуңа да карамастан, ул шомафый «МММ-2011» дип аталган тагын бер яңа пирамида төзеп ята. Алай гынамы әле? 90 нчы елларның «атаклы» аферисты Нигерия, Зимбабве илләренә барып җиткән. «МММ Көньяк Африка» финанс пирамидасы турында бүген бөтен дөнья сөйли. Ни өчен гел килеп кабалар соң пирамида ятьмәләренә? Җавабы гап-гади: пирамидада катнашучыларга аена 20 процент керем тәкъдим ителә. Ә бу гамәлдә мөмкин булмаган эш. Бер генә банк та мондый югары процентлы керем бирә алмый. Аның күләме уртача 9-10 процент тирәсе булырга мөмкин. Чөнки алар алдамый, алар клиент алдында үзләренең бурычларын төгәл үти. Мавроди моның белән генә чикләнеп калмый, ул пенсионерларга һәм инвалидларга (хәтта яклаучысыз карткарчыклар акчасына да кул суза) керемнәрен 30 процентка арттырырга вәгъдә бирә. Халыкны алдау чарасы бу, үзенә күрә бер реклама гына. Аңлашыла ки, коммерция оешмалары, клиентлардан кергән акчаны, аларга проценты белән кайтару өчен икътисадның теге яки бу өлкәсен үстерүгә салырга тиеш. Әгәр ул шушы принцип белән эшләми икән, җимерелүгә дучар. Бу очракта зыянны, әлбәттә инде, әлеге дә баягы гади халык күрә.

«Сизми дә калдым»

Финанс пирамидасы корбаннарын эзләп ерак китәсе түгел: алар үзебезнең арада да җитәрлек. Тик алар кармакка ничек килеп эләгүләре турында сөйләргә ашкынып тормыйлар. Кемнең дә кемнең «кара көнгә» дип саклаган акчасыннан белдексезлеге аркасында мәхрүм калуы хакында урамга чыгып кычкырасы килсен? Ә әйтергә, чаң сугарга, гаеплеләрне җаваплылыкка тартырга кирәк. Һичшиксез, кирәк! Пирамидага «мөкиббәннәрнең» үз схемасы, хокук саклау органнарының аларга каршы көрәштә – үз ысулы. Берәү дә тик тормый, йоклап ятмый, дип әйтәсе килә.

– Нишлисең инде? – дим, акчасын «Рост» җаваплылыгы чикләнгән кредит сәнәгать компаниясеннән ала алмый йөргән танышымның хәленә кереп. – Никләр шунда салдың, ичмасам...

– Кем белә аның шулай буласын, – ди ул, авыр сулап. – Күршем: «Улымны шуннан гына кергән процент акчасына укытам», – дип мактангач, саласы иттем шул. Еллык проценты күп иде бит – 18 процент! Бер генә банкта да алай бирмиләр. Менә... бирделәр инде... Ярты ел эчендә ишелде дә төште. Хуҗаларының кайда икәнлеген дә белмиләр. Безгә – гади халыкка бөтенесен әйтеп тә бетермиләр. Кайчан алырбыз ул акчаларны, алырбызмы, күрербезме ул көнне? Алданганымны сизми дә калдым...

Картаймыш көнгә дип тиенләп җыйган 200 мең акча җилгә очкан. Җилгә очкан дим, чөнки аның кайчан да бер иясенә кайтасына беркем дә ышанмый. Беркем дә гарантия бирми. Дәүләт карамагында булса, дәүләт җавап бирә, ә акча салучылар белән астыртын уен уйнаган мондый ялганчы оешмаларны җәзага тарту өчен иң элек аларның җитәкчеләрен эзләп табарга кирәк әле.

Сизми дә каласың шул. Моннан ун еллар чамасы элек редакциягә килеп, безне – журналистларны акча эшләүнең челтәрле маркетинг принцибына нигезләнгән халыкара схемасы турында сәгатьләр буе сөйләгәннән соң... тәки сертификат сатып алырга мәҗбүр иткән ханым (соңыннан аңладык, схема дигәне шул пирамида булып чыкты) баегандырмы безнең акчалар белән, юктырмы, әмма без акчаны суга салганны бик тиз аңладык. Ярый әле ул кадәр зур акчалар түгел иде ул.

БЕЛЕШМӘ

2014 елның гыйнварыннан 2016 елның декабренә эчке эшләр органнары тарафыннан гражданнарның 18 мең мөрәҗәгате тикшерелгән. Боларның барысы да финанс пирамидалары эшчәнлеге белән бәйле булуы ачыкланды. Китерелгән зыян миллардлар белән исәпләнә. Шушы чорда 38 җинаять эше кузгатылды.

Хәзер 29 җинаять эше – тикшерү стадиясендә, шуның 26 сы буенча гаепле кешеләр билгеләнде. 2014–2016 елларда судка 10 җинаять эше җибәрелде. 23 кеше хөкемгә тартылды.

Казан шәһәренең Вахитов районы судында финанс пирамидасы вәкилләренә карата чыгарылган хөкем карары күпләргә сабак булыр. Әлеге эшләр белән бәйле дүрт кеше гаепле дип танылды һәм аларның кайсы – 4,5 елга, кайсы 3 елга ирегеннән мәхрүм ителде. 2016 елның 13 октябрендә тагын бер кредит кооперативы директоры 7 елга хөкем ителде.

Акчагызны шикле банкларга һәм төрле кредит кооперативларына салмагыз. Алар вәгъдә иткән югары процентларга ышанмагыз!

Өч бала анасы Әлфия Хәсәнова акчасын «Русинвест»ка илтеп тапшырганда, аның көтмәгәндә менә шулай юкка чыгачагын күз алдына да китереп карамаган.

– Инде фатир алырбыз дип йөри идек, – ди әңгәмәдәшем, пошаманга төшеп. – Акчабызны күрмәбез, ахрысы. Безгә: «Акчагызны чит илгә күчергәннәр булырга охшый», – диләр. Кайтармаслар, дигән сыманрак та әйтәләр. Ә кая киткән соң ул акчалар? Айга очмагандыр бит. Минемчә, кайтарасылары килми. Дөресен әйткәндә, илдә кризис, ә бюджетыбыз, үзегез беләсез, саекканнан-саега бара.

Халык беркатлы, ул барына ышана. Кайчан да бер процентлар исәбенә баеп китәчәгенә дә, шулар исәбенә бетмәс-төкәнмәс проблемаларын хәл итәчәгенә дә... Ә иң мөһиме – ул дәүләткә ышана: алдарга юл куймаслар, дип өметләнә. Акчасын банкка тапшырганда ул бит аның финанс пирамидасы булуын белми. Югары процент вәгъдә итәләр ич аңа. Ә аңа шул кирәк тә һәм

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

көннәрдән бер көнне шау-шу куба. Акча салучылар барысы берьюлы банкка акча сорап килә. Ә банкта акча юк. Кая киткән?! Берәү дә белми. Әлеге дә баягы чит илгә чыгып качканмы, җилгә очканмы? Эзли башлыйлар, тик очына гына чыга алмыйлар. Инде хәзер аңлашыла: пирамидалар өч очракта җимерелә: беренчесе – закон белән проблема килеп чыкканда; икенчесе – оештыручылары – кырыкалдарлар; өченчесе – эшләтү системасын уйлап җиткермәү, оештыручыларының тәҗрибәсезлеге, акча салучыларның паникага бирелүе.

Республикада финанс пирамидалары ишелә.

Үсүгә табамы, бетүгәме?

Татарстан Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, быел полициягә кырыкалдарлар тарафыннан зыян күргән 2 меңнән артык кеше мөрәҗәгать иткән. Ә бу исә финанс пирамидаларының әкренләп ишелә баруын күрсәтә. Законсыз рәвештә оештырылган финанс һәм кредит оешмаларыннан зыян күрүчеләрнең саны артканнан-арта бара. Былтыр бер безнең республикада гына да эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итүчеләр саны 5 мең тирәсе.

Безнең республика финанс пирамидаларының активлыгы ягыннан да, саны ягыннан да, башка регионнар белән чагыштырганда, алда бара. Лидер без бу мәсьәләдә. Дөрес, уңай нәтиҗәләребез дә бар. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсе җитәкчесе Илдар Сафиуллинның әйтүенә караганда, 2015 елның март аенда Татарстанда «Рост» кредит сәнәгать компаниясенең эшчәнлеге туктатылган. Ул Россиядә иң эре финанс пирамидаларының берсе санала иде. Полициягә халыктан 2,5 мең гариза кергән. Күрелгән зыян 700 миллион сум тәшкил итә.

Ничек туктатырга?

Шулай да мондый уеннар белән мавыгучыларның күбесе җаваплылыктан котылу юлларын бик тиз эзләп таба. Чөнки финанс пирамидасына каршы тору юллары турында Җинаять кодексында төгәл билгеләмәләр юк. Оештыручыларны җитди җәзага тарту чаралары турында бер генә маддәдә дә телгә алынмый. Финанс пирамидасы башында торучыларны кырыкалдарлыкта гаепләп яисә банк эшчәнлеге законлы булмаган өчен генә җаваплылыкка тарта алалар. Күз алдына китерәсезме: миллиардлар урлап качкан каракларга карата гафу ителмәслек дәрәҗәдә җиңел караш. Шуңа да алар яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләрдәй үрчиләр. Дөреслекгә, үрчиләр иде. Ә хәзер... хәзер Остап Бендер дәвамчыларына карата җитди маддәләр эшләнеп ята. Шуларның берсе – 210 нче маддә – җинаятьчел берлек оештыручылар буларак, аларны 15 елдан алып гомерлеккә кадәр утыртып кую каралган. Күптән шулай кирәк иде. Кабул ителгән ул законнар эшләсен генә. Шул чагында гына без бу шомафыйларның кулына суга алырбыз.

Татарстан Республикасының Иминлек Советы секретаре Айрат Шәфигуллин республикада финанс пирамидаларын оештыручыларга каршы чын мәгънәсендә көрәш игълан ителү хакында белдерде. Гамәлдәге законнарга төзәтмә кертү өчен, Президент күрсәтмәсе буенча, эшче төркем төзелде. Әлеге төркемгә Милли банктан, прокуратурадан, Тикшерү комитетыннан, Эчке эшләр министрлыгыннан, Федераль Иминлек Советыннан, салым хезмәтеннән һәм башка ведомстволардан вәкаләтле вәкилләр керде. Бу төркем инициативасы белән өч яңа закон эшләнде инде. Мондый пирамидалар корган кырыкалдарларга 4 елдан 6 елга кадәр төрмә яный.

«Әллә каян күренеп тора...»

Тегe яки бу банкның йә булмаса кооперативның финанс пирамидасы икәнлеген каян белергә соң? Аферистлар белән эш йөртүеңне дәлилләүче билгеләре берничә: әйтик, Россия банкының лицензиясе булмау яки дәүләт реестрына ул оешманың исеме кермәү; әйткәнебезчә, югары процентлы керем вәгъдә итү дә шикле күренә. Мөрәҗәгать итәргә җыенган компания турында интернет, матбугат, танышларыгыз аша белешегез. Сайт булмау яки үзләре турында бик аз мәгълүмат бирү – бу инде сезне җитди уйландырырга тиеш. Ни өчен финанс эшчәнлеге хакында бернинди мәгълүмат юк, ни өчен җитәкчеләре турында берни язмыйлар... Ә бит болар бар да ачык һәм аңлаешлы итеп күрсәтелгән булырга тиеш. Аннары... яңа клиент тапкан өчен акчалата бүләкләү дә моның ялган пирамида булуын күрсәтеп тора.

Финанс пирамидаларының барлыкка килүендә безнең дә гаеп бар. Бушлай сыр тычкан тозагында гына. Акча җиңел килми, ә менә җиңел чыгып китәргә мөмкин. Иминлек Советы моны милли куркынычсызлыкка яный торган күренеш дип атады. Соңгы йөзьеллык дәвамында ул җир шарының төрле почмакларында уңышлы эшләп килә. Мондый юл белән баю турында хыялланмагыз да. Күпне өмет иткән азыннан да мәхрүм калган, диләр. Хыялланырга бу сезгә Мисыр пирамидасы түгел.

КЕМГӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ?

Инде килеп капкансыз икән, ул чагында түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итә аласыз:

- Идел–Нократ регионында (Казан шәһәре) финанс базары буенча Россия банкы хезмәтенең регионара идарәсе: 420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 53/6. Телефоны: (843) 264-69-09.
- Россия Үзәк банкы Идел–Нократ баш идарәсенең Татарстан буенча Милли банкы: 420013, Казан шәһәре, Бауман урамы, 37. Телефоны: (843) 235-06-68.
- Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсе: Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 9. Телефоны: (843) 291-32-60.
- Татарстан Республикасының Иминлек Советы: 420014, Казан шәһәре, Кремль. Телефоны: (843) 567-88-75.

БАЛАГА СҮЗ ӘЙТЕРГӘ ЯРЫЙМЫ



Журналның узган елгы ноябрь санында «Мин үзем кадәр әле...» исемле язманы укыдым да, бу темага карата үз фикерем белән бүлешәсем килде.

Хәзер әллә нинди мода барлыкка килде: балага бер сүз әйтергә ярамый, имеш, төзәлмәс психологик травмалар ала, алдагы тормышы зәгыйфь була. Әмма шул ук вакытта шәхсән миңа әниләрнең, әбиләрнең сөйләгәне искә төшә: элек күп балалы аналарның бала назларга бик вакыты да булмаган, заманына карап, тәрбия ысуллары да үзенчәлекле булган. Тик шулай да нинди яхшы кешеләр үскән, нинди әйбәт тәрбия бирә белгәннәр.

Элек тә төрлесе булган, бала-чагага карата булган катылыкны хупламыйм, әлбәттә, әмма уйланырга урын бар.

Язмада: «Кеше баласына сүз әйтергә ярамый, әйтсә, үз әнисе генә әйтсен», дигән фикер дә чагылган. Әмма, дөресен генә әйткәндә, кайвакыт әниләр һәм әбиләрнең балаларының читтән караганда бик сәер кыланмышларын да сөенеп, яратып диярлек кабул итүе, чит кешенең күзенә бәрелеп торганда да «күрмәве» еш очрый. Үсеп барган оныгы әбисенә сукканда да көлеп куйганнар бар. Сүз уңаеннан, каяндыр укыган бер хәл исемә төште. Автобуста 4-5 яшьләрендәге бер малай ботинкасы белән юри тибенеп барып, янәшәдә басып торган ханымның ак пальтосын пычраткан. Әйтеп-әйтеп тә аңлата алмагач, хатын моның әнисенә мөрәҗәгать иткән. «Юк, мин баламны фәлән методика белән үстерәм, анда бала фәлән яшькә кадәр ни тели – шуны эшли, сүз әйтергә ярамый», – дип, баласын яклый икән тегесе. Автобус халкы, аптырап, ни әйтергә белми торганда, якында гына басып барган бер егет килгән дә, авызындагы сагызын бу әнинең маңгай чәченә чәпәп куйган. Аннан авызын ачып калган ханымга: «Мине дә шул методика белән үстерделәр, ни телим – шуны эшлим», – дип әйткән ди. Ни дисәгез дә, кеше кешегә комачаулык тудырырга тиеш түгел, әни кешегә моны баласына аңлата белү дә кирәк. Аннары, дөресен әйтәм: иплән кенә әйтеп тә аңламаса, инде хәзер бармак буе балага да мин, өлкән кеше, сүз әйтергә куркырга тиешме? Әгәр ул миңа чынлап та комачаулый яки юри начар кылана икән, үз ата-анасы сүз әйтмәсә, ник мин түзеп торырга тиеш? Кызык икән: бала-чагага сүз әйтмә, ә ул сиңа ни әйтсә дә ярый!

Аннары тагын бер нәрсәне әйтәсем килә. Һәркемгә үз баласы бик кадерле, әмма чит кеше өчен ул тансык булмаска мөмкин. Күп кеше, артык комачауламаса, сабыйларны яхшы кабул итә, әмма нинди сөйкемле булса да, балагыз үзен кеше алдында теләсә ничек тотса да ярый дип уйлау дөрес булмас, минемчә. Мәсәлән, кайбер рестораннарда кичен балалар белән керү рөхсәт ителмәүне әти-әниләр гаепкә саный. Ә мин моны аңлыйм: тыныч кына ял итәргә дип килгән кешенең бала-чага чыр-чуын тыңларга теләмәскә дә хакы бар. Шул ук язманың авторына әйтәсем килә: аңлыйм сезне, әни кешегә кечкенә баланың һәр кыланмышы кадерле, әмма болай да стресслы дөньяда, кызганычка, кайвакыт утыргычына арттан бер тибү дә чыгырдан чыгарыр өчен җитәрлек була. Мин балага кычкырган апа яклы түгел, билгеле, әмма аны да аңларга була – бәлки, баланың шуклыгы аның өчен нәкъ менә соңгы тамчы булгандыр? Әни кеше дә баласына: «Кызым, алай тибенеп утырма!» – дисә дә булыр иде, мәсәлән. Тәрбия шул кечкенә вакытта башлана инде ул. Кызганычка, иҗтимагый урыннарда бер-беребезгә хөрмәт күрсәтә белмибез әле, «башка кешегә комачауламый микән», дип, аз уйлыйбыз (югыйсә башкалар алдында сәгатьләр буе телефоннан җыен юк-бар сөйләп, кешенең колагын тондырмас идек, әмма монысы башка мәсьәлә).

Психологларга килгәндә, гадәттә, аларның киңәше «балага менә шулай, шулай әйтегез», диюдән узмый. Теориядә балалар – идеаль, әйтү белән тыңлый, шундук бара, эшли. Ә чынбарлыкта... Өч балалы дустымның сүзләре искә төшә: «Кайвакыт, дәресеңә утыр, дип, һәрберсенә йөзәр кат кабатлап, йә үзара талашуларыннан туеп, шашар дәрәҗәгә җитәм. Кайчак каеш күрмичә туктамыйлар». Начар түгел, әйбәт әни ул – ләкин реаль тормыш белән психологик теориянең аермасы бар. Бала-чага да тере җан: нидер эшлисе килми, карыша, елый. Артык йомшаклыкны да шундук сизә – бөтенләй тыңлатып булмый үзен. Катгыйлыксыз да булмый кайчак. Әти-әниләр минем белән килешер дип уйлыйм.

Сүз уңаеннан, тагын бер темага кагылмыйча булмас. Хатын-кыз эштә дә баш күтәрмәскә тиеш, ире алдында да «йөзен бозмаска», инде менә баласына да тавыш күтәрергә рөхсәт юк. Мескен хатын-кыз үзенең эмоцияләрен кая куярга тиеш икән? Дөнья бу, кәеф тә төрлечә булырга мөмкин, әйтәсең дә, кычкырасың да, шулай түгелмени? Баланы кагып-сугып торуны хупламыйм, әлбәттә, әмма кайвакыт әнинең ачулануы тәрбия дәресләре дә әле ул. Иплән кенә әйтсәләр, кайчак күңелгә барып та җитми, ә хис-тойгылар кушылса, кайчак мәңгелеккә истә кала. Әни дә тере кеше! Әгәр бала ниндидер начарлык эшләп, аның кәефен төшергән икән, ник ул моны күрсәтмәскә тиеш?! Алай итәргә ярамаганын эмоцияләрсез генә ничек аңлатсын ул баласына! Аннары, гадәттә, ачуланыр өчен сәбәп тиктән чыкмый. Димәк, йә баланың тормышына зарар килмәсен дип курыккан ул әни, йә аны ниндидер куркынычтан сакларга тырыша. Бармагын розеткага тыгарга маташучы балага «алай итмә» дию генә дөресме соң? Аңлармы ул аны? Кайвакыт ныклап, бүтән кабатламаслык итеп әйтә белергә дә кирәк бит. Аннары, тагын бер сорау бирәсе килә: бер тапкыр да ачуланмаган бала нинди тормыш өчен үстерелә икән ул? Кайсы «теплицада» яшәр өчен? Үскәч, урамда берәр тупас адәмгә очраса яки эшендә җитәкчесе кычкырса (андый очраклар юкмы әллә?), ул чакта нәрсә? Кайвакыт тормышка реальрәк карау да начар булмас иде.

Гүзәл ХӨСНЕТДИНОВА.
Мәскәү.

КАЙТАВАЗ

PRESSA.RU

МӘХӘББӘТ = АЙГӨЛ



«Ә мин артист булырга җыенмыйм. Җыр ул минем бер мавыгуым гына». «Мин булачак иремне, балаларымны бернәрсәгә дә алыштырмаячакмын!» «Артист кешегә кияүгә чыкмаячакмын. Артист булу кыен, ә артистның хатыны булу икеләтә авыр». «Әтием исеменнән мин беркайчан да файдаланмадым!» «Мәчеткә бару хыялы бар әле тагын»...
19 яшьлек Айгөлнең – татар студентларының «Ягымлы яз» фестивале (1993) дипломантының – иң беренче интервьюсыннан бу юллар. (Ә ул аны нәкъ менә «Сөембикә» журналына биргән иде!) Ул вакыттан бирле шактый сулар акты. Күп нәрсә үзгәрде. Айгөл БАРИЕВА бүген бөтен татар дөньясына билгеле җырчы, Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исеме бар. Ә менә сылулыгы, гүзәллеге, самимилеге – шул икән! Җырларыннан да шундый ук сафлык бөркелә!
Ут ул. Күзе һәм үзе янып тора. Гел. Бәлки, шуның өчен дә аның белән аралашу шулкадәр җиңел һәм кызыклыдыр?!



Эльмира
ҖӘЛИЛОВА

Айгөл, бар җиргә өлгерү тормышны шулкадәр яратуданмы?

– Ирдән уңудандыр, бәлки?! Линар миңа бернинди киртәләр куймады. Һәрбер теләгән максатыма ирешергә тулы ирек бирде. Балалар да кечкенәдән мөстәкыйль булды, инде 5 яшьтән алар өйдә үзләре генә кала башлаган иде. Кызымның: «Әни, син тагын гастрольгә китәсеңмени?!» – дип мөлдерәп карап торган күзләрен хәтерлим...

Иҗат кешесе белән яшәгәннәргә һәйкәл куясы, диикме?!

– Кияүгә чыгуым да кинәттәнрәк булды инде минем.

Өч көндә танышып, кавышкан кешеләр без Линар белән. Ялга кайткан хәрби кешенең озакка сузарга вакыты да булмагандыр, беренче көнне өйгә кадәр озата кайтты, икенче көнне тәкъдим ясады. Мин ул вакытта ике эштә эшлим. Никах укытабыз да, Линар Себергә китә, мин Казанда калам дип план корабыз. Шулчак дәү әни: «Ир белән хатын никахтан соң аерым яшәми!» – дип кырт кисмәсенме! Мин әле ул чак «Хыял» хорына йөрим, безнең хор Италиягә барырга тиеш. Мин китеп бардым. Әни: «Бер дә борчылма, кызым, мин никахыңа калфак чигәргә бирдем», – дип калды. Гастрольдән кайтып, өч көн үтүгә никах укыттык. (Ә калфакны һаман кадерләп саклыйм, кызым үз никахында шуны кияр дип өметләнәм.) Никахтан соң ике көн үтүгә без Себергә киттек. Вокзалга алтмышлап кеше озатырга килде: хезмәттәшләр, дуслар, туганнар. Алар барысы да бу көтелмәгән яңалыктан һушсыз калганнар иде. Безнең туй шул вокзалда булды бугай, дип көләм мин хәзер.

Чит җир. Яңа тормыш. Ничек кабул иттең?

– Себердә без бер генә ел яшәдек. Бер-бер артлы балалар туды. Казанга кайткач та, мин әле биш еллап өйдә утырдым. Иҗат кешесе өчен һавасыз яшәү белән бер иде бу. Үз-үзеңнән ризасызлык, канәгатьсезлек. Ирем, балаларыма ачуланган чакларым да булгандыр. 2004 елда «Нечкәбил» конкурсында катнашу мине кабат сәхнәгә һәм тормышка кайтарды. Икенче урынны алып, диск чыгару һәм клип төшерү кебек бүләкләргә ия булдым. Мине Шамил Бариев кызы итеп кенә беләләр иде. Үз исемемне мин озак таныттым.

Әти-әниеңне бик иртә югалту да синең шәхес буларак формалашуыңа йогынты ясамый калмагандыр?

– Бу мәңгелек ике яра мине нык үзгәртте – мин кырысландым, үткенләндем, оялчанлыкны юып алгандай булды. Миңа инде үземә юл ярырга кирәк иде. Хәер, мин балачактан бик мөстәкыйль идем, анысы. Бәлки, шуңа да югалып калмаганмындыр. Иркә бала булдым дип әйтә алмыйм үземне. Әти хәтердә мәңгегә тынгысыз бер җан булып уелып калды: ул һәрвакыт каядыр чаба иде. Театрда репетиция, радиотапшырулар, телевидениедә төшүләр, ике институтта дәресләр... Ничек өлгерде икән ул? Өйгә кайтып керешкә урысча сөйләшеп йөргән әни белән икебезне: «Нинди марҗалар бу?!» – дип әрләп ташлый. Әти өйдә чакта гел татарча гына сөйләшә башлыйбыз... 5 яшьтән театрда «яшәдем» мин. Хәтеремә бер хәл бик уелып калган: тормышта шулкадәр уңай әтиемә спектакльләрдә никтер гел тискәре рольләр бирәләр иде. «Минем әти әллә чынлап та шулкадәр әшәке кеше микән?!» дигән уй сызылып үткән иде бер мәл. Аннары, еллар үтеп, үзем «Бичаракай» фильмында тискәре рольдә уйнагач, урамда туктатып, тамашачыларның: «Без сине бик яратып тыңлый идек, хәзер борылып карыйсы да килми!» – дигән сүзләрен ишеткәч, яхшы башкарылган рольнең ышандыру көчен аңладым. Мин әти-әнием белән аралашырга да өлгерми калдым кебек. Җитми алар миңа – исән булсалар, алар хакына әллә ниләр эшләр идем дә бит...

Эшлисең дә бит, Айгөл!

– Аллага шөкер, зур хыялым тормышка ашты – «Тапшырылган хатлар» китабы дөнья күрде. Анда әтинең хатлары тупланган. Тиздән әти-әни язмалары белән диск чыгарга тиеш. Әмма мин боларны ниндидер гайре табигый хәл итеп кабул итмим – мин исән чакта алар онытылмаска тиеш!

Артист баласының язмышы да шул юлдан тәгәри, күрәмсең?!

– Минем әти-әни каршы иде моңа. Мин үзем дә каршы. Хәтта балаларымны кечкенә чакта сәнгать юлына кызыга күрмәсеннәр дип, театрга да сирәк йөртә идем. Әмма без күзаллаганча гына булмый тормышта: улым беркем сүзенә дә колак салмыйча, актер булу турында хыяллана. Хыяллана гына да түгел, инде ышанычлы адымнар ясый. «Әни, син минем офис эшчесенә әверелеп, бәхетсез булуымны телисеңме?! Яисә син минем сәләтемә ышанмыйсыңмы?!» – диюеннән соң мин, гомумән, аның сайлаган юлын тәнкыйтьләмәскә булдым. Үзе егылсын, үзе торсын да алга барсын. Гәрчә мин үземне бик таләпчән һәм усал әни дип санасам да, балаларны ишетергә тырышам. Беркайчан аларның теләген кырт кисмим. «Башта әтиегез белән киңәшегез!» – дим.

Дөнья гизүдән без гел башка кеше булып кайтабыз.

Гаиләдә соңгы сүз ир-атныкы, димәк?

– Бездә андый нәрсә юк. Әгәр мин өйдә юк чак булса, Линар да балаларга: «Әниегез белән киңәшергә кирәк!» – дип әйтә. Алай да балалар әтиләреннән күбрәк шөлли бугай.

Линар җайлы холыклы кешегә охшаган.

– Күгәрченнәр кебек гөрләшеп кенә яшибез дисәм, ихласлыгыма хыянәт булыр иде. Тик миндә бер генә тапкыр да: «Ник бу кешегә кияүгә чыктым икән?!» – дигән сорау туганы булмады. Иң мөһиме: ул ышанычлы. Еллар үтү белән шашкын хисләр тоныклана, гаиләне хөрмәт кенә саклап кала ала. Ир-атка бик мөһим сыйфат – юмарт ул Линар. Мин кайчак ни теләвемне кычкырып әйтергә дә куркам, чөнки беләм, минем өчен ул аны соңгы акчасына алып кайтачак! Безнең аның белән тормышка карашлар да тәңгәл килә – матди байлык белән түгел, күңел кичерешләре белән юанып яшибез. Әгәр яңа машина алыргамы, әллә сәяхәт итәргәме дигән сайлау алдында калсак, икебез дә сәяхәтне сайлаячакбыз.

Син бик чая, матур һәм зәвыклы хатын-кыз.

PRESSA.RU







Башка ир-атларның сиңа игътибарын ирең ничегрәк кабул итә?

– Яшерен-батырын түгел, ул игътибар булды, бар һәм булачак. Ирем инде аңа күнеккән. Хатын-кызга игътибар кирәк, ә иҗат кешесе өчен мең тапкыр кирәгрәк! Янар өчен гел хыялый гашыйклык халәте булырга тиеш! Мин һәм мәхәббәт аерылгысыз төшенчә булып тоела кайчак. Бер танышым икенчесенә: «Мәхәббәт булмаса, Айгөл үләчәк!» – дигән әнә! Чын яратуда бернинди гөнаһ була алмый. Ә йөрәкне дөртләтмәгән мөнәсәбәтләргә мин битараф. Гел яратып-яратылып яшәргә ихтыяҗ миңа, мөгаен, әти-әнидән күчкәндер инде. Әтинең хатларын укыгач, «мондый яратудан бары мәхәббәтсез яши алмый торган бала гына туа ала!» дигән фикергә килдем мин. Мин ярата беләм!

Үзен яратсалар гына хатын-кыз матур була.

Гел янудан торган гомер, димәк?!

– Әтинең бер хатында «тереклек итәргә түгел, яшәргә кирәк бу дөньяда!» дигән юллар бар. Бу минем тормыш девизым хәзер. Гомер буе үз-үзем булып калырга тырыштым. Ясалмалылык ят миңа. Кешенең үз йөзен беркайчан яшереп калам димә, ул барыбер бер ачыла! Ә минем беркемгә дә берни дә исбатлыйсым юк. Беркемгә ярарга тырышасым юк. Турысын бәреп әйтә, ошамаса, борылып китә алам. Үз-үземә нык ышанган шәхес булып өлгергән чорыма килеп җиттем.

Һөнәреңне интригасыздыр дип әйтә алмыйм. Алай да син алтын урталыкны саклап, дуслык дигән төшенчәгә тугры кала аласың. Шул нисбәттән иҗат кешеләре арасында да якыннарың шактый.

– Әйткәнемчә, мин бик туры сүзле. Бераз гына ясалмалылык, көнләшү сизсәм дә, кеше белән аралаша алмыйм. Чын кешеләр бик аз калды бугай инде бу заманда. Шуңа күрә дә бөтен кеше белән дус булганнарга сагаеп карыйм, димәк, алар чынлыкта беркемне дә якын итми. Кеше бөтен кешегә дә ошый алмый, ошарга тиеш тә түгел. Мин, хәтта, дусларым белән әйткәләшәм кайчак. Бәлки, мин гел хаклы да түгелдер?! Миңа гел дөреслек кирәк! Һәр борчыган проблеманың төбенә төшәсем килә. Аларга минем белән бик җиңел дә түгелдер, әмма миңа алай тынычрак.

Иҗат кешесендә еш кабатлана торган халәт – депрессия. Үз-үзеңне югалтмау зур батырлык кебек?..

– Кемгә барып бәрелергә белмәгән чакларым була. Андый чакта серем сыярлык берничә якын кешем бар. Күп очракта мин эшкә кереп чумам. Җәяү йөрергә яратам. Аннары мине, мөгаен, ялгыз хатын-кыз булмавым коткарадыр.

Синең тагын бер таянычың – дин дип беләм...

– Минем ике дәү әти дә мулла иде. Кечкенәдән миңа да дәү әни догалар өйрәтте. Тик ул чакта никтер артык игътибарга алынмаган. 33 яшемә җиткәч, үзлегемнән догалар өйрәнеп, намазга бастым. Елый-елый беренче намаз укуымны хәтерлим – миңа кирәк иде бу ышаныч! Тәрәз каршына килеп басам да Ходайдан сорыйм. Башкаларга зыян китерми теләнгән теләк иртәмесоңмы барыбер кабул була! Сорый белгәнгә бирермен, дигән. Бу сүзләрнең хаклыгына мең кат инандым инде. Шуңа да мин үземне бүген бик бәхетле хис итәм. Тормышта бер үкенечем дә калмас төсле, ни теләдем шуңа ирештем шикелле!..

ҖӘМГЫЯТЬ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановны Гарәп Әмирлекләренең бөтен дөнья туристларын җәлеп итү тәҗрибәсе кызыксындырды. Ул Дубайда «Бөтендөнья авылы» («Global Village») тематик ярминкәсе эшчәнлеге белән танышты. Ярминкә беренче тапкыр 1997 елда ачык һавада оештырылган һәм туристлар арасында бик популяр. Анда төрле илләрне тәкъдим итүче, шуларның милли стилендә эшләнгән сәүдә павильоннары урнашкан.

Мәскәүдә Крокус Сити Холл концертлар залында Россия Мөфтиләр шурасы һәм Россия мөселманнары Диния нәзарәте Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көненә һәм ислам фәлсәфәсенә багышланган «Югалган васыятьнамә» музыкаль спектакленең премьерасын тәкъдим итә. Төп рольне танылган театр һәм кино артистлары Марат Бәшәров, Шамил Хаматов, Казакъстан актрисасы Бибигөл Актан Сөеншамина башкара. Шулай ук анда Г. Камал, М. Гафури театры артистлары катнаша. Тамашада Ибн-Фадлан, Салават Юлаев, Мөхлисә Бубый, Муса Бигиев чорлары тасвирлана. Спектакльне Казан, Уфа, Санкт-Петербург, Түбән Новгород тамашачылары да күрәчәк.

Татарстанның Беренче Президенты, республиканың Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең 80 яшьлек юбилее уңаеннан 22 гыйнвар көнне «Россия 1» телеканалы «Шәймиев Тартарияне эзли» дип аталган документаль фильм тәкъдим итә. Аны тележурналист Сергей Брилев әзерләгән.

КОТЛЫЙБЫЗ



Татарстанның халык артисты Зәһрә ШӘРИФУЛЛИНА 60 яшьлек юбилее уңаеннан «Фидакарь хезмәте өчен» медале белән бүләкләнде. Г. Тукай исемендәге филармониядә үткән кичәсендә җырчыга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән җиңел автомобиль ачкычы тапшырылды.

МӘГАРИФ

Боровое Матюшинодагы «Идел» яшьләр үзәге базасында Worldskills стандартлары буенча һөнәри осталык чемпионатында катнашачак Татарстан җыелма командасының беренче слеты башланды. Анда гомуми психологик халәтне җайга салуга һәм инглиз теле буенча белем дәрәҗәсен күтәрүгә корылган күп профильле эш көтә. 2019 елда Казанда Worldskills чемпионаты узачак. Махсус төзелгән полигоннар һәм лабораторияләр базасында яшь галимнәр һәм белгечләр, ашчылар, тегүчеләр, монтажчылар, тагын берничә дистә һөнәр ияләре үз эшләрен иң шәбе дип таныту өчен ярышачак.

ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы «Россиянең су хәзинәләре» Бөтенроссия туган як су пейзажлары фотографияләре конкурсын игълан итте. Бәйге Су ресурслары Федераль агентлыгы тарафыннан Россиядә экология елы кысаларында үткәрелә. «Пейзажлар», «Кешеләр һәм су», «Су – тормыш билгесе», «Су – бала күзеннән» кебек номинацияләргә караган эшләрне Россия Су ресурслары агентлыгында бәяләячәкләр.

МӘДӘНИЯТ



Мәскәүгә эш сәфәре кысаларында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Третьяков галереясында булды. Ул «Мәңгелек Рим. Ватикан пинакотекасы хәзинәләре» күргәзмәсе белән танышты. Галереяның генераль директоры Зөлфирә Трегулова сүзләренчә, бу – Россия өчен уникаль проект. Ватикан музейлары моңарчы читкә, башка илләргә даими экспозициядән бу кадәр олы коллекцияне чыгарганнары юк. Ул билгеләгәнчә, быел 26 апрель көнне Казанда Третьяков галереясыннан 56 сәнгать әсәре һәм ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееннан 22 рәсем тәкъдим ителәчәк күргәзмә ачыла.

Россиянең Дәүләт академия Кече театрында Камал театрының Фәрит Бикчәнтәев куйган «Хуҗа Насретдин» спектакле белән гастрольләре башланып китте. Камаллылар башкала тамашачысына соңгы елларда уйналган җиде спектакльне алып килгән. «Көтәм сине», «Кәҗә, Сарык һәм башкалар», «Галиябану», «Мәхәббәт FM», «Бармы ришвәткә дәва?», «Җилкәнсезләр» Мәскәүләргә дә ошар.

СПОРТ



«КАМАЗ-Мастер» командасының «Дакар» халыкара ралли-рейдында 14 нче тапкыр җиңүе һәм «Africa Eco Race» раллиенда 4 нче җиңүе Россия автоспорты тарихына алтын хәрефләр белән язылды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «КАМАЗ-мастер» командасын «Дакар-2017»дә җиңүе белән котлады.

PRESSA.RU









ҺАВА, ОЧКЫЧ, КҮК ФӘРЕШТӘСЕ...



Эльмира ЗАКИРОВА

Аэропорт. Анда һәрчак ниндидер үзенә бер ритм. Дулкынлану катыш рәхәт ыгы-зыгы. Самолетлар гүләве. Таблода – рейслар, шәһәр исемнәре, очу расписаниеләре йөгерә. Кемнәрдер каядыр ашыга...

Кабатланып торган игъланнардан Лос-Анджелес, Париж, Шанхай, Тель-Авивлар да бик якын тоела. Менә хәзер рейсыңны әйтерләр, регистрациягә чакырырлар. Ә самолет трабыннан күтәрелгәндә инде ягымлы елмаеп сәламләүче стюардесса кыз сине чын мәгънәсендә күкнең җиденче катына алып менеп китәр! Аһ итәрлек матур форма, сылу гәүдә, килешле хәрәкәтләр... Аэрофлотның йөзек кашы диләр алар турында. Шуларның берсе – безнең Чулпан!

Чаллы кызы Чулпан Моглиева инде ун елдан артык оча! 2006 елда Франкфуртка очып башлаган беренче рейсына яңа илләр, яңа шәһәрләр өстәлә тора. Биш кыйтганың 50 ләп илендә, 80 ләп шәһәрендә булырга өлгерә, Россиянең 40 ка якын шәһәрен күрә Чулпан. Чукотка, Камчатка, Сахалиннар... АКШ, Канада, Испания, Италия, Сингапурлар... Бразилия, Мексика, Чили, Филиппиннар... Чаллы телевидениесе Чулпан Моглиева турында сюжет та әзерләде. Безнең Чулпан күктә дә, җирдә дә, суда да дип, тормышындагы кызык мизгелләрне күрсәттеләр. Инглизчә, алманча, испанча сөйләшә торган кыз белемле, максатчан, тырыш, тәвәккәл, ачык, булдыклы! Мәктәп елларында ук татар теле буенча олимпиадаларда җиңә. Сәнгать мәктәбендә, музыка мәктәбендә укый. Шәп йөзә, йөгерә, чаңгыда шуа. Испаниядәге дуслары аны дайвинг белән мавыктыра. Су асты дөньясына мәхәббәт исә яраткан кешесе белән очраштыра, кавыштыра.

Чулпан гел эзләнүдә, камилләшүдә. Аның тормышы матур эшләргә, кызык вакыйгаларга гаҗәп бай. Мин шаккатып тыңлыйм аны.

Стюардесса булу турында уйлап та карамаган идем. Әнием кебек укытучы буласым килде. Алабуга педуниверситетының чит телләр факультетын тәмамлап, Чаллыдагы 76 нчы гимназиядә инглиз теле укыта башладым. Бер ел эшләгәч, алманчамны шомартырга дип, юллама белән Германиягә киттем. Виттенберг шәһәрендә бер гаиләгә гувернантка булып урнаштым. Хуҗа хатын Зульке хосусый юридик контора тота, ире юк. Иртәдән кичкәчә ике яшьлек Фабио, ун яшьлек Паскаль янында мин. Каникулларда балаларга төрле илләр күрсәтәләр. Паскальны көзге каникулларда – Төркиягә, кышкысында – Австриягә, Альпта тау чаңгыларында шуарга, язын Африканың нәкъ экватор өстендә ятучы Кениясенә алып бардым. Кояш нәкъ баш өстендә! Океан суы чигенгәнне дә шунда күрдек. Фабионың тәрбиячесе дә безнең белән барды. Ул «Люфтганза» авиакомпаниясендә бортпроводник булып эшләүче кызы турында мавыктыргыч итеп сөйли иде. Самолетта да стюардессаларны күп күрдем. Ә бездә, Россиядә ничек бортпроводник булырга, аларны кайда укыталар икән? Өйгә кайткач, эш эзләп Мәскәүгә китеп бардым.

Без – пассажирлар иминлеген кайгыртучылар!







PRESSA.RU

Кирәк бит: белдерүләрдә берничә мәртәбә бортпроводник вакансиясенә төртелдем! «Аэрофлот»ка, «Сибирь»га (S7) чакыралар. Инде өченче тапкырында «Трансаэро» белдерүен дә күргәч, тәвәккәлләп карарга булдым. Тик анда бортпроводник түгел, регистрация менеджеры кирәк икән. Әңгәмә үткәрүче кыз, бөтен таләпләргә туры киләсең дип, стюардесса булырга кодалый башлады. Инглиз телең әйбәт, буең озын, янәсе.

Иң беренчесе – инглиз теленнән тест иде. Грамматикадан белемнәремне, башкалар сөйләгәнне ничек аңлавымны тикшереп карадылар. Рәсем, спорт, музыка, йөзү, китаплар, дайвинг, сәяхәтләр, авыл табигате... Шулар турында инглизчә сөйләп, үз дөньямны ачтым кебек. Әтием Марат – КАМАЗда фәнни-тикшерену институтында инженер, әнием Сәлимә – Чаллыдагы кадетлар мәктәбендә завуч, энем Алмаз архитектура-төзелеш институтын тәмамлады дип, гаиләбез белән таныштырдым. Аннары психологик тест узарга кирәк иде. Төрле ситуацияләргә караган сорауларына җавап бирәм. Стрессларга чыдаммы мин, дипломат сыйфатларым бармы – кыскасы, берәүне дә үпкәләтми генә проблемаларны ничек чишә алуыма шундый имтихан менә! Бер дә кыен тоелмады алай. Тик әңгәмәнең кәттәсе алдарак икән әле – әзерлегеңне төрле инструкторлар, департамент башлыкларыннан торган комиссия тикшерә! Бөтен кешедән диярлек: «Ни өчен бортпроводник булырга телисең? Бу эшкә туры килерлек нинди сыйфатларың бар?» – дип сорыйлар. Иң кирәкле сыйфат, минемчә, кешеләрне яратырга кирәк!

Ура! 40 тан 7 кеше калдык! Мине алдылар!

Берчак миңа татар кызы булуым бик булышты.

Космоска очабыз диярсең! Конкурстан узганнарны 18 табиб җентекләп карый әле башта. Психологтан башлап наркологка кадәр!.. Кул көче дә, физик әзерлек тә тикшерелә. Дикция, вестибуляр аппарат, кан басымы... Буй 160 сантиметрдан ким булмасын. Татуировкалар, җөйләр юкмы, хроник авырулар борчымыймы... Өч айга якын уку дәверендә самолет ишеген ачарга-ябарга, кофены дөрес итеп пешерергә, беренче медицина ярдәме күрсәтергә, ярадагы канны туктатырга, тулгагы башланган хатынның баласын таптырырга, янгын чыкса сүндерергә, ярсыган пассажирны тынычландырырга... өйрәндем. Тагын... биеклектән курыкмаска, елмаерга, утырып торырга бер минут вакытың булмаганда да башкаларны тыңлый белергә, игътибарлы, ягымлы, тәмле телле булырга. Авиация куркынычсызлыгы, хокуклар, авария-коткару эшләре, пассажирга хезмәт күрсәтү нечкәлекләре, һава судносы конструкциясе, көтелмәгән ситуацияләрдән чыга белү – барысына да өйрәттеләр.

Пассажирлар – безнең кунаклар! Траптан ук елмаеп, хәвеф-хәтәрсез очыш ышандырып каршылыйбыз. Мин эчтән генә бисмиллаларымны әйтәм. Пассажирлар безгә исем белән эндәшә. Рейс башында микрофон аша исемнәребезне әйтеп таныштыралар. Аннары бейджикта да исемебез язылган. Безнең эшне арба белән ризык тарату гына дип ялгышалар. Бортпроводник ул йөз төрле эшне башкаручы. Бераз официант, ризык әзерләүче, шәфкать туташы, экскурсовод, юрист, психолог, модельер, дипломат, тәрбияче... Тагын әллә никадәр «бераз»лар.

Халык безне «стюардесса» дип атый. Дөресе – «бортпроводник». Укуның беренче көннәреннән үк безгә шуны сеңдерәләр. Хатын-кызга да, ир-атка да шулай әйтәләр. Бейджикта да шулай язылган: «бортпроводник Чулпан Моглиева». Эш сәгате 10–12 сәгать. Айга 80 сәгать очабыз. Романтика тулы дөнья кешеләре без. «Еще раз про любовь» фильмында уйнаган Татьяна Доронина кебек. Аңа гашыйк физик-ядерщик Евдокимов (Александр Лазарев) стюардесса Наташаны «Мәскәүнең һәм Мәскәү өлкәсенең иң матур кызы» дип атый! «Экипаж»да уйнаган Александра Яковлеваны, «Мимино»дагы Елена Проклованы күз алдына китерәм дә: «Менә без шундый», – дип, канәгать елмаям. Ир-атлар күзе белән караганда, иң матур хатын-кызлар – стюардессалар икән. Спортчы кызлар – икенче, фотомодельләр өченче урында, ди.

Минем өчен һәр очу – беренчесе сыман. Чөнки экипаж гел яңарып тора. Бер-беребезгә ияләшергә дә өлгермибез. Хәтта иллюминатордагы күренешләр дә гел яңа, бер дә кабатланмый кебек. Һаваның төсе бүтәнчә зәңгәр! Шәфәкъ кызыллыгы да күпкә матуррак!

Франкфуртка бортпроводник булып очам! Аэропортка килү белән старт медосмотрына керәм. Табиб документларны тикшерә, кан басымын үлчи. Очып китәргә сәгать ярым кала, өлкән бортпроводник брифинг үткәрә. Нинди типтагы лайнер, экипаж составы, һава торышы, кайсы юнәлештә очабыз, кемнең нинди вазыйфасы – шулар турында сөйләшәбез. Пассажирлар салонга кереп утырганчы кислород мендәрләрен, су запасын, азык салынган контейнерлар санын тикшереп чыгам. Елмаеп, пассажирларны каршы алам. Аларга үз урыннарын табарга, кулларындагы багажны урнаштырырга булышам. Һавага күтәрелергә 15 минут калганда утырту тәгәлләнә. Самолет күтәрелергә әзер! Пассажирлар әзерме? Иллюминатор пәрдәсе ачылган, иминлек каешлары эләктерелгән. Дулкынланып, юлчыларны сәламлим: «Уважаемые дамы и господа! Я – бортпроводник Чулпан Муглиева приветствую вас на борту самолета, выполняющего рейс Москва–Франкфурт...»

«Чулпан!» – диләр дә елмаялар. Күнегеп беттем инде: Чулпан Хаматова белән чагыштырырга яраталар. Кайбер кыюраклары кайдан, кем булуым белән кызыксына. Татарстаннан икәнемне, татар кызы булуымны әйтәм. Арада якташлар да очраштыра. Нью-Йоркка очканда мин өлкән бортпроводник идем. Күрәм: бер әбине коляскада алып киләләр. Социаль хезмәткәрләр шулай озатып калды. Ерак сәфәргә берүзе генә чыккан

әбинең океан аръягында яшәүче кызыннан башка беркеме юк икән. Русча сөйләшә белми, салондагылар аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламый. Тылмач итеп мине чакырдылар. Бәй, 82 яшен тутырган әби татар карчыгы икән ләбаса! Лениногорск районындагы бер авылныкы. Аның белән татарча сөйләшә башлагач, күзләре яшьләнде! «Менә, кызым, кеше туган җиренә үләргә дип кайта, ә мин үләргә дип чит илгә китеп барам», – диде ул еламсырап. «Борчылма, әбекәй, бар да әйбәт булыр», – дип, аркасыннан сөеп тынычландыргандай иттем. Рейс уңышлы үтте. Әбекәйне чикне узганчы озатып та калдым әле.

Көнем чемодан тутырудан башлана. Иң кирәкле әйберләрне генә алачакмын. Хәер, хатын-кыз өчен барысы да кирәк инде ул. Тагын бер тапкыр расписаниене тикшереп, вакытында очу-очмау белән кызыксынам. Кичке 8 дә регистрация урыны янында очрашырга килешәбез. Димәк, 7 дән калмый чыгып китәсе. 6 да җыена башлыйм. Безгә өч төрле форма бирделәр: итәк, чалбар белән блузка, күлмәк. Алар пиджак белән киелә. Муенга бәйләр өчен яулык, түбәтәй сыман баш киеме... Күлмәкне үтүклим, бизәнәм, чәчкә прическа ясыйм. Запас колготки тыгарга онытмыйм тагы... Документлар... монда! Машина ачкычы... алдым! Аһ, адаптер кала күрмәсен! Бөтенесе әзер бугай инде. Көзгегә генә күз салам да... Домодедовога җилдерәм.

«Аэрофлот» бортпроводниклары өчен дресс-код куелган. Безнең кызыл һәм зәңгәр төстәге формалар бар. Кызыл форма кигәндә колготкиларның тән төсендәгесен сайлыйсың, зәңгәренә караңгыраклары туры килә. Тик бутарга ярамый! Яулык һәм бейджик – мәҗбүри. Зур алкалар, бриллиантлар, зур сәгатьләр рөхсәт ителми. Кыска итеп киселгән чәч белән йөрисең йә артка җыеп куясың. Бизәнү буенча да махсус дәресләр алдык. «Кычкырып» торган иннекләр сөртмәскә дигән кагыйдәне яхшы беләбез. Форма дигәннән, ун ел дәверендә минекеләренең төсе үзгәреп торды: зәңгәр һәм күк төсеннән башлап (ул җәйге форма иде), ачык яшел, ал, зәңгәрләрен кидем.

Сезне Боинг-747-400 бортында сәламлим! Елмаеп, пассажирларга көн саен шул сүзләрне җиткерәм. 527 кеше сыйдырышлы киң фюзеляжлы ике катлы зур лайнерыбыз, меңнәрчә чакрымнар үтеп, ерак араларга оча. Кәеф һәрвакыттагыча күтәренке! Мин пассажирларны җайларга-көйләргә әзер! Берничә сәгать буена үкчәле туфлиләрдән йөрү үзен сиздерә, әлбәттә. Самолетта һава корылыктан күзләр авырта кайчак. Гипоксия, ягъни кислород кытлыгы галәмәте инде. Плюсы да бар андый һаваның: гел яшь күренәбез!

Депутатлар, олигархлар оча торган рейслар да бар. Ул дүртенче бүлеккә карый. Аэрофлотның генераль директоры элиталы рейслар өчен иң матур, инглизчә шәп сөйләшә торган кызларны җыйды анда.

Бизнес-класста эшләргә яратмыйлар. Пассажирлардан озын күренмәс өчен, заказларын каршыларына утырып сорарга кирәк: «Сезгә нәрсә китерергә? Чәйме, кофемы?»

Көтелмәгән хәлләрдә дә калабыз. Озакка сузылган «задержка»лар, «нелетная погода»лар, тәүлек буе аягөсте калулар, гауга чыгаручы исерек пассажирлар, аларны тынычландыру... Боларсыз булмыйдыр инде. Кайчак көлке хәлләр дә килеп чыга. Экипаж командиры йә өлкән бортпроводник, самолет төшәсе аэропортны бутап, бөтенләй башка шәһәрнекен әйтә. Ялгышларыбызны төзәтеп, пассажирларны тынычландырырга, гафу үтенергә туры килә. Үзем белән дә андый хәлләр булгалый. Бер мизгелгә кайчак югалып та каласың. Хәзер кайда соң әле мин? Ослодамы, Копенгагендамы? Әллә Стокгольмдамы??? Бүген атнаның кайсы көне, иртәгә нинди көн – белмим дә. Үз рейсларымның даталары гына баштa чуала.

Нишләптер Казанга рейсларым туры килми. Ун елга нибары ике тапкыр эләкте. Ноябрьдә эстафета булды: Казанда кунып, икенче көнне Симферопольгә очтык. Бер тапкыр Уфага очасымны белгәч, тиз генә әти белән әнигә шалтыраттым. Авылыбыздан ике сәгатьлек кенә юл бит! Мин траптан төшкәндә, алар терминалда көтәләр иде инде.

Самолет салонын – «банка», креслолар арасын «бульвар» дибез.

Бортпроводникларның үз сленгы. Бизнес-класста приборлар төрелгән киндер салфетканы – «курчак», өлкәннәрдән башка гына очучы балаларны – «умка», реактив самолетны – «сыбызгы», пилот кәнәфиен – «чашка», пассажирларныкын – «топчан» дип йөртәбез. «Разворот» – көнендә урап кайтыла торган рейс, ә кунып кала торган ерак рейслар – «эстафета». Аэробус – «арбуз», Домодедово – «Домик», Внуково – «Внучка», Боинг – «Бройлер» яки «Бобик», Атлантик океан – «Лужа». Шул сүзләрдән тулы бер сүзлек төзерлек!

«Рейс алдыннан пиджакның төшкән төймәсен тегеп куя күрмә!» Мине шулай кисәттеләр. Юньлегә түгел: йә авария була, йә очалмый утырасың, имеш. Менә шулай! Ышануларны санга сукмауны да гафу итә алмый авиация. Энә-җеп сорап, авыз да ачасы түгел! Тагын шундый ырым бар: самолетка беренче итеп ир кешене уздыралар. Стюард яки пилотны, мәсәлән.

+30 дан -30 га! Иртән – җәйдә, кичен – кышта. Эшебез шундый! Бервакыт эссе Доминиканда Яңа ел каршылап, 30 градус салкынлы Мәскәүгә кайтып төштек. Пассажирлар яланбаш, юка күлмәкләрдән... Тышта салкын чеметтереп ала! Ә миңа тагын очып китәсе! Таиландка! Түзмәдем, әнигә «смс» җибәрдем: «Салкыннарны Мәскәүдә калдырып, кабат җәйгә күчтем мин! Кояш яндыра!»

...Ә берничә сәгатьтән күктәге гадәти эшем башланыр. «...Корабль командиры һәм экипаж сезне Боинг-747-400 бортында сәламли. Без 10 мең метр биеклектә, сәгатенә 700 чакрым тизлек белән очабыз... Хәерле юл телим сезгә!»

PRESSA.RU









«АЛТЫН ТАУЛАР ВӘГЪДӘ ИТМИМ...»

Татарстан Республикасының Беренче Президенты, республиканың Дәүләт Киңәшчесе, күренекле сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе, гаҗәеп кешелекле, тыйнак, гади һәм гали зат – Минтимер Шәрип улы ШӘЙМИЕВНЕ олуг юбилее белән котлыйбыз!
Шушы зур вакыйга уңаеннан укучыларыбыз игътибарына Минтимер Шәймиев тормышына багышлап язылган китаптан кайбер өзекләрне тәрҗемәдә тәкъдим итәбез. «Күренекле кешеләр тормышы. Биография дәвам итә...» сериясеннән Мәскәүдә «Молодая гвардия» нәшриятында дөнья күргән әлеге китапның авторлары танылган журналист Игорь ЦЫБУЛЬСКИЙ һәм Татарстан Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА.

Авылда туй ясаганнан соң, яшьләр Мөслимгә килеп урнаша. Минтимер – РТСта баш инженер, Сәкинәне райпотребсоюзга өлкән икътисадчы-плановик итеп эшкә алалар.

Сәкинә Шәймиева сөйли: «Безгә дүрт гаиләгә исәпләнгән барак тибындагы бинадан бер бүлмә бирделәр. Һәр бүлмәдә зур мич кукыраеп тора. Безнең уртак хуҗалыкта туйга әти бүләк иткән тимер карават, үзем Казаннан алып кайткан урын-җир әйберләре, икешәр алюмин кашык һәм чәнечке, ике аш тәлинкәсе, кечкенә өстәл һәм ике урындык бар. Мин ашарга әзерли торган керосинка да бар әле тагын. Без бәхетле идек: бергә утырырга өстәлебез, кочаклашып йокларга караватыбыз бар. Тагын ни кирәк?! Ләкин Минтимер гаиләнең үз өе булырга тиеш дип исәпләде».

Яшьлеге, тәҗрибәсезлеге аркасында Минтимер алган ике шелтә дә нәкъ менә гаилә тормышы башлану белән бәйле. Икесе дә Мөслим РТСында баш инженер булып эшләгән чагында эләгә.

Минтимер Шәймиев сөйли: «Беренчесе – «запчастьларны әрәм-шәрәм иткән өчен» булды. Мин Казанга өйләнергә киттем. Өйләндем. Ә иртән ишек шакыйлар. Таныш шофер булып чыкты. Мөслимнән өч машина килгән – директорым, доверенность тоттырып, районнарны запчастьлар белән тәэмин итү идарәсенә җибәргән. Үземне хөрмәт иткән егетләрне ничек кире борасың инде. Киендем дә «Сельхозснаб»ка киттем. Кирәк бит – әле генә яңа запчастьлар кайткан. Урыпҗыюның нәкъ кызган чагында! Машиналарга төяп җибәрдем. Директор запчастьларны башка районнар белән бүлешергә тиеш иде. Ә болар тоткан да бөтенесен Мөслимдә калдырган. Озакламый яшь кәләш белән мин дә Мөслимгә кайттым. Кинәт директорны Казанга чакырталар. Җәзага тартырга һәм «запчастьларны әрәм-шәрәм иткән өчен» эштән куарга дип. Ләкин доверенностьта минем, ягъни баш инженерның имзасы куелган бит. Шуннан инде директор бөтенесен миңа сылап калдырды...

Икенче шелтә – үз белдегем белән йорт салырга карешүем өчен эләкте. Йорт салу үтенече белән директорга кердем. Ул чакта планнан тыш төзелеш алып бару рөхсәт ителми иде, риза булмады. Бераздан авырып китте, аны Бөгелмә хастаханәсенә салдылар. Бер-ике айсыз чыкмас, диделәр. Мин инде бураны күтәреп куярга да өлгердем. Ул хастаханәдән кайтуга, без Сәкинә белән күченеп тә куйган идек. Директор иртә тора иде, берничә тапкыр йортым тирәли әйләнгәләп йөргән... Берникадәр вакыттан соң миңа каты шелтә белдерелгән икенче кәгазь килеп төште.

Өйләнешеп, тугыз ай үтүгә – Минтимер белән Сәкинәнең уллары туа. Дуслар белән килешенгәнчә, аңа Айрат дип исем кушалар.

Сәкинә Шәймиева сөйли: «Бәби көтүемне уртак шатлыгыбыз итеп кабул иттек. Бер-берсен ихлас яраткан кешеләр генә шулай сөенә аладыр...

Баланы җиңел таптым. Нарасыемны беренче тапкыр имезергә китергән минутларны искә төшереп, хәзер дә дулкынланам әле. Мин аны бик җентекләп карадым, бөтен тәнен, гәүдәсен капшап чыктым, нәни куллары, тәпиләре, күзләре, кечкенә генә бармаклары үз урынында икәненә тәмам инандым... Соңыннан табиблар, ирегез төне буе шалтыратып, безне аптыратып бетерде, диделәр».

Минтимер Шәймиев сөйли: «Район активы җыелышында утырам, президиумга хәбәр итәләр: «Тимер, анда сине хатының чакыра!..» Сәкинә соңгы аена кергән иде, бүген-иртәгә бала тууын көтәбез. Чыктым, ул: «Бала тудыру йортына барырга кирәк», – ди. Ярый әле ерак барасы түгел – юл аркылы гына. Сәкинәне медикларга калдырдым да, кире җыелышка кайтып утырдым. Җаныма һич урын табалмыйм. Җыелыш бетүгә тагын шунда чаптым. «Барыгыз, өегезгә кайтыгыз, – диләр. – Тудыргач, үзебез хәбәр итәрбез. Борчылмагыз».

Кая ул! Кайттым да телефонга ябыштым. Төне буена акушерларга эшләргә комачаулап бетергәнмендер, мөгаен. Сәгать саен шалтыратып торам... Хатынымның бөтен фотоларын яшереп бетердем. Картлардан шундыйрак ырым ишеттем: кешегә авыр булса, хастаханәдәме, башка җирдәме ул, аның сурәте күз алдында тормаска тиеш... Ышанып бетмәсәм дә, фотографияләрен еракрак җыйдым. Улыбыз туып, Сәкинә бәби белән өйгә кайткач, моның өчен бераз пешереп тә алды үземне. «Нигә алай эшләдең?» – ди. «Бала тапканда үлеп китәрсең дип курыктым», – дим...

Улыбыз 7 март иртәсендә туды. Мин берникадәр вакыт ышана алмый тордым, берничә тапкыр кат-кат сорадым: «Чынлап та улыбыз тудымы? Дөресме?!» – дим. «Әйе, улыгыз туды, улыгыз!» – дип, санитарка мине телефоннан котлады. Шуннан соң гына йөрәккә җиңел булып китте...

Үземне дөньяда иң бәхетле кеше итеп тоеп, хатыныма записка язарга утырдым. Бөтенләй моңарчы кабатланмаган иң җылы, иң назлы сүзләрне табасы килде. Әмма, үч иткәндәй, Сәкинәне таң калдырырлык, аңа лаек булырлык бернәрсә дә башка килмәде. Шунда мин классигыбыз Һади Такташ шигырьләреннән файдаланырга булдым, мәктәптән үк аның әсәрләрен яттан белә идем.

Ана! Нинди бөек исем!
Нәрсә җитә ана булуга?
Хатыннарның бөтен күрке,
Бөтен матурлыгы ана булуда!

Записканы хатыныма тапшырдылар. Соңыннан үзе дә сөйләде. Укыгач, үзеннән-үзе күзләре яшьләнгән. Шатлык яшьләре, билгеле».

Заманында Минзәлә өяз шәһәре була. Шәймиевләр мичкә ягышлы бүрәнә өйдә яшиләр. Суга чиләккөянтә асып йөрисе. Минтимер иртәдән кичкә кадәр эштә. Сәкинә дә шәһәр сәүдә челтәрендә икътисадчы булып эшли.

Сәкинә Шәймиева сөйли: «Минзәләдә без биш ел яшәдек. Минтимер өчен дә, минем өчен дә тормыш

PRESSA.RU

мәктәбе булды ул. Кечкенә бала белән килеп төштек. Эшләргә дә, хуҗалыкны да алып барырга, баланы да карарга кирәк. Икенче улыбыз Радик туды. Малайлар кечкенәдән үзара тату булдылар, бер-берсен якладылар. Олысына күбрәк эләгә иде, ул елаганда, кечкенәсе аның хәленә кереп, башыннан сыйпый һәм: «Не пач, не пач...» – дип кабатлый. «Елама» дип юатуы инде үзенчә.

Ул чакларда декрет ялы дүрт ай була иде: бала тапканчы ике ай һәм тудыргач ике ай. Дүрт айдан соң эшкә чыкмасаң, күп сөйләшеп тормыйлар, җибәрәләр генә. Шуңа улларыбызны ике айдан яслегә йөртә башладык. Ике сәгать саен эштән сорап китеп, бәйдән ычкынгандай яслегә чабам – баланы имезергә кирәк. Бөтенесенә 30 минут вакыт бирелә. Ясле эштән ерак, бернинди транспорт йөрми. Бер-ике минутка соңга калсаң – профкомга чакырталар, җыелышларда кыздыралар. Бөтенесенең күз алдында басып торасың, сине оялталар. Берсен бакчага, икенчесен яслегә илттем, шуңа соңардым дип аңлатырга маташулар файдасыз. Җитешә алмасаң, эшкә кичтән үк кил, дип төрттерәләр иде.

Без директор өендә яшәдек. Уңайлыклар юк дәрәҗәсендә. Иремне, директор буларак, машина йөртә, ләкин хатыны берничек тә балаларны бакчадан машинада алып кайтырга тиеш түгел. Асфальт турында хыялланасы да юк. Елның күп вакыты өчен иң уңайлы аяк киеме – резин бутыйлар. Эштән кайтышлый балаларның берсен бакчадан, икенчесен яследән алам. Бер кулда азык-төлек тулы сумка, икенчесендә – кечкенә улым. Олысы, арудан шыңшып, итәгемә ябышып атлый. Әнә шулай елый-елый өйгә кайтабыз. Өйгә җитәрәк, бәләкәе кулымнан шуып төшә, аны тотарлык хәлем дә калмый. Ишек зур амбар йозагына бикләнә, аны ачканда кулларым калтырый башлый. Балаларның



үзләрен генә калдырып, көз-кышларын пычрак ерып, караңгыда суга йөгерәм. Иңсәмә көянтә асып ничә чакрымнар үттем икән!.. Өйдә ике бәләкәй бала булганда, никадәр су кирәген чутлап карагыз... Ашарга да пешерәсе, керен дә уасы, башка кирәк-яракка да тотасы. Ике чиләк су алып кайтасың да иң башта нәрсәгә тотасыңны тиз генә хәл итәсең: ашарга пешерергәме, чәй куяргамы, кер юаргамы. Ә балаларның киемен көн саен юарга туры килә. Бүген юмасаң, иртәгә бакчага кидерер кием юк. Кичтән юасың, иртән үтүклисең – һәм көн саен шулай.

Өйне җылытыр өчен көн саен ике зур мичкә ягасы. Шулар аркасында күпме күз яше түктем!.. Безнең утын гел чи була. Минтимер утын белән хезмәткәрләрен тәэмин итеп бетергәч кенә, үзебезгә кайтарта иде. Ә алар йә көзге яңгыр астында озак ятып чыланып беткән, йә беренче суыклардан чиләнеп калган.

Мунчабыз, яшелчә бакчабыз да бар әле. Хәзер дә шаккатам: ничек барысына да җитештем икән? Минтимер ялларсыз эшли. Бераз гына буш вакыт тисә, су ташый, мунча яккан көннәрдә су аеруча күп бетә. Ашарга керосинкада пешерәм. Анысы тагын бер җәза. Шул чактагы сакчыллыгыма исем китә. Кәстрүл, табалардагы корымны аз су белән дә ничек юып бетерә алдым икән?

Иремә эштән кайтышына берәр тәмле ризык пешерергә тырыша идем. Аңа шалтыратып, бүген нәрсә пешерим, нәрсә ашыйсың килә, дип сорый идем. Кич бөтенесенә өлгерергә кирәк, шуңа бик тиз әзерләргә өйрәндем. Минтимер бөтенесенә сөйли икән: янәсе, аның хатыныннан башка беркем дә кыстыбыйны ярты сәгатьтә пешерә алмый! Чынлыкта, андый тизлектә бөтенесен әзерләп өлгерер өчен миңа тиен урынына бөтерелергә туры килә иде. Бәрәңге пешкән арада камыр җәям, аны кечкенә кисәкләргә бүлгәләп, табада кыздырып алам да, төйгән бәрәңгене кыстырып бөкләп чыгам. Җитешми хәлең юк!

Минтимер Шәймиев сөйли: «Һәркем гомер буе үзе кечкенәдән ашап үскән ризыкка өстенлек бирәдер, мөгаен. Минем иң яраткан ризыгым – кыстыбый. Үзе тәмле, үзе туклыклы. Юка төче камырга кайнар бәрәңге боламыгы йә тары боткасы төреләде майлап табынга куела. Әйтеп аңлаталмаслык тәмле була! Минем хатыным искиткеч тәмле пешерә аны! Татарлар әйтмешли, телеңне йотарлык була!»

Сәкинә Шәймиева сөйли: «Бервакыт югары температура белән балаларны бакчада алмадылар, үзләрен генә өйдә калдырдым. Малайлар парикмахерлы уйнарга булганнар. Өйгә кайтсам, бәләкәе танырлык түгел! Абыйсы шундый итеп «кыркыган» – баш ала-тилә итеп туналган! Ярый әле кайчы белән ул-бу китереп чыгармаганнар! Икенче көнне чын парикмахерга барырга, «өйдәге мастер»ның эшен төзәтергә туры килде инде.

Көнкүреш кыенлыклары адым саен очрап тора иде. Әмма Минзәләдә яшәгән елларны сагынып искә алам. Яшь идек, көчле идек, тормышыбызны үзебезчә җайга сала белдек. Анда без беренче суыткычыбызны алдык,

радиоалгыч күтәреп кайттык. Ул чактагы шатлануларым!.. Минтимер өйдәге эшләремне төрлечә җиңеләйтергә тырыша иде шулай...»

Минтимер өйләнер алдыннан ук булачак хатынына турысын әйтә: «Сәкинә, мин сиңа алтын таулар вәгъдә итә алмыйм. Үзең беләсең, авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым, эшем авыл белән бәйләнгән. Без авылда яшәрбез. Әмма шунысын ышандыра алам: гомер буе сине кайгыртачакмын һәм яратачакмын!»
Сигез ел Мөслим һәм Минзәлә районнарында эшләгәннән соң, 1967 елда Минтимер Шәймиевне Казанга партия өлкә комитетына инструктор итеп күчерәләр.

Сәкинә Шәймиева сөйли: «Казанда тусам да, җитеш көнкүрештә яшәмәдек. Җәйләрне авылда туганнарымда үткәрәм, табигать почмагында утырган авыл тормышын яратам. Һәм беркайчан да иркә шәһәр кызы булмадым. Казанга күченү хәбәрен исем китми генә кабул иттем. Бөтен уңайлыклары булган фатирга кереп утыргач исә үземне оҗмахка эләккәндәй хис иттем. Су ташыйсы юк, көянтә-чиләкләр кирәкми. Чи утын белән мич тә ягасы түгел: батареялар болай да кайнар. Краннан кайнар һәм салкын су ага. Үз бәхетемә ышана алмый тордым хәтта! Казанга күчкәч, Минтимернең дә балаларга вакыты кала башлады. Районда чакта тәүлек буе эштә тоткарланса, монда ял көннәре дә бар икән. Эшкә дә таңнан ук чыгып чабасы түгел. Ул баштагы мәлләрдә гаҗәпләнеп: «Сәкинә, обкомда кешеләр эшкә тугызга гына килә икән...» – диде».

Ышанычлы тыл һәм җан тынычлыгы. Болар Сәкинә Шакир кызы турында, әлбәттә. Исеме дә гарәпчәдән «җан тынычлыгы, иминлек» дип тәрҗемә ителә. Мөгаен, аңа югарыдан шундый вәкаләт тапшырылгандыр... Минтимер Шәрип улы журналистларга биргән интервьюларында һәрчак: «Минем өчен эш беренче урында булды. Сәкинә барында гаилә өчен борчыласы юк», – дип әйтә килде.

Сәкинә Шәймиева сөйли: «Казаннан ерак түгел, Васильево бистәсе янында безнең дүрт сутыйлап җиребез бар иде. Минтимер бакча эшләрен малайларга бүлеп бирде. Тапшырылган эш сыйфатлы итеп башкарылгач кына уйнарга чыгарга рөхсәт ителә иде. Ул һәрчак, һәр җирдә улларын хезмәткә өйрәтте. Өйдәге стенада башкарыласы эшләрнең графигы эленеп торды. Малайлар аларның үтәлеше өчен үзләре җаваплы. Кем – идән, кем – савыт-саба, кем кер юа, кем ашарга әзерли... Айрат аеруча әйбәт җыештыра. Ул тотынса, фатир чип-чиста булып кала. Ә Радик ашарга әзерләргә маһир. Без көннәр буе эштә булгач, кайтуыбызны көтеп тормыйча, бөтен эшне дә бетереп куялар иде. 7–8 нче класстан башлап өйләнгәнчегә кадәр булыштылар. Әтиләре шулай өйрәтте. Хатыннары нинди бәхетле булачак дип уйлый идем. Ләкин менә бит парадокс: өйдә гел булышмыйлар дигән сүзләрне ишетәм киленнәрдән. Мин инде шаяртуга күчәм, балачакта эшләп туйганнардыр, дим.

Һәр җәйдә улларыбызны авылга җибәрә идек. Беренче хезмәт хакларын да шунда алдылар: җәй буе комбайнчы ярдәмчесе булып эшләделәр.

Улларыбыз белән һәрчак горурландык. Алар чын кеше булып үстеләр: акыллы, юмарт, эш рәте белә торган, юл куя белгән, мөстәкыйль... Башкаларны аңлыйлар, аларның хәленә керә беләләр. Юлда сумка күтәреп торган әбине күрсәләр, машинага утыртып, өенә кадәр илтеп куялар. Әби-бабалары каберенә чәчәкләр куеп кайталар.

Кече улыбыз Радик армиядә чакта бик борчылдым. Миңа калса, ул иң авыр хезмәтне – диңгез пехотасын сайлады. Әтисе дә эчтән сызды, төннәр буе йоклый алмый ятты. Башка гаскәрләрне сайларга күндерергә тырышты. Радик үз сүзеннән кайтамы соң?! «Әти, ә анда кем хезмәт итәр?» – диде.

«Ничек шундый акыллы балалар үстерә алдыгыз?» – дип сорыйлар кайчак. Әллә нинди махсус тәрбия дә булмады кебек, без аларны ярата идек, алар хилафлыклар эшләмәсен дип тырыша идек... Аллага шөкер, балалар өчен кызарырга туры килмәде. Балачакта әтиләре белән малайлар арасында җитди сөйләшүгә сәбәп булган ике генә очракны хәтерлим.

Минтимер белән эштән кайтып киләбез шулай. Күрше малае очрады. «Абый, сезнең Айрат анда малайлар белән тәмәке тарта», – ди. Олы улыбыз ул вакытта дүртенче класста укый иде. Әтисе улына бер сүз дә әйтмичә гастрономнан папирос сатып алып керде дә Айратны тартырга мәҗбүр итте. Бала тончыга, тыны кысыла, ютәлли, елый. Әтисе өзми дә куймый: «Тарт, тарт...» – дип кабатлый. Иртә белән тагын шул ук хәл. Һәм атна буе шулай. Нәтиҗәсе күз алдында: ни олысы, ни кечкенәсе ник бер тартып карасын!

Катлаулы ситуацияләрдә Минтимер, үзе дә сизмәстән, әтисе кебек коры була белде. Хәзер алар ул көннәрне елмаеп һәм рәхмәт белән искә алалар.

Андый җәзаларны күреп тору миңа авыр иде. Балалар бик кызганыч, мин икенче бүлмәгә чыгам да елыйм. Ә Минтимер: «Сәкинә, малайларга катырак булмасаң, алардан кемнәр чыгасы билгесез», – ди торган иде. Хәер, ул үзе дә минем белән бергә кайгыра, балаларга ныграк эләкте бугай, дип борчыла иде».

Минтимер Шәймиев сөйли: «Зөбәрҗәт туебызны үткәрдек – бергә яши башлавыбызга 55 ел! Уен эшмени! Миннән еш кына гаилә тормышының озын гомерле булу серен сорыйлар. Гаиләләр ничек яшәргә тиешлекне заманча болай аңлатыр идем: ике якның да хокуклары һәм бурычлары тигез, 50 гә 50. Ирләргә тагын бер киңәш, бәлки, кемгәдер ярап куяр. Мөнәсәбәтләр киеренкеләнә башласа, бирелгәндәй, кулларымны өскә күтәрәм дә хатыныма: «Син хаклы, алдан ук гаебемне таныйм!» – дим. Ничек кенә ярап куя әле! Бәхәс, кабынырга да өлгермичә, шундук сүнә. «Хатын-кыз хаксыз булса да, аңардан гафу үтенергә кирәк», – дип французлар белеп әйткән шул...»

PRESSA.RU



ЯРАТУ! ТАГЫН – САБЫРЛЫК, ТҮЗЕМЛЕК, ЗИРӘКЛЕК... БЕР-БЕРЕҢӘ ХӨРМӘТ, ИХТИРАМ. ТИРӘ-ЮНЬДӘГЕЛӘР СОКЛАНЫП КАРАГАН ҺӘР ГАИЛӘНЕҢ НИГЕЗЕНДӘ ИҢ ЭЛЕК ШУШЫЛАР ЯТА.

Бүген сезне шундый матур гаиләләрнең берсе – Гөлнара һәм Азат НУРМӨХӘМӘТОВлар белән таныштырабыз. Көрәш белән кызыксынучылар Азатны күптән беләләр. Билбау көрәше һәм татарча көрәш буенча Россиянең спорт остасы, Казан шәһәренең «Ак барс» көрәш балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе директоры ул. «Татарстан» радиосын тыңлаучылар Гөлнараны да тавышыннан таный. Аяз һәм Камал исемле ике ул үстерәләр.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

МӘХӘББӘТ, СИН МИНЕ НИШЛӘТТЕҢ?!

Танышу

Гөлнара: Минем иң беренче туры эфирым иде ул... Көнен дә хәтерлим – 17 сентябрь. «Татарстан» радиосында туры эфирны шактый тәҗрибә туплаганнан соң гына бирәләр. Аның миңа нинди зур вакыйга булуы аңлашыла инде... Директорыбыз Тәүфикъ Камәртдин улы: «Үзеңә нинди тема якын – шуны ал», – диде. Яшьләр темасына тукталдым: аларның тормышка, милләт язмышына, гаилә коруга мөнәсәбәте турында сөйләшергә уйладым. Казанда «Шәрык» клубының гөрләп эшләгән чагы – тапшыруга шул клубка йөрүчеләрне чакырдым. Берничә кыз килергә ризалашты. «Берәр егет тә булса...» – диюемә, «Безнең Азат исемле бик акыллы егетебез бар, аны чакырырбыз», – диделәр. Студиягә кызлар белән бергә Азат та килеп керде. Юк, шунда ук ошаттым дия алмыйм... Сорауларны алдан биреп куйган идем – әзерләнеп, җавапларны язып ук килгән. Монысы күңелемә хуш килде. «Чын татар гаиләсе нинди булырга тиеш?» – дигән иң соңгы соравыма Азат: «Әти-әниемнең гаиләсе нинди – татар гаиләсе шундый булырга тиеш дип саныйм», – дип җавап бирде. «Димәк, Азат бик яхшы гаиләдә үскән», – дип уйладым. Мин аңа шул минутта гашыйк булдым бугай... Икенче тапкыр без «Шәрык» клубында очраштык. Ул миңа «сез» дип эндәште. Оныткандыр дип уйладым – кәефем төште...

Азат: Таныдым... «Син» дияргә уңайсызландым гына. Бер күрүдә Гөлнарага гашыйк булдым, дия алмыйм. Миндә ул хисләр беркайчан да адым саен кабынмады. Әмма бер кабынса – гомерлеккә!..

Гөлнара: Безне «Шәрык» якынайтты... Икебез дә бик актив кешеләр булып чыктык без: татар яшьләренең иҗтимагый тормышы эчендә кайнадык. Атнага алты төрле чара уза иде «Шәрык»та. Бөтен кеше «Вконтакте»да утырмый иде әле: яшьләрне кичәләргә чакырган белдерүләрне принтердан чыгарып, шәһәр урамнарында үзебез ябыштырып йөрдек. Азат белән бергәләп шулай йөри-йөри дуслашып киттек инде без.

Азат: Мин «Атнакич»не алып бара идем «Шәрык»та. Очрашуга кемнәрне генә чакырмадык: җитәкчеләр, депутатлар, язучылар, җырчылар... «Шәрык» яшьләрне күп нәрсәгә өйрәтте, киләчәккә старт бирде. Аның таралуы бик кызганыч... Без анда йөргәндә, танышып, җиде пар өйләнештек ул чакта.

Гөлнара: Ул парлар белән хәзер дә аралашабыз. Һәммәбез гаиләсендә татар телендә генә сөйләшә, балаларын да шул рухта тәрбияли. Барыбызның да туйлары бер тирәдә булды, шуңа күрә балалар да бер яшьтәрәк. Аязның туган көнендә уникәү булдылар әнә!

Пар канат булыйк гомергә...

Гөлнара: Моны сөйләсәм буламы, акыллым? Без танышканда, мин читтән торып ике җирдә укый, радиода эшли идем. Беркөнне иртәнге унда Азатка шалтыраттым. Мин инде иртәнге эфирдан кайтып, хәбәрләр язып утырам. Телефонны алды да: «Йоклый идем әле», – ди... Шулкадәр гаҗәп тоелды, бу вакытта кеше йоклап ятамы, дип эчтән уйлап куйдым.

Азат: Гөлнара ул чакта 9 мең хезмәт хакы ала иде – аның кесәсендә гел акча бар. Ә мин авылдан 500 сум алып киләм... Эч поша башлады. III курсны тәмамлагач, мин дә читтән торып укуга күчтем, эшкә урнаштым.

Үземә сүз биргән идем: читтән торып укуга күчәм икән, тагын берәр җиргә укырга керәм, дип. Сүземдә тордым. КФУ каршындагы Карьера үсеше һәм халыкара сертификация үзәгендә укыдым, инглиз телен өйрәндем. Монысы – икенче югары белемем. Көрәш ярышларында хөкемдар булып йөри башлагач, инглиз телен белү ихтыяҗы туды.

Гөлнара: Текстларны хәрефләп укый иде беренче мәлдә, аптырый идем. Мин мәктәптә өйрәндем инглиз телен, яхшы беләм дип саный идем – беренче мәлдә Азатка шактый булыштым. Ә хәзер ул аптырый, телне белмисең, ди. Үзе инде инглизчә иркен сөйләшә ул.

Азат: Уку ошый миңа! Университетта гел «бишле»гә генә укыдым, спортфакны кызыл дипломга тәмамладым. Лекцияләргә иртәнге җидегә чаклы әзерләнгән көннәр күп булды. Бүлмәдәш егетләр йокыга киткәнне көтеп ятам да, торып чыгып, коридорда яки кухняда укырга утыра идем. Иртән – алар торганчы кереп ятам.

«Ак барс» көрәш сараенда эшли башлагач, мине янә укырга җибәрделәр. Бу юлы идарәче кадрлар әзерләүче Президент программасы буенча ике ел белемемне күтәрдем. Көн саен төшкә кадәрле чит тел өйрәндек без анда – инглиз телем шунда чарланды.

Аннан аспирантурага кердем менә. Элек шунда-шунда укыйм дип горурланып әйтә идем, хәзер яшерәм – һаман укый бу, башка эш белми диярләр.

Гөлнара: Аспирантурага керергәме-юкмы, дип бик озак уйладык. Аннан тәвәккәлләдек. Азатның хыялы иде бу! Конкурста 14 кеше катнашты, җидесен генә алдылар. Аның фәнни эшенең темасы бик кызык: һәр язган мәкаләсен мин дә укып барам.

Азат: Татар көрәшенең тарихы турында бездә китаплар язылган, ә менә аның теоретик ягы бөтенләй өйрәнелмәгән дисәм дә була. Әйтик, күнегүләргә кайсы яшьтә тотынырга, 12-14 яшь арасында көрәш алымнарының кайсыларын өйрәтергә, көрәшкә әзерләнгәндә ничек тукланырга... Көрәшнең башка төрләрендә боларның барысы да кат-кат өйрәнелгән, тикшерелгән. Ә бездә – юк. Татар көрәше яшәсен, үссен дисәк, аның фәнни ягын да үстерергә кирәк. Көрәш алымнарына өйрәтү буенча махсус программа булдырасым килә. Мин бүген шул эш белән шөгыльләнәм.

Гөлнара: Без сезгә вакыйгаларны ашыктырыбрак сөйләдек бугай...

«Миңа кияүгә чык!»

Азат: «Бергә булыйк!» – дигән тәкъдимне Гөлнара диплом алган көнне ясадым. Халыкара гаилә көне иде.

Гөлнара: Төн уртасында! Без ул көнне көндез Азат белән күрешә алмадык. Дөресрәге, ул котларга килмәде. Башка кызларның егетләре чәчәк тотып каршы алдылар, ә Азат юк!

Азат: Ә мин эштә идем...

PRESSA.RU



■ Һәр кыз бала кебек мин дә туем бик үзенчәлекле булырга тиеш дип хыяллана идем. Нәкъ шулай узды! Азатлар җиккән атларда гармун уйнап, җырлап килеп керделәр авылга. Азатның башында – түбәтәй, минем өстә узган гасыр башы күләшләренеке кебек бөрмә итәкле күлмәк. Барысы да гади генә булса да, матур иде.



Гөлнара: Кәефем төшкәнне сизгәндер инде... Артымнан Кукмарага кайткан! Шалтырата: «Чыгып кер әле», – ди. Ә мин бит аңа үпкәләгән әле, горур, сер бирмим имеш: «Бу вакыттамы? Төнге унике икәнен беләсеңме? Без инде йоклыйбыз!» – дим. Ахырда түзмәдем, билгеле, чыктым. Капка төбендә «Чык миңа кияүгә!» дигән язу тотып басып тора. Открыткасы бар иде әле тагын бик үзенчәлекле. «Риза!» – дип җавап биргәч, мин анда кул куярга тиеш идем. Миңа – 23, Азатка 21 яшь бу вакытта. Үзебезне бик зурлар дип санаганбыздыр инде...

Азат: Әти белән әни «иртәрәк» дип, бер сүз әйтмәделәр! Әти белән без бер генә сөйләшәбез. Яки хәзер, яки утызда гына дидем.

Гөлнара: Әйе, безнең әти шулкадәр Азатка ышана ул... Шунда ук «ярар» дигәндер! Аннары сорарга килделәр... Хәләл туй уздырдык. Районның туган якны өйрәнү музее белән сөйләшеп, анда кыз сорау йоласын үткәрдек. Азат минем энекәшләргә «җизни бүләге» дип пәке бирде. Кара-каршы җырлаштык. Римма Ибраһимованың «Мәңге бергә» җырына вальс әйләндек. Барысы да «Шәрык» клубы рухында узды!

Без туйда ял иттек. Барысы да алдан төзелгән план буенча барды. Азатның гадәте ул план төзү. Загстан чыккач, кунакларның кайсы нинди машинага утыра, кем табынга чәкчәкне алып керә, кем музыка өчен җаваплы... Барысы да алдан язылган иде аның.

Азат: Без туй көнне яңгыр явар инде, дип кенә борчылдык. Аңа кадәр койды да койды... Ә 4 ноябрь иртәсендә көн аязып, аяк астын катырып куйды. Күктә бер болыт юк иде!

Сынаулар

Гөлнара: Мәхәббәт очрашканда бертөрле була, ә өйләнешкәч, бөтенләй үзгәрә икән. Сынаулар уза-уза ныгый. Иреңнең еш командировкага йөрүе дә сынауга әйләнергә мөмкин кайчак... Аяз белән сигез айлык авырлы чакта сукыр эчәгемә операция ясадылар. Безнең өчен беренче сынау шул булды. Бала өчен бик курыктык: ничек туар, зыяны булмасмы? Азат янымнан китмәде. Аяз тугач, табиб аңа: «Улыгызның күзе сезнекенә охшаган», – дигән. Бу аның өчен зур бүләк булды...

Оясында ни күрсә...

Азат: Әби-бабай белән үскән балаларны мин бик бәхетлегә саныйм. Минекеләр ике генә чакрымдагы күрше авылда яшәде. Авылга кайткан чакларда йөгерергә чыксам, юлым гел шул якка – Тәмте Мәтәскәгә алып бара мине: йорт алдына шомыртлар үскән нигезләренә кадәр барып җитәм дә, кире борылам. Әни ягыннан бабай тракторда эшләде, миңа аның янында бөтерелү кызык иде. Өстәвенә, ул әле тальянда уйный! Әби гомер буе укытучы булган. Китаплар яратy – алардан күчте.

Гөлнара: Аяз: «Мин әти булам», – ди дә, Азатның ничек китап укыганын күрсәтә.

Азат: Әни дә, әти дә бик күп укыйлар безнең. Иртәнге дүртләргә кадәр китаптан аерыла алмаган чакларым бар. Кызганыч, әдәби китапларга вакыт җитми хәзер. Кул астымда күбрәк менеджмент, маркетинг буенча дәреслекләр. Заманы шундый – белемеңне өстәп, үзеңне үстерү белән шөгыльләнмисең икән, бик тиз артта каласың.

Гөлнара: Безнең өйдә, әлбәттә, Азат – баш! Малайлар үстерәбез бит – алар гаиләдә нинди тәртипләр булырга тиешлеген кечкенәдән күрсен, белсен.

Азат: Ике якта да әти-әниләребез тигез, матур яшиләр – аларны кабатламасак, гөнаһ булыр. Әле безнең барысы да алда – яши генә башладык. Тирә-юньдә аерылышучылар шактый. Уйландыра... Очрашып йөргәндә яраткан кешеңә булганыңнан әйбәтрәк күренергә, яраклашмаска кирәк. Чөнки бу уйнау белән бер: үз-үзеңне дә алдыйсың, сайлаган ярыңны да. Кушылып яши башлагач, барыбер барысы да ачылачак. 10-15 елдан түгел, 10-15 айдан ук.

Гөлнара: Безнең гаилә нинди булачак, дип, өйләнешкәнче үк сөйләшергә кирәктер. Әгәр егете, юк, алай була алмый, дип кискен каршы төшсә, кыз уйланырга

тиеш. Гаилә корганда хисләрне юкка гына читкә куеп торырга кушмыйлар. Егетнең әти-әнисе ничек яшәгәненә дә игътибар итәргә кирәк – без барыбыз да үзебез үскән гаиләләрне кабатлыйбыз.

Азат: «Күз төшеп йөргән кызың белән тукталышта торганда менә мондый тәҗрибә үткәреп кара әле, – дигән иде бер танышым. – Автобус килеп җитәрәк: «Юк, әйдә, трамвай белән кайтыйк әле», – дип әйт. Ә трамвай тукталышына барып җиткәч, кире автобусныкына алып кит. Кызың аяк терәп каршы төшми икән, димәк, бар да әйбәт булачак, аңа өйләнә аласың». Мин Гөлнараны шулай йөрттем берсендә. Ул сизмәде дә!

Гөлнара: Ире акыллы булган хатын-кыз үз урынын белергә һәм чәчрәп алга чыкмаска тиеш. Ә без шул хәзер «үзебез дә булдырабыз»... Тормышта күбрәк хатын-кыз булып кала белергә кирәктер. Әмма моның өчен, әйткәнемчә, ирең акыллы булу кирәк!

Азат: Ир-ат үзенең хатыны турында: «Мин аның яклаучысы!» – дип уйларга, моның чыннан да шулай икәнен сизеп, күреп, белеп торырга тиеш. Аңарда бу хис калмау куркыныч, минемчә.

Гөлнара: Яңа өйләнешүчеләр күп вакыт акча кем кулында булырга тиешлеген хәл итә алмый. Без бу хакта әле очрашып йөргәндә үк сөйләшеп куйдык. «Сезнең өйдә акчаны кем тота?» – дип, мин аннан турыдан-туры сорадым.

Азат: Гомер-гомергә акча әти кулында булды. Утка, суга, газга да ул түләде, хәзер дә шулай. Гөлнара белән безнең «синең акча, минем акча» дигән сүз юк. Барысын да икәү хәл итәбез.

Гөлнара: Азат кайчак: «Шуны-шуны алдым», – ди. «Үзең эшләгән акча, нигә әйтеп торасың?» – дим.

Азат: Анысы минем кычкырып уйлавым инде... Мин өйләнгәндә Гөлнарага: «Эшләмәсәң дә була, ләкин өйдә утырма, җаныңа туры килгән шөгыль тап», – дидем. Радио аның өчен бүген барысын да алыштыра: эшне дә, хоббины да – шуңа күрә ул аннан китмәде. Өйдә дүрт стена арасында гына утырса хатын-кыз үсештән туктый. Ә кеше гел үсештә булырга тиеш: күбрәк белергә, күбрәк өйрәнергә омтылырга... Башкалар белән чагыштырганда түгел, кичәге «үзеннән» күбрәк белергә.

Гөлнара: Без бу хакта Азат белән еш сөйләшәбез. Ул менә аспирантураның I курсын тәмамлады: ел, димәк, бушка узмады. Минем дә андый хыял бар – балалар исәйгәнне көтәм... Әлегә фотомәктәп тәмамладым менә – күптәнге теләгем чынга ашты, ниһаять. Күн мозаикасына өйрәнеп йөрим.

Азат: Көрәштән дә киткән юк! Сөенерлек уңышлар бар, Аллага шөкер... Былтыр Теләче балалар Сабан туенда беренче тапкыр Аяз да көрәште. Беренче урын алды! Сәләте бар дип әйтергә иртәрәк, аңа әле 4 яшь тулды гына. Нииндидер алымнарга махсус өйрәткәнем дә юк. Үзем исә 3 нче сыйныфтан бирле көрәшәм.

Гөлнара: Мин элегрәк Азатның көрәшкәнен карап торырга да курка идем. Әни – кайнанам хәзер дә карамый... Азат өчен бик борчылсам да, мәйдан читендә утырып, аның көрәшкәнен күзәтү хәзер кызык та миңа. Алымнарын таныйм! Көрәш темасына кереп китсәк, безнең сүз беркайчан бетми...

12+
TATAR RADIOSI
Kazan 100.5 FM**
ЛИДЕР СРЕДИ РАДИОСТАНЦИЙ, ВЕЩАЮЩИХ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ*
*По данным ЗАО «ТНС ГЭЛЛАП МЕДИА» («TNS Gallup Media»), отчет от 27.09.2016 г. По договору №К048/2016 от 1 августа 2016 г.
**Казань 100,5 фм
РЕКЛАМА

PRESSA.RU



Татарстанның халык шагыйре, Республиканың Тукай премиясе лауреаты Разил Вәлиевкә 70 яшь! Бу санның зурлыгы яшәгән гомернең, иҗатның олылыгы белән бәяләнә. Шуны барлар өчен, Дәүләт кешесе белән эш хакында түгел, фәкать иҗат, дуслар, онытылмас еллар хакында иркенләп сөйләшү нияте белән, Татарстан Дәүләт Советына (!) якынлашып киләм. Шагыйрьнең эш урыны яшел лампа кабызып куелган имән өстәлле тын кабинет кына түгел шул. Бәлки меңнәр сукмак салган депутат кабинеты! Инде дистә еллар шулай. Бу еллар дәверендә әллә нинди шигъри күңел дә, тозлы яшьле гозерләрне тыңлый-тыңлый, каешланып бетәргә мөмкин.



Асия ЮНЫСОВА

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ: «МИН ЙӨРӘГЕМ ЯКЛЫ»

«И-и, булса да булыр икән дөньяларда бер яхшы кеше!» – ди пропуск язып утыручы ханым, кем янына килгәнемне белгәч. Аз-маз беләм, дим, эчемнән генә. Яшьлеккә бергә кергән идек ләбаса.

Разил («ович»ларны читкә куябыз, бездән кабул итми дә ул рәсмилекне), җиде көлтәне матур, көяз итеп бәйләп куйдык, дисең инде. Бәрәкәтле гомер кичерүең белән котлыйм сине. Котлауны «Сөембикә» журналы, аның син күрсәткән ярдәм белән ишәйгән күпмеңле абунәчеләре исеменнән дә кабул ит! Синең янга гел җитди итеп сөйләшү, дәүләти ярдәм соралган гозерләрен хәл итү юлында йөргән кешеләр киләләр. Ә мин менә яшьлегеңнән сәлам булып килдем әле. Сөйләшүне дә шуннан башлыйкмы?

– Әйдә, алайса, Казаныбызның Кызыл Позиция урамындагы 2 нче тулай торакның 27 нче бүлмәсенә керик. Без анда – бер бүлмәдә – дүрт шагыйрь яшәп алган идек. Ул бүлмә студент тормышының беренче адымнарына гына түгел, һәркайсыбызның үз төбәгендә инде бераз чарланган каләменең сынап каралуына да шаһит. Мин университетка шагыйрь дустым Мөдәррис Әгъләмов – Нәни гигант белән бергә килдем. Тулай торак коридорында икенче бер гигант – Зөлфәт белән маңгайга-маңгай бәрелештем. Бүлмәдәш тә булып чыктык. «Детский мир» кибетеннән сатып алып, пардан яшел бишмәтләр киеп йөрдек. Мин Зөлфәткә шаярып «абый» дип эндәшә идем, чөнки ул миннән бер көнгә өлкәнрәк. Икебез дә сигез-тугыз балалы гаиләдән. Шактый гына дәү егетләр булгач та туган көннәрне бергә үткәрә идек.

Дөнья әдәбияты ялгыз талантларны сөйми. Хәтеремдә иңгә-иң торган дуслык үрнәкләре яңара. Герцен–Огарев, Аполлинер–Матис, Пушкин–Дельвиг, Шәүкәт Галиев–Илдар Юзеев, Разил Вәлиев–Зөлфәт... Бу исемлекне озак дәвам итеп булыр иде. Шагыйрьләр, гомумән, иҗат кешеләре дуслыгы гади генә төшенчә түгел ул. Шагыйрьнең даһилыгын аңлар өчен аның янәшәсендә шундый ук бер даһи торырга тиеш. Гади бер табынучы, яратучы гына түгел, нәкъ менә зурның зур икәнен бәяли белүче. Теләктәш, мәсләктәш, казанышыңны күрүче, дәртләндерүче. Тик әшнә түгел! Бер кызык җөмлә укыган идем: «Матис аның бөек иҗатчы икәнен күргәч кенә Аполлинер Аполлинер булды». Сез бер-берегезне «күрә» белә идегез.

– Белдек, дип уйлыйм. Чөнки, заманы җиткәч белән, Мөдәррис тә, Зөлфәт тә халык таныган зур шагыйрьләр булып җитештеләр, Тукай премиясенә ирештеләр. Бер бүлмәдән шулкадәр шагыйрь чыгу үзе дә феномен бит. Шунда гына – янәшә бүлмәдә генә Илдус Гыйлаҗев, Нур Әхмәдиев, Харрас Әюпов яшәп ята, юк ла, язып ята. Болар да зур шагыйрьләр! Марсель Галиев тә әллә ни ерак түгел... Тулай торакның һавасы ук әфсенле иде, шигырь белән сулый торган идек.



■ Мин университетка шагыйрь дустым Мөдәррис Әгъләмов – Нәни гигант белән бергә килдем. Чулман–Идел буйлап бер пароходта. Икебезгә бер түтәрәм ипи, үзебездә үскән кыяр-помидор белән юлга чыккан идек. Мөдәррис – татар бүлегенә, мин – журналистикага.

Сез бит әле бүлмә газетасы да чыгара идегез...

– Әйе, «Фанатик» дигән газета иде ул. Рәфикъ Юныс белән мин журналистлар лабаса. Газетада үзебезнең шигырьләр басыла. Үзара осталыкта ярышабыз. Минем әткәйгә багышланган шигырем беренче ярышта ук бертавыштан җиңүче дип табылган иде.

Хәтерлим ул шигырьне мин дә. Ничек әле:
«Минем әти
Тарих тәгәрмәченә
Тимер кыршау кидергәндә
Тапталып үлде...» – дип башланып китәме әле ул? Исән әти турында мин «үлде» дип яза алмас идем.

– Шагыйранә шартлылык бу. Үз әтиемне түгел, ә шәхес культы елларында корбан булган әтиләрне күздә тотып язган идем мин аны. Без бит гадәтилектән качып, инкыйлаби романтикага чумган идек. Коридорда трибун тавыш белән шигырь укып йөргән Зөлфәт кулында Байрон булса, минекендә Гарсиа Лорка иде.

Тоташ сәясәт, димәк. Ә мин 60 нчы, 70 нче еллар шигърияте мәхәббәт канатында җилдерде, димәк, сез дә мәхәббәт учагына утын ташыдыгыз, дигән фикерне куәтләмәкче идем. Тик менә бөтен шигырьләреңнән алда телемә: «Каерып ач урыс капкаларны, / Керсен бәйрәм татар өенә», дигән шигъри юлларың килә. Ярсу, дуамал идегез... Язучылар корылтае барган залга листовкалар томыручылар да сез бит – 27 нче бүлмә шагыйрьләре. Сез ул вакытта судан коры чыктыгыз кебек тоелган иде. Алай ук булмаган, ахры. Синең Мәскәүдә – Әдәбият институтында ректордан шелтә алуың, стипендиядән мәхрүм ителүең, бераз соңрак Зөлфәт белән Мөдәрриснең университеттан сөрелүе, шул листовкалар аркасында булгандыр.

PRESSA.RU

– Әлбәттә, мондый бәйләнеш бар. Холык шундый иде шул. Яши-яши үзгәрәбез. Хәер, үзгәрәм микән?

Үзгәрәсең, үзгәрәсең… Минем дәлилем бар:
«Офык сала алтын бишегенә…
Мин саташам, тирлим, ут янам.
…Чал карт булып кич йокыга талам,
Сабый булып таңда уянам», – бу да син!

– Дөрес тотып алдың. Мин мәктәптә үк шактый кыю сәяси шигырьләр язган кеше. Барыбызда да бар иде ул Такташ, Лорка романтикасы. Мин аннары да, Әдәбият институтында укыганда да, латыш шагыйре Александр Чак, америка шагыйре Уолт Уитмен, француз шагыйре Франсуа Вийон белән җенләндем. Кайвакыт «сәясәтем» үз шәхесем тирәсендә дә тулганып ала торган иде:

«Кеше атлы нәни бер кыйтга мин…
Матурлык бар миндә, батырлык.
Күпме тырышсаң да, булмый мине
Хәят диңгезендә батырып!»

Ә минем сәяси эстафетаны менә болайрак дәвам итәсем килә:

«Мин яу булып түгел, яучы булып
Бусагаңа бастым, Европа.
Дөньябызда әле хаксызлык күп –
Берәү елый, берәү елата.

Без күтәргән йөкне кем җиңел, ди!
Кем кайгыны безнең аз дия?!
Азияне Европага димлим,
Европаны сиңа, Азия!»

Их, менә бу төштә Разил Вәлиевнең дөнья буйлап сәяси сәфәрләре турында сөйләп китәсе килә. Ә бәлки шул дөньяда Татарстанны – тиңнәр арасында тиң, татар телен – үксез түгел, бәлки хуҗа тел итү өчен барган мәңге туктап калмаска тиешле көрәш хакында синең кебек кайнарланып язарга кирәктер. Ә бит син Ватан, Ирек кебек кыйммәтләр хакына җырга әйләнгән шигырьләрең белән дә көрәштең. «Ватаным», «Татарстан», «Бәхетем башкаласы»… Бүтән санамыйм. Әйдә, йодрыкны төйнәп басылыйк та Мәхәббәт турында сөйләшик. Мәхәббәт, димәк, Музалар хакында. Һәр шагыйрьдә бар алар. Пушкинның Анна Керны, Маяковскийның Лилясы, Есенинның Дунканы, Высоцкийның Владие… Ә менә татар шагыйрьләренең телен чиштереп булмый. Музасыз гына язалар бугай алар мәхәббәт шигырьләрен.

– Татарның тыйнаклыгыннан, сөйгән ярларының исемен кадерләвеннән килә ул. Кемдә булмасын инде ул сөйгән сөеклеләр? Илһам ияләре! Миндә дә булган инде ул. Язылган да. Укый белергә кирәк шигырьләрне. Мин бит беренче китабымда ук хәбәр иткән идем: «Бер мәхәббәт табар өчен / Бер яшьлегем җитәрме?» – дип. Яраттым мин дә. Зөлфәт менә гадәти генә хатын-кызны да матур итеп күрә белде, акыллыларны сайлап сөйде, ә мин чибәрләрне! «Юмарт булыйк, әйдә, / Чын күңелдән Бөреләргә чәчкә дип дәшик!» – менә безнең девиз нинди иде.

Укый белмиләр димә. Үзгеңне көйдергән мәхәббәтеңә дә дәлилем бар минем.

«Аны миннән көннәр генә алды.
Йөрәк каргый хәзер елларын.
Сагынганда инде элеккечә
Ызаннарга ятып еламыйм.
Ләкин әле җитәкләшеп йөргән
Урман сукмакларын юксынам.
Гомер юлым тагын шул сукмакка
Алып барып чыгардыр сыман».

Бу шигырьнең ачкычын табу кадәресен укучыга калдырыйк. Минемчә, бихисап җырларыңның һәркайсының иясе бардыр. «Зинһар өчен, кермә төшләремә…» дип инәлгәндә дә, «Ядкарь» дип, үлә язып сагынганда да шагыйрьнең йөрәге яралы…

Шулай да әдәбияттагы иң зур казанышың?

– Казанышмы? Иң зурысы алда булырга тиештер дип уйлыйм мин. Хыялым – бөтен эшне ташлап көнтөн язып утыру. Уйда йөргән, сәгатен көтеп торган темалар байтак. Шигырьләр түгел. Өлкәнәйгәч, акыл утырткач прозага күчү мәслихәт. Шигырь – яшьлек ул. 20 яшьтә «Эт кояшы» дигән бәян язган идем мин. Бу әсәремне 21 елдан соң гына нәшир итә алдым. Казаныш булган өчен басылмады бугай ул. Нәшриятның ул чактагы баш редакторының бәясе кызык: «Артык көчле язылган. Начар булса, кеше укымас иде. Ә болай, бу әсәр – куркыныч! Җитди хәлләр хакында талантлы итеп язылган. Чыгармыйбыз». Шушы вердикт Аяз Гыйлаҗевның: «Шәп! Лихо!»сын күмеп китте. Шуннан соң мин шигырьгә барып сыендым, сәхнә әсәрләренә качтым. Шактый вакытлар узгач кына прозага – «Яшисе килә», «Иске сәгать дөрес йөри» бәяннарына, «Мирас» романына әйләнеп кайттым…

Сәхнә өчен язылганнарың сине җырлар язуга китерде. Чөнки «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» дигән музыкаль комедияң, асылда, мюзикл бит инде ул. Ә мин, казаныш дигәндә, гражданлык гамәлен күздә тоткан идем. «Яшен тамыры» дигән икенче китабыңның әҗер акчасына туган авылың Ташлык мәчетен манаралы, айлы итү гамәле иң биек нокта түгел әле…

Кабатланды бит ул…

– Кабатланды. Милли китапханә директоры булып алгач, элекке Печән базары мәчете бинасын китапханә өчен алуга ирештем. Анда борынгы сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге ачтык. «Кинопрокат» ише төрле оешмалар хуҗа булып торганнан соң ул тарихи бина бик бетеренгән иде. Ремонт хәстәре белән Министрлар Кабинетына – Мансур Хәсәнов янына кердем. Бер очтан мәчетнең манарасын күтәрергә дигән ниятем барлыгын да әйттем. Туздырып ташлады бу мине. Мәскәү нишләтә безне моның өчен,

диде. «Нишләтми, юлы бар аның, – дим. – Мин бит мәчет ремонтламыйм, китапханә бинасын рәткә китерәм, ә тарихи бинаның архитектурасын тергезгән өчен гаепләмәсләр». Бинаны да яңарттык, манараны да торгыздык, аен да куйдык – шулай итеп тарих кабатланды. Хәзер ул мәчетне халык Нурулла мәчете дип тә, Ак мәчет дип тә йөртә. Минем өчен ул чыннан да Ак мәчет. Әйбәт эшләр майтару өчен беләкле генә түгел, теләкле дә булырга кирәклекнең символы да әле ул.

Дусларыңны барладык, инде дошманнарың кайсы илдә яши?


– Дусларны барлап бетермәдек әле. Алар да төрле илләрдә яши. Әдәбият институты минем дуслар географиясен, милләтләр вәкиллеген шактый киңәйткән иде. Алары да сыналган. Бер мисал. Әдәбият институтында профессор Водолагин: «Кырым татарлары барысы да сатлыкҗан», – дигән җөмлә әйтеп ташлады. Мин урынымнан тордым да: «Башка сезнең лекцияләргә йөрмим», – дип чыгып киттем. Миңа бурят егете дә, латыш егете дә, алтай егете дә иярде. Алар гомер буе дусларым исәбендә булды. Ректор Пименов исә мине кабинетына чакырып тиргәде: «Институтта шигырь язалар, сәясәткә кермиләр», – дип, тагын өч айга стипендиядән мәхрүм итте. Гаиләмне төнлә макарон фабрикасында эшләп туендырдым. Әй, дошманнар дигән идең бит әле. 1985 елда, гомеремнең иң авыр бер чорында, Язучылар оешмасы төзүдә булышырга дип, Әфганстанга баргач, телевидениегә чакырдылар. Алар да шушы сорау белән сүз башлады. Имеш, «дошманнарга» мөнәсәбәтем ниндирәк? «Мин бу илдә беренче мәртәбә генә. Дусларым да, дошманнарым да үз илемдә, Казанымда калды», – дидем.

Әфганстан. Мөгаен, бу илдә калган сугыш хатирәләре, анда татып караган хәвефле романтика китапка күчү сәгатьләрен тилмереп көтә булыр. Әфганстанның хуҗасы Бабрак Кармаль белән очрашып сөйләшкән, бронетранспортерда, вертолетта, самолетта Әфганстанны аркылы-торкылы буйлаган язучы безнең әдәбиятта бүтән юк. Көтәбез ул әсәрне.

– Әфганстанда татар авыллары да бар икән. Бу хакта миңа Бабрак Кармаль белән Нәҗибулла сөйләде. Татар егетләре күпләп кырылган Кандагар, Герат, Кундуз калалары төшләремә кереп, бүген дә бимазалый. Мине анда Максим Горькийның оныгы – Россия илчелеге секретаре Максим Пешков озатып йөрде. Әйе, язасылар күп. Моңа кадәр болар турында язарга мөмкинлек юк иде... Хәзер киртәләр алынды сыман. Мин әле һаман иртәгәдән яши башлармын гына кебек.

Иң бәхетле көн йә алда, йә үткәндә була диләр, ә менә иң фаҗигалесе һәрвакыт синең белән.

– Иң фаҗигале «көнем» җиде ай дәвам итте. Әфганстаннан кайткач, җиде ай хастаханәдә яттым.



Башта Казанда, аннары Мәскәүдә. Минем диагноз белән операциягә кергән уникe кешенең уникесе дә исән чыкмады. Мин унөченчесе, бәхетлесе булып, Казанга унсигез килога ябыгып кайттым. «Син тәмам Тукайга охшап калгансың икән», – диде урамда очрагач Рөстәм Фәйзуллин. «Әйе, – дидем. – Кыяфәтне ясадым, иҗат ягын җайлыйсы гына калды».

И-и, синең шул гел дә гел юмор белән сөйләшүләрең...

– Безнең өйдә әткәй дә, әнкәй дә төрттереп сөйләшергә һәвәсләр иде. Ә менә тиргәү, ачулану булмады. Гел мактап, үсендереп тора торганнар иде. Мин үзем дә балаларны, оныкларны тиргәмим. Күбрәк әйбәт сыйфатларын күрергә тырышам. Калганын алар үзләре дә аңлыйлар.

Үкенечләр?

– Үземә кагылганы – чит телләрне белмим. Кызым Сөембикә өч тел белә, оныкларым дүрт телдә сөйләшә. Милләткә кагылганы – туксанынчы еллар белән чагыштырганда сүрәнләндек, милли ашкыну, милли куәт кими бара сыман. Әнә, Астанада Сөембикә ханбикәнең 500 еллыгына затлы китап чыгарганнар, бер урамнарына аның исемен кушканнар. Ул бит югыйсә безнең ханбикә! Ә без монда ни эшләдек? Тарихыбызны, асыл затларыбызны башка милләтләр берәм-берәм йолкып ала, үзләштерә бара. Шулай итеп, үкенечләр, фаҗигаләр бер төенгә төйнәлә. Ярый, мин кызыма Сөембикә исемен куштырдым, ханбикәбезгә багышлап җырлар яздым. Сез ханбикә исемен журналда саклыйсыз. Болар гына аз бит. Һәйкәл кирәк, урамнар кирәк, Сөембикәгә багышлап фәнни конференция үткәрергә кирәк. Тынычланырга иртә әле безгә. Дөньялар гел болай гына бармас. Мин халкыбызның киләчәге матур булыр дип өметләнәм. Шуның өчен җан атып яшим.

Әйе, Яңа елга кергәндә киләчәккә ышаныч белән карыйк. Исән булыйк! Теләкле, максатлы булыйк.

PRESSA.RU

ҖЫР БӘЙРӘМЕ









Казан. 17 декабрь. Сәгать телләре 17.00 гә якынлашып килә. Җырмоң сөюче халык «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгенә ашыга. XVII «Татар җыры» фестивален тамаша кылырга!
Ел да көтеп алына торган җыр бәйрәменең 2016 елгысы менә шулай 17 саны белән бәйләнгән иде. Фестивальнең режиссеры Ирина Алешина: «7 – бәхет саны, 1 ле исә аның тәэсирен тагын да арттыра. Быелгы «Ак барс» сыны катнашучыларга һичшиксез бәхет китерәчәк», – дип, санның хикмәтен дә аңлатып үтте. Барлыгы 17 номинациядә 26 җырчыга «Алтын барс» сыннары тапшырылды. «Барс Медиа» компаниясе дәүләттән бер тиен алмыйча уздыра торган бу фестиваль заманында бик күп җырчыларга зур сәхнәгә юл ачты инде: Алинә Шәрипҗанова, Иркә, Илназ Баһ, Ландыш Нигъмәтҗанова, Раяз Фасыйхов, Алинә Сафиуллина. Быел исә «бәхетле билет» яшь җырчылар Лилия Хәйруллина, Рамил Закиров, Гөлназ Батталова, Сөмбел Билаловага эләкте.
«Татар җыры»н тамаша кылырга килүчеләр арасында Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән һәм мәгариф милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев тә бар иде. «Беренчеләрдән булып татар җырын зур сәхнәгә күтәргән фестиваль бу. Бүген фестивальләр, конкурслар шактый. Әле күптән түгел генә, Президентыбыз ярдәме белән, «Үзгәреш җиле» концерты узды. Аннан бездә Ваһапов фестивале бик популяр, «Татар моңы», Рөстәм Яхин фестивальләре бар. Кайберәүләр, шулкадәр күп фестиваль, конкурслар нәрсәгә кирәк, дип әйтер. Җырчыларны да кемдер – 800, ә кемдер 2 мең, ди. Алар булсын. Җырласыннар. Әгәр дә кеше җырларга омтыла икән, димәк, аның күңелендә ниндидер талпыныш бар. Бу һич кенә дә начар түгел. Вакыт үтәр, кибәге очып китәр, алтын бөртекләре калыр, дип уйлыйм мин», – диде ул тантанадан соң. Ә алтын бөртеге кем икәнлеген халык үзе билгеләде. Зәйнәп Фәрхетдинова, Филүс Каһиров, Хәния Фәрхи, Айдар Галимов, Гүзәл Уразова чыгыш ясаганда зал шартлардай булып алкышларга күмелде бит әнә. Президент Рөстәм Миңнеханов үзе дә килгән иде «Татар җыры»на.
Аның исеменнән сәхнәгә зур кәрзин белән чәчкәләр чыгарылды.
«Татар җыры» фестивале тирәсендә ел да тәнкыйть болытлары куермый калмый. Шулай да оештыручыларның нинди зур эш башкаруын аңлап, җырчыларга канат куярга теләп, хуплау сүзләре җиткерүчеләр күбрәк, дисәк, ялган булмас. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, режиссер, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин да: «Һәр чорның үз җыры бар. Прогресс бара, берәүләр алмашына, икенчеләр чыга. Җырчыларның сәләтләре бертигез түгел, бар уртакул башкаручылар. Барысы да кадерле. Иң мөһиме – алар бит татарча җырлый, татар моңын күтәрә», – дип, үз фикерен белдерде.
Оештыручылар, XVII «Татар җыры» фестивале 12 миллион сумга төште, диләр. Мондый масштабтагы тамаша иганәчеләр ярдәменнән башка тиешле дәрәҗәдә уза алмас иде. Ә алар – сыналган, оештыру эшләрендә ел да ярдәм итеп килүчеләр: «Агросила» агрохолдингы, «Татнефть» оешмасы, Кама коммерцияле банкы, «АВА-Казан» клиникасы, «ФинДом» төзелеш оешмасы, «Кукмара» металл заводы, «Матбугат.ру» сайты, «Бизнес Онлайн» электрон газетасы, «Татар радиосы», ТМТВ телеканалы һәм башкалар...

Фәнзилә МОСТАФИНА.
Фото: Эльмир ГАБИДУЛЛИН.

















PRESSA.RU

Такташның сүзен хәтерлибез: «Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә...» Иске, әлбәттә. Тик һәр йөрәктә ул яңара, төрле әверелешләр кичерә. Һәркем үзенчә ярата. Бик сирәк кешеләр генә аны тасвирлап бирә ала. Ландыш ГАБДРАХМАНОВА шундый сирәк кешеләрнең берсе. Шагыйрә. Аның лирик шигырьләренә нәни эпиклык хас, аның шигыре ниндидер бер вакыйгадан үсеп чыга. Аңа ышанасың. Хисләренә, кичерешләренә... Ул абстракт төшенчәләр белән эш итми, берни дә аңлатмый торган гомуми сүзләр кулланмый. Гади генә сүзләрдә дә мәгънә төсмерләре. Шуларда үзенчәлекле шагыйрәне танысың.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА



Ландыш
ГАБДРАХМАНОВА

УЛ КАДӘР ҮК ЕЛАК ТҮГЕЛМЕН!!!

Синсез...

Таңнар да ата икән...
синсез...
кояш та бата икән...
синсез...
йолдыз да калка икән...
синсез...
гөлләр дә үсә икән...
синсез...
җилләр дә исә икән...
синсез...
тик...
таңнары –
никтер төссез...
гөлләре – моңлы,
иссез...
йолдызлар сүрән,
хиссез...
кояш нурлары –
көчсез...
Синсез...

Ачык капка

Еллар аша килеп, саксыз гына,
Кактым синең күңел капкаң,
ә үзем бит беләм: минем өчен
бу капканы хуҗа күптән япкан...
Үҗәтләндем: «Ачтырырмын барыбер,
Яшьлектәге төсле
йөрәгеңне яндырырмын!»
Ачтың...
Танымадың...
Уз, – диеп тә ялынмадың.
Ә минем бит килде кулларыңа
кагыласым,
назлы итеп муеныңа сарыласым...
Әрсезләндем, кактым кабат:
«Искә төшер! Хәтереңне яңарт!»
Җавап бирдең: «Сөйдем...
Яшьлегемдә синең өчен
яндым-көйдем...
тик син... үзең белән
артык мавыктың...
ә мин... яралардан яңа савыктым...»
Үзсүзләндем кабат-кабат:
«Тагын ярат! Тагын ярат!»
Елмайдың... «Ә бу безгә кирәкме?
Кайсы өстен:
Акылмы? Әллә соң йөрәкме?»
Тынып калдым...
Кире борылдым...
Барыр сукмагымны тапмадым...
Ә син...
Карап калдың...
Ә капкаңны...
Ә капкаңны никтер япмадың...

* * *

Яраткандыр, – димә,
Яратмадым...
Авыр чагым иде... сыендым...
Серләремне килде бүлешәсем,
Туктап калдым никтер, тыелдым...
(Аңламассың кебек тоелды...)
Яраткандыр, – димә,
Яратмадым...
Ярдәм көтеп бары төбәлдем...
Игътибарлы булдың, үзеңә тиң
Биеклеккә мине күтәрдең...
(Түбән төшердең дип үртәлдем...)
Яраткандыр, – димә,
Яратмадым...
Мөлдерәмә идем... түгелдем...
(Тулган чагы иде күңелнең).

Көчсезлектә мине гаепләмә,
Кайтып кара –
Мин чынлыкта...
Ул кадәр үк елак түгелмен!!!

Исәнме!

– Исәнме, бу бит – син!
– Исәнме, әйе, мин!
(Юл чатында, еллар аша килеп,
басып торабыз... өн бу, өн!)
– Ә син үзгәрмәгән... шул ук күзләр...
– Олыгайдык... җыерчыклы йөзләр...
(«Ел саен шул сагыш өстәп китә
Синсез килгән көзләр»).
– Ничек икән анда без утырткан
пар каен?
– Яшьләр җыела бугай,
язлар җиткән саен.

(«Ничек булсын? Төнге күкне уйла,
нишләр иде, югалтса аен?»)
– Ә мин онытмадым... исәр,
дисеңме?
– Әниең ничек? Хәле? Исәнме?
(«Әллә мине оныткандыр дисеңме?
Улым йөртә синең исемне»).
– Аерыласым килми...
җибәрәсе килми кулың...
– Сау бул! Бәхеткә төренсен
үтәсе юлың.
(«Сизмәдең шул...
гомер буе сине көтәм...
Раббым, очраштырмасаң иде
бүтән...»)

Уяну

Чүл...
Ком тузаны бәргәләнеп
учларымнан ага...

– Бик тирән бугай күңел яраң...
– Сөюемнән китеп барам...

Чүл...
Кәрлә куаклар шәүләсе
кочагыма ава...

– Димәк, үзеңнән качып барыш?
– Калдыр, дәрвиш... минем язмыш...

Ком...
Ниндилеген аералмыйм...
Сарылыгы – сагыш...

– Хыянәтенме кичермәдең?
– Нигә сиңа?.. Төшенмәдем...

Төн...
Ялгызы түгел... Йолдызлары,
Ае – аның табыш...

– Син җырлап кара, булдыралсаң...
– Алай гына... ансат котылалсам...

Төн...
Ул бүген дә ялгыз түгел...
әнә якынлаша...

– Әйдә, җырлыйк...
син кушылырсың...
– Әйдә... Бәлки миңа куш
булырсың...

Төн...
Сарыладыр акрын гына
сары ком аша...

– «Сөйгән ярым китеп барды
кулын болгап.
Кайтыр микән тагын миңа юллар
урап?»
– «Сау булыгыз акчарлаклар,
акчарлаклар.
Мәхәббәткә кирәк икән
пар канатлар...»

– Жиңеләйдеме... җырлый алгач?
– Булмый...ялгызлыкны
көйгә салгач...

– ...Ә ай, йолдызлар нинди төстә?
– Көлдерәсең... кара өскә?..
– Ә кояш ничек чыга, әйтче?
– Тиледер син, дәрвиш, китче...
– Син хыянәтне әче, дисең...
– Әче... тапмадылар аңа исем.

Төн...
Сарыла ул... тузан тына...
Буыла тын гына...

– ...Акчарлакны?.. Бармы күргәнең?
– Диңгездә юкмы йөргәнең?
– Диңгез... зәңгәр диләр дулкыны...
– Синең... аңламыйм холкыңны?..

Таң...
Кояш нуры чүл өстенә
Ягыла тын гына...
Дәрвиш белән арам нигә якын?
Чүмәшкән яныма...

– Яраң тирән дип, ялгышканмын...
– Ничек инде ялгышканмын?..
– Сөю ул китсә, тагын килә...
– Хыянәте җанны теләә...
– Син бик бәхетле... аңла шуны...
– Күрсәт миңа туры юлны...
– Күктә йолдыз саный алу...
акчарлакны таный алу...
дулкыннарны барлый алу...
үзең булып кала алу...
бер үлгәч, кабат уяну...
Бәхет ул.... син аңладың мине...
– Кичер, дәрвиш... кичер мине...

Чүл...
Ком тузаны бәргәләнеп
Җаным аша ага....
аксын...
Кәрлә куаклар шәүләсе
кочагыма ава...
аусын...
Сары комда – минем эзләр...

Колагымда чыңлый сүзләр:
«...Күктә йолдыз саный алу...
акчарлакны таный алу...
дулкыннарны барлый алу...
үзең булып кала алу...»

Көн...
Үз илемә...
Үз-үземә кайтам...
Кайтып килеш...
Ком тузаны аша
кулын болгый...
Сукыр дәрвиш...

* * *

Кабереңдә ят чәчкәләр күреп,
Дертләп киттем: Ул! Килгән!
Минем канәферләр, үги сыман,
Бераз гына читкә этелгән.
Иртән дулап алган кар бураны
Эзләренә яткан. Каплаган.
(Йә Ходаем, җитмәгәнме аңа
Язмышларны безнең таплаган?)
Килгән! Сагынадыр... Түзәлмәгән!
Димәк, ул да бүген бирешкән!
Бармы икән тагын исәр җаннар,
Киткәннәрне шулай бүлешкән?
...Рәшә нурларында яз шәйләнә –
Ул да карлар белән көрәштә!
Синең китүеңне кичерәлми,
Алты чәчәк ята янәшә...

* * *

«Ут, диеп ялгышма!
Күзләргә ягылган,
Йөзләрдә чагылган
Ул бары –
Яндырган күперләр яктысы!
Син тыңла! Син аңла! Чамала!
Сүрелсен өметең чаткысы!» –
Диясе урында...
Нигә, дип, мин биим, аңышмый,
Саташкан күзләрең учында?
Нигә соң мин күләм бу кадәр
Шашынган бер исәр шикелле?
Кып-кызыл миләшләр татлыдыр...
Бозларын эретү икеле...
Ышыкла, арала нахактан.
Көч алыйм тылсымлы җылыңнан.
...Үзем дә аңламый түгеләм
Сап-сары өрәңге җырыннан...

PRESSA.RU



Фирүзә
ҖАМАЛЕТДИНОВА

ОФЫК АРЪЯГЫ БОЛЫТЛЫ...

(Хикәя)

Яхшылык белән явызлык бертигез булмаслар, чөнки яхшылыкта файда һәм савап бар, явызлыкта зарар һәм газап бар.

(Коръән. «Фуссыйләт» сүрәсеннән.)

Гадәттә мин урамга чыгар алдыннан тәрәзәгә күз төшереп алам: ни хәлләр бар икән дөньяда? Бәлки, куртка-мазар эләктерәседер, кем белә, яңгыр явып китмәгәе.

Ләкин бу юлы кояшның пәрдә аша чалымланган алтын нур-толымнары уйнаклавы күңелемә тынычлык өстәдеме – тиз генә җыендым да өйдән чыктым.

Подъезд ишеген ачуга, уң ягымдагы фәрештәм:

«Дөнья матур!» дип пышылдады кебек.

«Офык аръягы бераз болытлап тора!» диде сул яктагысы.

Башымны күтәреп, зәңгәр күкләргә төбәлдем. Сабырлыкка уралып, тын гына өрфия болытлар йөзә. Тукталышка илтүче сукмак буендагы юкәләр, яшь кызлар кук, бер-берсенең колагына иелеп сер сөйләгәндәй тоела.

– Дөнья матур! – дип кабатлыйм уң яктагы фәрештәмә кушылып. – Дөнья һич кенә дә ямьсез була алмый, Аллаһы Тәгалә аны искиткеч камил итеп яраткан.

Шул мәлдә салкынча җил исеп китте, биек күкләрнең бер читендә йөзеп барган караңгы болыт күзгә чалынды. Сул яктагы фәрештәм, миңа кушылмавын сиздереп, җилкәсен сикертеп куйгандай тоелды. Беләм: гамәлләрем дөрес булса да, гадәтем дөрес үк түгел; дөнья никадәр генә үзенең ак һәм кара төсләрдән торганлыгын исбат итәргә тырышса да, бар вөҗүдем һаман яктылык ягына авыша, болытларны гына түгел, кешеләрне дә судан пакь итеп күрергә тели. Күрәсең, мин камиллек үлчәве тәлинкәсендә аклык баса төшкән мәлдә туганмындыр...

Йа Аллам, сәеррәк автобуска эләктемме соң әллә? Күрче, урыннарны баскычлап-баскычлап урнаштырганнар. Элек автобусларда да тигезлек иде шул... Рәт арасы да менеп-төшеп йөрешле түгел, урындыклары да гел алга карап барышлы. Безнең яшьлек шундый чорга туры килде: артка карау, гомумән, гаеп санала иде. Хәзер башкачарак, кемгә алга, кемгә артка карау ошый.

Шулай да, бу юлы артка төбәлеп барышлы булса да, урыным өстәрәк туры килде. Урамдагы хәрәкәт шау-шуы, кешеләрнең үзара әкрен генә сөйләшүләре бергә кушылып, ниндидер серле халәт тудыра; тәрәзәдән сибелеп кергән үткен җил каты сулышы белән чәчләрне сыпыра,

кайсы якка теләсә, шул тарафка рәхәтләндереп тузгыта. Берәү түзмәде кебек, күз алдымда чиксез нәфис бармаклар иренеп кенә тәрәзәне ябарга үрелде. Абау! Минем мондый да матур тырнакларны әлегәчә күргәнем булды микән? Үзләре озын, үзләре әллә ничә төскә буялган. Бер... ике... өч... дүрт төс... Рәссам картиналары диярсең. Мин тырнак иясенең йөзенә төбәлдем: «Статуя» дип уйлап куйдым эчтән генә. Гөнаһтыр кешегә болай кушамат тагу. Гафу ит мине, мәрхәмәтле Аллам! Горур нәфис сыныннан котып салкыннары бөркелә сыман чөнки. Гадәттә, мондый гүзәл ханымнар автобуста йөрми. Йә шәхси машинасы ватылган, йә һава суларга чыккан җирдән ялгыш кына гади халык арасына эләккән бу чибәркәй. Бала белән бара икән бит әле. Нарасые уенчык машинасын тоткан көенчә йокымсырап киткән. Әнә уянды да.

Әлбәттә, үтәли җил балага ярамас. Тик яшь ана, тырнакларын җәрәхәтләүдән куркыпмы, пыяланы бер якка этеп карады да кулын кире алды. Җиңелчә хәрәкәтеннән борынга тәмәке исе бәрелде. Юк, юк, затлы сигарет иседер инде. Сукыр тавыкка бар да бодай диләрме әле... Ул арада без тукталышка якынлаштык.

– Әннә-нә-нә! – дигән тавышка күтәрелеп карасам, тагын берәү бала арбасын эчкә тартып кертте дә тәкәббер ханым янынарак урнаштырды. Ике коляска янәшә туры килде. Автобуста үтәли җил уйнавын яшь ана шунда ук сизде, тәрәзәне бер тартуда ябып та куйды. Эшләп ныгыган кулларын бер күз ташлауга чамаларга була: тырнаклары буялмаган, үзе дә гади ситсы күлмәктән иде. Чәчләрен дә артка җыеп төйнәп кенә куйган. Улының күзләре үткен икән: янәшәсенә утырган малай кулындагы уенчыкны шунда ук күреп алды.

– Әннә-нә-нә! – дип аваз салды ул нәни кулын юлдашы ягына сузып.

Аның йөзендәге хәрәкәтләр: «Ай-яй матур уенчыгың, минем мондый машинам юк шул!» дигәнне аңлата иде кебек.

– Кәрим, балакаем, егылып төшәрсең, матур гына утыр әле, – дип кисәтү ясагандай итте ана.

«Таш сын» исә чит малайның баласына үрелүен ошатмады: юка иреннәрен кыса төште, колясканы читкәрәк күчерде. Тик Кәримне уенчык чиксез кызыктыра, күршесенең уенга кушылмавы бераз гаҗәпләндерә дә иде.

– Әннә-нә-нә! – дип, ул тагын уенчыкка үрелде. «Миңа да биреп тор инде, тотып кына карыйм бит», – дигән кебегрәк ялвару катыш эндәште ул. Тәкәббер ханым, кашларын җыерып, башта балага, аннан әнисенә канәгатьсез караш ташлады. Үзе дә сизмәстән, елкылдык бриллиант алкаларын, йөзекләрен тоткалап, төзәткәләп куйды. Аның бу гамәле «хәерче башың белән балаңа шулхәтле ирек бирәсең» дигәнне аңлата иде булса кирәк.

Берәрсенең бизнесмен ирен тартып алгандыр әле, күзендә оят әсәре күренми, дип уйлап куйдым. Алинә кебек... Динара кебек, мәсәлән... Танышларым арасында да күп икән кеше гаиләсенә керүчеләр. Дөресрәге, гаилә бозучылар. Тәкәбберлекне сөя бугай ла ир-ат затлары. Салкын чибәрлеккә мөкиббәннәр...

Сатирә исемле хезмәттәшем дә, әнә, бер байдан бала табып, тегенең хатынын тәмам чиргә сабыштырды. Сау-сәламәт ир авыру хатын белән яшәмәс бит инде, дип, үз-үзен акламакчы була хәзер. Бик беләсең килсә, акча гаепле барысына да, ди.

Мәрхәмәтле Аллам, үзең ярлыка... гайбәт итеп түгел, гыйбрәт итеп кенә искә алуым...

Тик нигәдер алар бер дә мәхәббәт турында сөйләшмиләр шул. Мәхәббәт югыйсә Аллаһы бүләге. Әлеге сабыйлар да. Бөтен автобусның игътибары аларга юнәлгән әнә.

Тик Кәрим кебек үк, әнисе дә аны-моны уйламый, ике нарасыйга төбәлеп, ихлас елмаеп торуын белә. Ә Кәримнең күзе күршесендә генә шул. Кызыктыра ла аның уенчыгы. Бала тагын бер кат машинага үрелде, тегесе җыерылып, уенчыкны күкрәгенә кысты. Авызын турсайтып, ямьсез итеп карап куйды. Кәрим бераз хәл җыеп, уйланып утырып торды, һәм янә үрелеп, кабартмадай куллары белән бер яктан коляскага тотынган көенчә күршесенең кул аркасын сыйпады. Ул сыйпауның җылылыгын, йомшаклыгын автобустагы һәммә кеше тойды шикелле. Аның һәр хәрәкәте: «Синең белән дус буласым килә, биреп кенә тор инде уенчыгыңны!» дия иде кебек. Баланың җанындагы бар назын салып, яратып сыйпый белүенә гаҗәпләнүдән баш чайкап куйдым. Кайлардан килә диген сабыйга шулкадәр акыл! Әлбәттә, Аллаһтандыр.

– Кәрим, әтиең акча алгач та үзеңә сатып алырбыз, кешенекенә кызыкма, бәбекәччәем, – дип, әнисе, иелеп, улының чәченнән кат-кат сыпырды.

Зифа тәкәббер зат үзеннән кыскарак буйлы хатынга кимсетүле карап алды да, боларның гадилеге йокмасын тагын, дигәндәй, колясканы янә бер читкәрәк күчерде. Аннары тәненә ябышып торган кыска зәңгәрсу елкылдык күлмәген сыпырып куйды. Зәңгәр сөрмәле озын керфекләре арасыннан әллә нинди мәгънәләр сыпылып чыкты. «Йә, аңла инде үзегезнең кем икәнлегегезне!» дигәнен генә эләктереп кала алдым шикелле.

Ләкин малайдан алай гына котылып булмасы көн кебек ачык иде.

– Кәрим, тәтием, өйдә үз уенчыкларың да җитәрлек бит, – дип, әнкәсе күпме кабатласа да, күршесенеке кызыктыра иде шул. Уенчыгы күп булса да, мондые юктыр ла аның! Аннан уенчыкта гынамыни хикмәт! Дуслар да кирәк ласа ошбу җиһанда!

Кәрим бер мәлгә тынып калды: «Нинди генә чара табарга соң моңа? Шулкадәр саран булмаса!» – дия төсле иде аның гаҗәпләнгән карашы.

Кинәт кулы муенына асылган имезлегенә тиеп китте. Менә икән бит хикмәт! Сөенечен кая куярга белмичә, сабый коштай талпынып куйды, елмаюдан йөзе нурланып балкыды. «Ыгы-ыгы» дип үзенчә сөйләнде һәм имезлекне өмет катыш җиңеллек белән эләктереп тә алды... Төбәлеп торды да, елмая-елмая, аны күршесенә сузмакчы булды. «Иң кадерле әйберем бу минем. Иң татлы ризыгым. Ансыз яши алмыйм. Йоклый да

PRESSA.RU

алмыйм. Ләкин мин аны сиңа кызганмыйча бирәм», дия иде малайның күзләре.

Кайлардан килә адәм баласына мәрхәмәт? Әлбәттә, Аллаһтандыр.

Кайлардан килә адәм баласына игелек? Әлбәттә, Аллаһыдан.

Бай ана да түзмәс: «Йә улкаем, биреп тор уенчыгыңны, төшкәндә кире алырбыз», – дияр дип көттем мин үзем. Ләкин ул бер сүз дә дәшмәде. Тәкәбберлек кешеләрне каты күңелле дә итә шул.

Улы исә авызын бәлшәйтте дә машинасын күкрәгенә тагын да ныграк кысты. Нәни җан иясенең күңеле барыбер бер йомшыйсына ихлас ышана иде бугай нарасый. Ничек ул уенчыгын җәлләргә тиеш инде? Машина имезлек түгел бит әле. Теләсә кемгә биреп булмый торган әйберме? Тоттырып кына каратсын иде. Күршесе үзен аңлап бетермәде дип уйлады булса кирәк, «әннә-нә-нә», дия-дия, «ризыгын» янә малайга сузды. Әлбәттә, башы имезлеге артыннан тагын да ныграк тартылды һәм тәмам малайга якынаеп бетте. Бу хәлне күреп торган тәкәббер ананың иреннәре юкарып, тәмам төсе үзгәрде. Шул мәлдә... Шул мәлдә гүя автобусны яшен сукты.

Малай уенчыгын итәгенә ташлады да күршесенең йөзенә нәни йодрыгы белән тондырды. Нарасыйның имезлеге кулыннан төшеп үк китте. Бала бер мәлгә тын ала алмый торды, аннары илереп елап җибәрде.

– Мәрхәмәт җиңелде, – дидем мин ихластан әрнеп.

Инде тәкәббер ана улы өчен гафу үтенер дип көттем. Яхшы уйлап һаман ялгышам шул кешеләр хакында.

Автобусның тыны кысылды гүя. Миңа да һава җитми кебек тоелды.

«Ник инде авызын капламый, нарасыен рәнҗеттереп тора», диде сыман сул яктагы фәрештәм түземлеген җуеп. Уң яктагысы үз сукмагына төшерде: «Күз алдыңа китер: сүз иярә сүз чыгып, талаш-ызгыш китте, ди. Яхшылык явызлыкка әверелә бит. Ә тәрбияле хатын ул чикне атламады. Яхшылык ягында кала белде».

– Кәрим, тәтием минем, әйттем бит сорама дип... – Ананың тавышы калтырана иде.

Сул яктагы фәрештәм борчылып:

«Аңа чиксез авыр ласа... Чигә тамырлары бүртеп чыкты әнә», диде.

«Шуңа да яхшылык бәхетле затларга гына бирелә. Аллаһы бүләге ул. Аны һәммә кеше булдыра алса, җир өсте күптән оҗмахка әйләнер иде. Хак түгелме?» диде уң яктагысы.

«Син хаклы», дип хуплады төсле сул яктагы фәрештәм, каләмен күңел түремә ташлап.

Мин дә килештем. Автобустагылар яхшылыкның шаһиты булды ласа. Әйе, тәкәбберлекне беркем дә якламады. Беркем дә каршы да чыкмадымы? Шул гамәлләре белән дә кешеләр яхшылык ягында калдылар мәллә соң?

Мин шуны аңладым: яхшылык күңелдә булырга тиеш икән ул. Күңелдә булган нәрсә барыбер дөньяга чыкмый калмый.

Чынлап та, тәкәбберлек чамасыз икән бу ханымда. Гафу үтенсән, шулкадәр халык арасында үзеңне гаепле тоярга кирәк бит аннары, дип уйлыйдыр мөгаен. Хәер, ул моны булдыра алыр идеме? Юк, юк, матди байлык кешеләрне иблискә әйләндерәдер. Иблисне дә Аллаһ оҗмахтан тәкәбберлеге өчен җир өстенә куып төшергән. Ә җир өстендә әле ул күпләрне юлдан яздырадыр... Бармак тулы бриллиантлары янәшәсендә йөзек-алкасыз, иске коляскалы бу затлар кем инде, җә? Тәкәббер ана шулай уйлый булса кирәк. Бу хакта аның күз карашы, бөтен вөҗүде сөйли шикелле.

Баланың авыртудан бигрәк, гарьлектән елаганы бөтен кешегә дә аңлашыла иде. Чөнки ул гади елау белән еламый: арбада үз гәүдәсен үзе күтәреп ыргыта. Бармак башы кадәрле уенчык өченме мондый мәсхәрә? Дуслашырга теләгәне өченме?

Беләмен: тәкәбберлек – кара көчләрнең коралы. Күз алдымда кара көчләр белән бәрелештә малай беренче чирканчык алды.

Уйлардан арынырга тырышып, тәрәзәгә төбәлдем. Җиһан җәй хозурында тирбәлә. Шәһәрнең гөлбакчасы – ял паркы яныннан үтеп барабыз икән. Бөдрә таллар әйләнәсендә зәп-зәңгәр күл җәйрәп ята. Юан-юан имәннәр, күл буендагы таллардан көнләшкәндәй, сусап, боегып кына тирә-юньне күзәтәләр. Суның һәр тамчысы могҗиза шул. Тамчыдан җыела ул күлләр. Чишмәләр күп иде без үскәндә. Сулары татлы иде. Елгаларга ашыктылар алар. Елгалар – диңгезләргә. Тик чал диңгезнең суы тозлырак нигәдер...

Кәрим дә нәни диңгез тамчысыдай тынгысызланды, әнисенең кулларын этте. Югыйсә баласы өчен күбрәк әнкәсе әрнеде кебек. Ир бала өчен аналар икеләтә борчылучан була. Йөзен кызыл тимгелләр басты әнә. Килешле кысык күзләре ачылып, вак карлыганны хәтерләткән күз алмалары эреләнеп киткәндәй тоелды. Көтелмәгән хисләр авырлыгына чыдый алмыйча, күз аллары томаланып алдымы, баскан урынында чайкалып куйды. Беренче чәч бөртекләре, мөгаен, шул мәлдә агаргандыр... Автобуска никләр утырганына да үкенгәндер. Тик һәммәсен тешләре белән кысты шикелле. Бер генә сүзен дә йозак-биктән ычкындырмады. Җәннәткә дә иң беренче юмартлар һәм сабырлар керер, ди, бит... Алай гына да түгелдер... Җимешле агач иелә төшә шул...

Әлбәттә, автобустан төшкәч, әлеге вакыйгага карата үз фикерен баласына әйтер ул. Андый саранлык әйбәт түгел, дияр. Тәртипсез малай икәнен күрсәтте, алай сугыш чукмары булырга ярамый, дияр... Ә бәлки, яхшылык янәшәсендә яманлык дигәне дә яши. Җир шарының түгәллектә әйләнеше шушы ике төшенчәнең дә тигезлегеннән гыйбарәт. Явызлык һәрчак җиңәргә тели, үлчәү тәлинкәсен тизрәк басып төшерәсе килә, тик яхшылык аңарга ирек бирми.

Нарасыйның әле бу беренче дәресеседер. Ана үзе тормыш сабакларын шактый үзләштергән булса да, баласының хәзер үк мондый сынауга тарыйсын башына да китермәгәндер. Ашыгуым аркасында барысы да, дип, үз-үзен битәрләгәндәй тоелды миңа ул.



Рәсем: Наталья Васильева

Әйе, ашыгабыз шул без... Берәүләребез игелек орлыгы салып өлгерик, дибез. Икенчеләребез намус, әдәп, тугрылык орлыгы сибә. Кемдер ни эләксә, шуны чәчә. Оятсызлык, тәкәбберлек, гаделсезлек... Орлыклар күптөрле. Нәтиҗәләр дә. Нәтиҗәләр турында уйланырга вакытыбыз гына юк. Ашыгабыз... һәм соңга калабыз. Бу яшь әни дә тизрәк барып җитим, дигәндер.

«Нәни разбойник»ның исе дә китмәде әнә, куе зәңгәр башлыгын йолкып алып итәгендәге машинасы өстенә ыргытты да тынычланды.

«Йа, Ходаем, каның да зәңгәр мәллә соң синең, балакаем? Кем өйрәтә сине шулай мәрхәмәтсезлеккә?» дип пышылдады төсле уң яктагы фәрештәм.

«Тәкәбберлек бары тик явызлыкны гына тудыра ала. Башта нәни явызлык була, аннан ул зур явызлыкка әверелә», диде сыман сул яктагысы. Мин килештем. Нәни явызлык зур явызлыкка әверелгән мәлләрдә кабынгандыр ул илләр белән илләр арасында сугыш уты. Шул ут һәлак иткән ласа халыкларны.

Тәкәбберлек янәшәсендә мондый хәлгә юлыгуың көн кебек ачык инде.

Нарасыйның елавына чыдый алмыйча, әнисенә эндәштем:

– Баланы кулыгызга алыгыз да, минем урынга утырыгыз. Юлга каратып кайтыгыз, әйдә. Тынычлансын әзрәк, – дидем.

Төшәргә дә вакыт җитеп килә иде инде. Әнисе тыңлады. Бала да, юлдагы машиналарга карап, онытылып китеп елавыннан туктады. Башын әнисенең күкрәгенә салып, тынып калды.

Тышта йомшак, җылы нурларын җир өстенә сибәсибә кояш көлә. Автобус сикертеп куйган саен ул нурлар салмак тирбәлешеп ала. Әйтерсең, аларны да бишеккә салганнар. Әйтерсең, аларны Кояш белән Җир-әнкә шушылай иркәли, шушылай үсендерә. Күкләр астында нурларның да үз урыны бар шул. Аларга да яктылык, ямь тарату вазыйфасы йөкләнгән. Ә кешеләргә? Автобус эченә күз салдым. Кешеләр битараф күренә, һәммәсе үз уена чумган. Теге «башкисәр»нең дә уенчыгы алдында таралып ята. Үзе оеп, йокымсырап китәр төсле. Әнкәсе башын тагын да югарырак чөйгән сыман. Каргадан карчыга тумый, диләр... Халыкның шушы әйтеме минем баштан сызылып үткәндәй булды.

Автобус тынлыкка батты. Төшкәнче уйланып бардым. Рәнҗетелгән баланы яклап берәү дә сүз әйтмәде бит. Яхшылыкны яклаумы соң бу? Хәзерге яшьләрдән шүрлиләрме кешеләр? Әллә явызлыктан куркалармы? Әллә битарафлык шулай телсез, күзсез итәме аларны? Миңа хәтта куркыныч булып китте. Безне кеше кешегә дус һәм туган дип тәрбияләгәннәр иде ләбаса. Без дуслардан кыенлык күргәндә дә еламаска тырыштык шуңа. Тик ни сәбәпле үзебез теләгән җәмгыятьне төзи алмадык икән соң? Хәер, болар барысы да безнең үткәнебез инде. Ә киләчәк менә шушы балалар кулында.

– Әннә-нә-нә! – Бала җиңел гәүдәсен турайтып, зәп-зәңгәр күктә әкертен генә йөзеп барган өрфия болытка бармагы белән төртеп күрсәткәндәй итте дә кинәт балкып көлеп җибәрде. Тәрәзәдән кергән нурлар тагын да яктыра төште сыман. Ул арада автобус тукталышка килеп җитте, ишекләр ачылып китте.

– Әннә-нә-нә, – дип такмаклады Кәрим, әнисенең дә игътибарын таләп итеп.

«Тәкәбберлектән явызлык туа», дип пышылдады кебек сул як фәрештәм.

«Мәрхәмәт яши! Ә дөньяны мәрхәмәт яшәтә!» дип кушылды гүя уң яктагысы.

– Дөнья барыбер матур! – дип пышылдадым мин.

PRESSA.RU



БЕЗ КҮП! БЕЗ ТӨРЛЕ!

Бадияннар салдым батмаска,
Сөлге салдым акмаска.
Бу бирнәне без тутырдык,
Кире әйләнеп кайтмаска.

Апа-җиңгиләре, дус кызлары – ахирәтләре Сылубикә исемле кызның бирнә сандыгын тутыра. Кәләшнең үзе чиккән ашъяулыгы, тәрәзә кашагалары, киявенә дип әзерләгән күлмәк, аяк чолгавы... Яшь киленнән «Сабантуй батырына» дигән чиккән сөлге! Һәркайсының телендә бер теләк: «Сылубикә барган җирендә аш булсын да таш булсын»... («Зиләйлүк» фольклор коллективы, Саба районы).

...Бу йортта да туй! Туган-тумача кызны кияү йортына озатырга җыелган. Кәләшне киендерәләр: чәчләрен үрәләр, бизәндерәләр. Дуслары белән килгән кияү кулына кызны әнисе тапшыра. («Зоренька» вокаль ансамбле, Биектау районы).

...Ә күршеләрдә бәби туган! Яшь әти белән әнинең, әби-бабайның шатлыгын уртаклашырга тирә-күрше, туганнар килгән. Аларда – «тоонтонюулга»: ана баладан котылганнан соң соңгылыкны һәм кендек бавын җиргә күмү йоласы. Соңгылык күмелгән урын һәр бурят өчен бик мөһим: ул аның кече Ватаны санала, тәненә көч, җанына тынычлык бирә. Кайда гына яшәсә дә, бурят елга бер тапкыр туган ягына кайтып килергә тиеш. (Бурятларның Казандагы милли-мәдәни автономиясе.)

...Бу нигездә дә бәйрәм! Йортка яшь килен килгән. «Ә бу сезнең яңа хуҗабикәгез! Тыңлагыз аны!» – дип, кайнана ишегалдындагы мал-туарны килене белән таныштыра: терлек-туарны аның кулына тапшыра. Сыер мөгезен хәтерләткән баш киемен мукшы кызлары гомерләрендә бер тапкыр бары тик шушы көнне – «Бозау чукындыру» йоласы үткәндә генә кигәннәр.









Фото: Ксения Богданова


(Мордва милли-мәдәни автономиясенең «Кудоатя» арт-группасы).

«Ак барс» яшьләр үзәге сәхнәсендә Халыкара «Мәдәниятләр меңьеллыгы» милли-гореф гадәтләр фестивале бара. Татарларны – руслар, аларны исә керәшеннәр, яһүдләр, бурятлар, чуашлар, удмуртлар, мордвалар, әзәрбайҗаннар, индуслар, вьетнамнар, әфганнар алыштыра. Һәр халыкның үз йоласы, алар бер-берсенә охшаган да, шул ук вакытта аерыла да: «Хна йахты» («кына кичәсе» – әзәрбайҗаннарда туйга берничә көн кала кыз ягында үтә торган йола), «Питрау көн», «Нуны сюан» (удмуртларның бәби туе), «Хер йери» (чуашларда туй алдыннан «кыз елату» йоласы)...

Фестивальгә узган ел нигез салынды. Аның барлыкка килүе гаҗәп түгел – Казанда 115 тән артык милләт кешесе яши. Дуслыкта һәм татулыкта! Милли гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен саклау һәм үстерү өчен аларның барысына да бердәй шартлар тудырылган. «Мәдәниятләр меңьеллыгы» фестивале исә безнең күпмилләтле республикада яшәүче халыкларның гореф-гадәтләре, йолалары, милли үзенчәлекләре белән берьюлы танышу мөмкинлеге тудырды. Фестивальне оештыручылар – Казан мэриясе, Татарстан халыклары ассамблеясе, ТР Мәдәният министрлыгының традицион мәдәниятне үстерү Республика үзәге шушыларны күз алдында тоткан да. Фестивальне ачып җибәрү өчен сәхнәгә күтәрелгән кунаклар – Казан шәһәренең муниципаль берәмлекләр башлыгы урынбасары – Казан шәһәр думасы рәисе урынбасары Евгения Лодвигова, Татарстан халыкларының «Дуслык» йорты директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ирек Шәрипов та нәкъ шул сүзләрне кабатладылар: «Без бүген республикада яшәүче халыкларның гореф-гадәтләре белән танышабыз. Мондый чаралар безне тагын да якынайта. Бу халыкларның күбесе аңлы рәвештә Татарстанны инде күптән икенче Ватан итеп сайлады», – диделәр.

Быел тамашачы барлыгы 13 төрле йола белән танышты. Ә фестивальдә катнашырга теләк белдереп, 80 нән артык гариза кергән: иң-иңнәре генә сайлап алынган. Фестиваль узган «Ак барс» Яшьләр үзәге фойесында кул эшләре осталарының күргәзмә-ярминкәсе дә эшләде.

PRESSA.RU



СЕЗ ДАВЫЛЛАП КИЛГӘН ЯҢГЫР АЛДЫННАН БУЛА ТОРГАН ХАЛӘТНЕ ХӘТЕРЛИСЕЗМЕ?.. КӨЧЛЕ ҖИЛ КУБА, ЯҢГЫР ИСЕ... МЕНӘ СИНЕ ДӘ БУ ЗИЛЗИЛӘ БЕР ЯФРАК СЫМАН КҮТӘРЕР ДӘ, ӨЕРМӘСЕНДӘ БӨТЕРЕП, ӘЛЛӘ КАЙЛАРГА АЛЫП КИТӘР СЫМАН...



Лариса
МАЛИКОВА

САГЫНУГА ДӘВА ЮК ИКӘН...

Минем бу гаиләгә килеп керүем дә нәкъ шул давыллы хисләргә тиң. ЗӨЛФӘТ... Дөресен генә әйткәндә, мәктәбебездә татар теле юк дәрәҗәсендә иде, шуңа күрә татар әдәбиятын яхшы беләм дип мактана алмый идем мин. Өйдә гел татарча гына сөйләшсәк тә, балалар бакчасына йөри башлагач, башка телдә уйларга, аралашырга куштылар. Мәктәптә дә барлык фәннәр русча укытылды. Мин, математиканы яраткан кыз, Казан университетының ВМК факультетына укырга кердем. Минем кебек математикага гашыйк бер егет КАИда укый икән... Дусларыбыз мине Азамат белән таныштырганда: «Аның әтисе «Чаян»да эшли», – дип кенә әйтеп үттеләр. Ә үз әнием белән әтием, бу исемне ишетүгә, бераз аптырабрак калды кебек. Ләкин мин аларны тынычландырырга ашыктым: «Бер дә курыкмагыз, алар искиткеч, алар гаҗәеп туган җанлы, дуслары өчен үлеп торалар». Булачак кайнанам Фирая... Анысы башкаларга игелек кылудан бушамый. Үзе чибәр, үзе ачык... Булачак кайнатам Зөлфәт... Шаян да, гади дә, бала-чага кебек беркатлы да... Тагын әллә нинди матур сыйфатларга төреп күрсәтәсем килә аны! Миңа «килен-балакай» дип дәшә иде. Бу җылы сүз әле дә колагымда яңгырый кебек... Килен булып төшкәч, үзем өчен ЗӨЛФӘТ дигән дөньяны ача башладым.



■ Гаиләдә иң күңелле мизгелләрнең берсе. Кем җиңәр: әтиме, безме?

Башта шигырьләре

Азамат мине гаиләсе белән таныштырган көннәрдә әтинең «Ике урман арасы» китабы әзерләнеп ята иде. Мин дә үз ярдәмемне тәкъдим иттем. Ике дә уйламыйча (машинкада баса беләмме, юкмы? Мондый эштә тәҗрибәм бармы – сорап та тормадылар!), кәлтәсе белән шигырьләр тоттырдылар. Ә минем өчен бу Зөлфәт шигърияте белән генә түгел, язу машинкасы белән дә тәүге танышуым иде. Шул вакытта аның шигырьләрендәге образлар, көтелмәгән чагыштырулар, моңарчы үзем бер тапкыр да ишетмәгән аһәңле сүзләр, ут, өермә, кайнарлык җаныма мең пыяла кыйпылчыгы сыман кадалдылар. Аның шигырьләрен яңадан укыганда шул вак пыяла кыйпылчыклары төрле төсләр белән уйнап, мозаикадагы кебек бүген дә әйләнә, бөтерелә... Мине әдәбият, шигърият, язучылар, сәнгать дөньясы үзенә тарта башлады. Йотлыгып татарча шигырьләр укыйм, эти-әниләргә килгәч, иҗат кешеләре белән аралашам. Читтән торып редакция тормышында кайныйм. Миңа кызык, миңа ошый ул дөнья! Һәм көннәрдән бер көнне (фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килгәндер!) «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза ханым Туфитуллова мине редакциягә эшкә чакырды! Журнал беренчеләрдән булып компьютерга күчеп маташа, һәм нәкъ мин булдыра ала торган эшләр икән анда!

Зөлфәт-әти

Гаиләдә өч малай һәм бер кыз үскән: Азамат, Илһам, Фазыл һәм кадерле Кадрияләре. Язучылар дөньясында бер шаяру яши: имеш, Зөлфәт – Фираяның бишенче баласы. Юк, килешмим!.. Бу гаиләдә «әти сүзе» дигән төшенчә бар иде. Һәм ул сүз, балалар үсеп, инде аларның гаиләләре булгач та, көчен югалтмады. Хәтеремдә: ул сүз бик тыныч һәм бер генә әйтелә иде. Аннан соң инде бернинди дә бәхәскә, сүз куертуга урын калмый...

Зөлфәт-әтинең бик күп кызык яклары булган. Мәсәлән, командировкага кая гына барса да, ул шул ил телендәге балалар китабы алып кайта торган булган һәм, әлбәттә, шул телдә дистәләгән сүз дә ияртеп кайткан. Китап киштәләрендә чех, поляк, Балтыйк буе илләре телләрендәге ул алып кайткан китаплар, сүзлекләр һаман да саклана әле.

Тагын бер мөһим нәрсәне әйтеп китмичә булдыра алмыйм – бу гаиләдә балалар кул арасына иртә кергәннәр, эш рәтен белеп үскәннәр. Өч ир малай, нинди генә эшкә тотынса да, коеп куя: өйдә ремонт ясау, электр, сантехника эшләре... Алар бит әтиләренең эшләгәнен күреп үскән, аңардан өйрәнгәннәр!

...Бар дөньямны минем җылыттың,
Бу ярсулы дөнья уртасында
Ярый әле сиңа юлыктым...

Зөлфәт-бабай

Бүген Зөлфәтнең бабай исеме белән горурланып яшәүче тугыз оныгы бар. Алар арасында иң зур бәхет – әти белән иң күп аралашу – безнең олы кызыбыз Камиләгә елмайды.

...Беренче онык. Әти белән әнинең әле бик яшь чагы – Фирая-әнинең дәү әни буласы килми генә бит (мин аны бүген бик яхшы аңлыйм!). Баланы диванга утыртып куеп, аның алдына тезләнеп: «Мин дәү әни

PRESSA.RU



Зөлфәт-бабай оныклар арасында. Ул мәңгелеккә күчкәч, оныклар инде тагын икегә артты.

«Абыкай!» – диеп эндәште сеңел, Куе болытлар китте таралып...

түгел, мин – әника», – дип әйтүләре һаман да күз алдымда. Һәм ул бүгенгәчә «әника» булып калды да! Ә Зөлфәт-әтиебез, киресенчә: «Юк, мин – бабай!» – дип сөенеп һәм горурланып әйтте! Зөлфәт-бабай... Ул оныкларын бик яратты. Оныклары белән бергәләп бер кызык уен уйнаганы әле дә исемдә, һәм ул уенның ни дәрәҗәдә балалар өчен файдалы булганын вакыт узгач кына аңлый башладым. Уенның сере – ни күрсәң, шул әйбер турында әкият уйлап чыгарырга кирәк. Зөлфәтнең күзләре яна, чөнки аңа балалар фантазиясе, аларның тузга язмаган әйберләр уйлап чыгаруы ошый. Балалар да шат – бабалары бит әнә әле алар ишетмәгән бер генә сүз өсти: әкият тагын да мавыгулырак, кызыклырак булып китә. Җыйнаулашып бөтенләй яңа, сихри дөньяда яшәп алалар.

Камиләнең скрипкада уйный башлаган чоры. Бер дә уйный белмәгән кешенең скрипка кыллларыннан нинди тавышлар чыгаруын күз алдына китерүе авыр түгел. Бу хәлгә бары тик әни кеше генә түзә ала һәм... Зөлфәт түзде. Тәүге музыкаль «опусларның» ул иң беренче бәхетле тыңлаучысы иде. «Молодец, кызым! Өйрән, тырышасың!» – дигән сүзләре балага канат куйгандай була торган иде. Ә инде Камиләбезнең бабасының «Яфрак төшкән юлга...»ны скрипкада уйнавын ишетеп сөенгәне!..

Зөлфәт оныкларының чит телләр өйрәнүен дә гел хуплады. Камиләгә дә: «Телләр өйрән, кызым», – дип әйтә иде. Бабасының сүзләрен васыять кебек кабул итеп, Камилә – инглиз мәктәбен, аннары КФУның шәрык телләре факультетын кызыл дипломга тәмамлады. Мактанып әйтүем түгел, бабасының (исән булмаса да) сүзе ни дәрәҗәдә үтемле булуы турында искә төшерүем генә...

Күзәтүләрем

Шагыйрьгә илһам иңгән. Бүлмә ишеге ябык. Бөтен кеше аяк очында гына йөри, бармакны сак кына авыз тирәсенә куеп: «Тссс... Яза», – дип пышылдашабыз. Төн җитте. Өй эчендә шылт иткән тавыш та юк. Гаҗәп: хәтта сәгать тә туктап калган сыман. «Фирая, каләм!..» Бераздан: «Фирая, ручка!..» Сәгать төнге өч тә, иртәнге биш тә булырга мөмкин, тагын Зөлфәт тавышы: «Фирая, тыңла!..» Ә иң гаҗәпләндергәне – төне буе керфек какмый язганнан соң, иртән җыенып эшкә чыгып китүе. Юк, дөрес түгел, эшкә чыгып китүе түгел, редакциядә көне буена җимертеп эшләп кайтуы. «Чаян»ның ул еллардагы баш мөхәррире Рәшит Зәкиев әйтмешли, «Чаян» 30 ел Зөлфәтчә «сөйләде».

Ә кичләрен инде «Әкият» курчак театрының баш режиссеры Илдус Зиннуров килеп керә. Минем өчен ул вакыттагы иң кызык күренеш – кәгазьләрен өстәлгә түгел, урындык өстенә куеп, аларның яңа пьеса иҗат итүләре.

Менә йөгереп кенә безгә яшь актер Илдус Габдрахманов килеп керә... Камал театрында Фәрит Бикчәнтәев әти тәрҗемәсендә Лопе де Веганың «Биючә»сен куя. Аның да үз тарихы бар. Пьесаны заманында режиссер Рифкать Бикчәнтәев куярга кызыккан була, әмма өлгерми кала. Зөлфәткә Фәрит яңадан мөрәҗәгать итә һәм этисенең хыялын тормышка ашыра... Хәзер уйлап карыйм да бер нәрсәне ачык аңлыйм – Зөлфәт яшәмәде, ул янды... Ялкынланып, илһамланып, бөтен барлыгы белән эшкә, иҗатка күмелеп...

Ялгышуларым

Миңа әти белән бер бинада, хәтта бер катта, күрше генә редакцияләрдә эшләргә насыйп булды. Сагынам ул елларны. Тугызынчы катыбыз гөрләп тора иде. Йә «Һаман яратам», «Кичер!», «Ашкын, кешем!» җырлары яңгырый (әтинең бүлмәсендә радио бар – яраткан җырлары тапшырылса, ул аның тавышын көчәйтебрәк куя), йә «Сагынуга дәва юк икән» җыры җаннарны актара: «Бүләр болыннары, Сәет урманнары...» бөтен коридорга яңгырый да туган ягына – Мөслим тугайларына ук алып китә (ә менә минем Мөслимгә һаман кайта алганым юк әле, бик күрәсем килә Зөлфәтнең яшьлеген саклаган Бүләр, Сәетләрне!..), йә «О-о, дускай...» дип, әтинең дусларын каршылавы ишетелә... Тугызынчы кат гөр килә. Күңелле... Сер түгел: иҗатташ дуслар җыелган җирдә «кызганрак» чаклары да булгандыр. Баштарак бик уңайсызлана идем. Бер бүлмәдә утырган рәссам Светлана Ибраһимова минем кыенсынып, оялып утырганымны сизеп, сәбәбен белгәч, бер генә җөмлә әйтте, һәм ул җөмлә минем өчен дә, башкаларның имеш-мимешләренә дә җавап булырлык бик әйбәт аксиома булып калды: «Лариса, талант прощает все!»

Табышларым

Бу гаиләдә тормышка карашымны үзгәрткән берничә «гыйбарә»гә тап булдым. Шуларның берсе: бу тормышта, үлемнән кала, барысын да үзгәртеп була. Маликовлар гаиләсендә бу гыйбарә белән бәйле истәлекләр бик күп. Бергә җыелышкач, бик күңелле итеп сөйлиләр. Шуларның берсен искә төшереп үтим: әтинең дусты Мөдәррис Әгъләмгә дә дога булып барсын.

Мөдәрриснең әти белән әнинең «Яшь ленинчы» газетасында эшләгән чоры. Баш мөхәррирләре Роза

ханым Туфитуллова Мөдәррис Әгъләмовны Мәскәүгә командировкага җибәрмәкче. Мөдәрриснең абыйның ялгыз яшәгән чагы, аны Мәскәүгә әзерләп җибәрү Фираяга йөкләнә.

– Мөдәррис, мин сиңа булышырмын, әлбәттә, тик шимбә кил, яме. Якшәмбедә лагерьга балалар янына барасым бар, – дип үтенә Фирая.

Көтелгән шимбә үтеп китә. Ял көнне Фирая сумкаларын төяп ишек бусагасын атлап чыкканда, ялт итеп, Мөдәррис тә пәйда була. Һәм аны Мәскәүгә әзерләү миссиясе шулай итеп Зөлфәткә тапшырыла. Фирая-әни лагерьдан әйләнеп кайтканда, «Татарстан» поездының кузгалып китәренә нибары ике-өч сәгать вакыт калып бара... Лоджияда Мөдәррис белән Зөлфәт сыра эчеп, бәхәс куертып утыра, бауда Мөдәррис абыйның күлмәкләре кибә, ә кер юу машинасында пиджагы әле әйләнеп кенә ята...

Бу урында үземне күз алдыма китерәм. Мин ни эшләр идем? Чарасызлыктан паника яки истерика башланыр иде: «Бу ирләргә эш кушарга ярыймы соң?!» Ә Фирая белән Зөлфәт очрагында куркыныч берни дә булмаган – өйдә кием бетмәгән бит!.. Кайдан нәрсә табып, Мөдәррис абыйны киендереп, юлына азык-төлек тутырып, Мәскәүгә озаталар.

Зөлфәт-абыкай

Сигез балалы гаиләдә үскән Зөлфәт туганнары өчен олы абый була белде. Үзләренчә яратып, «абыкай» дип йөртәләр иде аны. Әти үзе дә туганнарының һәр борчу-мәшәкатен җаны аша уздырып, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша иде. Хәер, абыкайлары белән җиңгәчәйләрендә аларны һәрвакыт якты йөз, тәмле сүз, кайнар аш белән каршы алуларын бөтен туганнары да белә иде, әлбәттә...

Ә хәзер бу гаиләнең иң четерекле чорына күчәсем килә. Әти арабыздан китте... Йөрәктә бер зур әрнү калды, һәм бер сүз һаман баш миен бораулый: «Өлгермәдек, өлгермәдек, өлгермәдек...» Тиешле кадер-хөрмәт күрсәтергә өлгермәдек... Үзе белән тагын да күбрәк аралашырга, үсеп килүче балаларыбыз белән туйганчы аралаштырырга өлгермәдек... Хәтта бергә фотога төшәргә дә...



■ Нәкъ Маликовларча! Истәлеккә – үзләре яшәгән тугыз катлы йорт түбәсендә. Казакъстаннан кунакка кайткан Халисә сеңлесенең гаиләсе белән.

Әти үлгәч, әни – шашар дәрәҗәдә... Бер ел узды – һаман шул ук халәт. Ел ярым... Ничек кенә тынычландырсак та, булышырга теләсәк тә, барысы да комга сипкән су кебек сеңеп бара... Язмыш гомер көзләренә кереп баручы ике ялгыз кешене очраштырмаса, бу хәл күпме дәвам итәр иде – билгесез. Һәм без – балалар – язмышка бик рәхмәтле. Фирая-әнинең бу адымын аңламаучылар да байтак булды, ә без, аның якыннары, бүгенге көндә әнинең Шаһинур абый (эзтабар-язучы Ш. Мостафин) белән бергә булуына сөенәбез генә.

Казакъстаннан – Халисә, Мөслимнән Назилә сеңелләре, Казанда яшәүче энеләре Галләм, Ханнан, Ренал, җыелышып, абыкайлары янына барып зиярәт кылдылар. Кайтышлый, Шаһинур абый белән әни аларны үзләренә кунакка алды. Табын әзер... Кунаклар да килеп җитте... Ләкин өйгә кермичә, аста – подъезд төбендә басып торалар. Авыр аларга... Шул мәлдә ничек борчылганыбызны белсәгез икән... Киләбез дә тәрәзәгә капланабыз... Рәхмәт, әни тормышындагы бу яңалыкны кабул итүләрен күрсәтеп, бусагадан атлап керделәр. Һәм бу өйдә чынлап та Зөлфәт рухы яшәвен күреп (китап киштәләрендәге – абыкайларының фотолары, өстәвенә, шигырьләре яңгырап тора), алар канәгать һәм риза булып киттеләр...

Узар гомерләр
искән җил кебек,
Сөю – мәңгелек,
сөю – мәңгелек!..

* * *

...Беркөнне редакциябездә телефон шалтырады. Саимә апа Ибраһимова (әти-әни белән «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә озак еллар бергә эшләгән язучы, тәрҗемәче) икән. Мин трубканы алуга, сөенеп:

– Лариса, нәкъ син кирәк идең миңа. Әле генә радиодан «Һаман яратам» җырын тапшырдылар. Мин елыйм... Фирая бит...

Сүзнең кай якка борылганын чамалап, аңлатырга ашыгам:

– Саимә апа, Шаһинур абый белән әни бер-берсенә терәк булыр өчен бергә алар. Ул өйдә дүрт кеше яши – Шаһинур абыйның мәрхүмә хатыны Дамирә апа белән Зөлфәт-әти дә шунда... Аларның фотолары – өйләре түрендә, икесен дә сагынып һаман искә алулар...

– Булды-булды, Лариса... Аңладым. Мин тагын елыйм...

P. S. Шулай итеп, күңелем түрендә булган Зөлфәт-әти белән бәйле тормыш мизгелләрен сөйләвемнең максаты – бөек шагыйрь Зөлфәтне кеше, әти, бабай, абый буларак ачу иде. Мин бушанып калдым. Күңелдә – көчле яңгырдан соң була торган сафлык, рәхәт тынлык...

PRESSA.RU



КЫШКЫ РОМАНС

БОЛДЫРГА ЧЫГЫП БАСКАН АЛИМӘ АҺ ИТТЕ. БУЛСА ДА БУЛЫР ИКӘН ГҮЗӘЛЛЕК! АЛМА БАКЧАСЫ МАЙ АЕНДА ДА БУ ТИКЛЕМ СОКЛАНГЫЧ БУЛМЫЙ ТОРГАНДЫР.

Асия
ЮНЫСОВА

Тәлгәш-тәлгәш кар алкалар саф көмеш сыман аклык белән кышның тансык нурында иркәләнә. Төне буе явып туктаган кар ап-ак мамык юрган хасил иткән дә, ымсындырып, чум әйдә, дигәндәй, кызыктырып, күпереп ята. Әгәренки оҗмахның кышы була торган булса, ул нәкъ менә шушы кышкы бакча рәвешендәдер. Һай, элек тә була торган иде андый оҗмахый кыш мизгелләре. Була торган иде, була торган иде...

Алимә яшьләрчә җитез адымнар белән болдыр басмаларыннан йөгереп төште дә әнә шул яшьлектәге кыштан хәтергә уелып калган сүзләрне бияләйле кул аркасы белән йомшак карга язып куйды: СИН МИНЕМ ТАБЫШЛАРЫМ! Аннары капкадан чыгып, үзен көтеп торган «Субару» эченә кереп чумды. Кышның бу көне ничек кенә ямьле булмасын, Алимәнең нечкәреп торырга, хыялга бирелергә вакыты юк. Ел ахыры, отчетлар тапшырасы, хезмәткәрләргә премияләр язасы, балаларына Кыш бабай күчтәнәчләре хәстәрлисе бар. Үз оныклары да итәк тулы – аларга да бәйрәм ясыйсы...

Эшенә барып утырып, инде күнегелгән мең мәшәкатенә чумгач та теге – ишекне ачып чыгуга үзен бөтереп алган «Кышкы романс»ның алгысыткыч көе, моңы җибәрмәде аны. Үзе дә сизмәстән әкрен генә җырлый да җибәрә: «Син минем сагышларым...» Нидән бу, нилектән? Нидән булсын инде – әкияти кышкы манзарадан! Шул уята хәтер күзәнәкләрен! Шул бимазалый ашкын хисле күңелне! Ашкын хисләр, имеш. Һе, әллә безне сөймәгәннәр, дисезме, диме әле шагыйрь? Әллә без үзебез сөймәгәнме! Ә бу романс нәкъ менә шул хакта – сөюләр, табулар, югалтулар хакында. Кайсы алдан йөри – табуымы, югалтуымы? Әллә башта югалтуы, аннан табуымы?

Эш белән мавыгып төш җиткән ләбаса. Җиңелчә ризык китертеп, тамак ялгап алырга булды Алимә. Гадәтенчә, радионы кушып җибәрде. Бу ниткән көн булды соң, ниткән могҗизалы көн?! Радио дулкыннары да бүлмәгә Фидан Гафаров тавышы белән килеп керде: «Син минем сагышларым...» Бу ниткән мистика! Тәки Алимәне үткәндә калган кышларга кайтармакчы бит бу моң. Кайсысына микән? Әйдә, бу җырны икәү бергә сәхнәдән җырлаган кышка кайтсын әле ул.

Баланлыга педпрактикага кайткан иде Алимә. Баланлы авылын үзе сайлады. Чөнки җәй көне, яшь җиңгәсе авылларына Сабантуйга чакыргач, абыйсына ияреп кайтканы бар иде инде ул бу авылга. Сабантуйда башта түгәрәк уртасында гармун уйнап кызларны биеткән, аннары мәйданга чыгып көрәшкән егетне күреп, күреп кенә түгел, тәмам күз салып киткән иде кыз. Шул чагында абыйсына әйтте дә әле ул: «Менә, абый, күр дә тор, мин шушы егеткә кияүгә чыгам!» Абыйсы елмаеп кына куйды: «И-и, сеңлем, мондый егетләргә кызыгучылар күп булыр. Адарынма. Анысы, син дигәнеңне эшләми калмыйсың инде. Тик шулай да, ни бит, сеңлем, үз тиңеңне чамаларга кирәк». Абыйсының бу сүзләренә Алимә үпкәләп тормады.

Декабрь башында мәктәпкә кайтып та төште. Практика дигәч тә, аңа читтән торып укып йөрүчеләрнең сәгатьләрен өеп бирделәр. Тарих, география, җыр – өлгер генә. Яшь кеше тарта ул дигәндәй, Яңа елның Чыршы бәйрәмен үткәрү дә Алимәгә йөкләнде. Әйләнбәйләне генә җитмәгән, зурлар өчен бал-маскарад, концерт дигән өлеше дә. Көн-төн репетицияләр. Ә теге гармунчы-көрәшче егет шул мәктәпнең физика укытучысы булып чыкты. Хәер, Алимә аның шулай икәнен белеп килде ләбаса бу мәктәпкә. Разведка эшләде. Ягъни егет йөрәгенә илтә торган иң кыска, иң туры юлны сайлады тәвәккәл кыз. Сәхнәдән менә шушы – бүген эзәрлекләгән «Кышкы романс»ны җырлаган көне Алимәне Ибраһимның йөрәк патшасына әйләндерде дә куйды. Менә бит җырның кодрәте. Әйе, гармунчы-физик Ибраһим исемле иде. Ул Алимәнең үзен «аулаганын» сизмәстән, кызга үлеп гашыйк булып куйды. Икесенең дә тәүге мәхәббәтләре иде бу. Электә булган шаярулар, яратам бугай, дип уйланылган кыз-егетләр, бер дә булмагандай, онытылды да куйды. «Акты тулып, акты ташып кар сулары. Шулдыр инде язның шашып ярсулары...»

Репетицияләрдән соң, авылның ак карын шыгырдатып, янәшә атлап кайтулар чаңгы юлларында янәшә эзләр салулар белән чиратлашты.

Уку елы тәмамлануга алар Казанга киттеләр. Яшь гаилә булып. Китәр өчен сәбәп чыкты. Алимәне Комсомолның өлкә комитетына инструктор итеп алдылар, Ибраһим да кала алмый иде. Кем әйтмешли, тукмагың кайда, сукмагың шунда! Мең мәшәкатьле комсомол эшенә яшь балалы гаилә ыгы-зыгысы өстәлде. Ничек тә булса тораклы – үз почмаклы буласы килү теләге дә йөгертә иде яшьләрне. Тик торганга – шымытыр, диләрме әле. Бер эшне дә ярты-йорты эшли белмәгән Алимә тиен кебек бөтерелде. Әҗере дә озак көттермәде. Фатирлы булып куйдылар. Хәер, Ибраһим да гаилә камытын тырышып сөйри. Аның эше хәзер командировкалар белән бәйле. «Терминал» заводына тәэминатчы булып урнашкан иде ул. Тәэминат эше бүренеке кебек, аны да аяклары туйдыра. Шуңа күрә атналык командировкалар гадәти хәл итеп кабул ителә иде.

Бервакыт комсомоллар Аккош күленә чаңгылы сәфәргә чыктылар. Алимә, кышкы урманга хозурланып, кызылтүшләр уенына сокланып бара торгач, урман түренәрәк кереп киткән. Хәер, берьялгызы түгел икән әле. Әнә, алдарак бер пар назлашып бара. Кызы таеп егылгач, егете аны торгызып, өстен каккалады, иелеп битеннән үбеп алды. Алимә шуып барган җиреннән шып туктап калды. Егетнең өстендә Алимәнеке төсле чаңгы киеме иде. Ибраһим белән икесенә бер иштән итеп, Ригадан алып кайткан иде ул шундый костюмны. Булмас! Ибраһим Дубнага командировкага киткән иде бит әле. Бер атнага. Атнасы ике көннән генә тәгәлләнә.

Тик бу кеше чыннан да Ибраһим иде. Алимә аны мең, юк, миллион кеше арасыннан да танып алыр иде. Ул бу, ул! Ә теге хатын-кыз кәмәше кем, алайса? Нигә Ибраһим аны үбә?

Тегеләр борылып каршыга шуып килә башлады. Алимә аларга юл биреп читкә тайпылмады, хатын-кызның йөзенә бәреп кенә күз ташлады да выжлап

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

узып китте. Ибраһим ягына күз ташлап та тормады. Нигә?

Хатынны таныды Алимә. «Терминал» заводы ашханәсендә цех башлыгы булып эшләүче Зинира – Зиночка иде. Битләре уймакланып, күзләре ялкынланып торган чибәр дә, дәртле дә хатын. Бервакыт алар катнашкан банкетка хезмәт күрсәткән иде ул. Шуннан хәтерләп калынган. Ул чагында аның Ибраһимга елмаюлары этикет кына дип кабул ителгән иде. Алай гына булмаган икән шул. Әле менә чаңгы юлында да Алимәгә бик җылы елмаеп калды. Акыллы елан!

Соңлап кайткан хатынын Ибраһим гаепле кыяфәт белән каршы алды. Ул бүген командировкадан «кайткан» иде. Хәтта шулпа да куеп җибәргән. Балаларның өй эшләрен дә карашкан. Менә ич ул – гаиләдән беркая да китмәгән! Тәмләп кенә кичке ашны ашагач, Алимә иренә урын җәйде. Ибраһимны мактап та алды: «Акыллы кеше инде син, багалмам. Зәвыгың да бик әйбәт икән. Бик чибәр хатын тапкансың». Шуннан бүтән сүз куертып тормады. Әмма аның йөрәгенә кар суыгы төшкән иде. Кайчан гына җылыныр ул. Ярсыйсы да, җылыйсы да килми иде аның. Арыды ул, арыды, рухы сынды. Бетмәс-төкәнмәс җәмгыять эше белән гаилә бәхете уртак фикергә килә алмый торгандыр шул. Үзе, бары үзе генә гаепле. Иренә игътибары, җылылыгы җитмәде. Инде менә бөтен, бәхетле дип уйланылган гаилә түгәрәге өзелеп бара. Тик аны ялгау, ямау хәстәре белән йөрергә Алимәнең вакыты юк. Йөген, вазыйфасын алга таба тартасы бар. Аның сынатырга хакы юк. Ә ирне тыеп, тиргәп, оялтып кына туры юлга күндереп була дигәнгә ышанмый ул. Ибраһимның үз акылы бар.

Ул – комсомоллар башлыгы, чарасыз калганда бер Ходайга аркалана торган иде.

Йөрәгендә боз суыгы тоеп яшәү алты елга сузылды. Ибраһим сабыр хатынының ызгыш-талаш чыгармасын аңлагач, беркадәр басыла төште кебек. Хатынына ягымлы, балаларга игътибарлы, кайгыртучан ир һәм ата булып кыланды.

Ул арада заманалар болгана башлады. Барысы өчен үзен җаваплы санаган Алимә гаилә иминлеген, балалар киләчәген уйлап, тәвәккәллек сорый торган гамәлләргә тотынды. Фирмалар ачты, киңәйде. Хәзер инде аның вакыты бөтенләй дә юк. Шулай әйбәт тә. Югалган бәхете өчен кайгырып утырса, үзенең дә югаласын белеп тора ул. Ә аңа югалырга, сынатырга ярамый. Көндәшләр, дошманнар көрәшеп яшәр өчен, яңа җиңүләр яулар өчен кирәк ул!

Бер көнне киңәшмә вакытында Алимәнең кәрәзле телефоны шалтырады:

– Ибраһим нигә телефонын алмый? – диде телефондагы хатын-кыз, боеручан тавыш белән. – Ул бүген миңа кучеп килергә тиеш иде. Әйт аңа, көтеп утырам.

– Ул өйдә калган иде. Телефонын нигә алмаганын әйтә алмыйм. Башка телефонга шалтыратып карагыз, – диде Алимә сабыр гына. Үзенең чәч төпләренә кадәр тир бәреп чыкты. Киңәшмәдә утыручылар берни сизенмәскә тиеш.

– Ибраһим синең ахмак, томана балаларыңны караганчы минем акыллы балаларымның әтисе булыр. Синең ише бозык хатын янында тилмереп яшәмәс. Син әле дә начальнигың астыннан җаваплашып ятасың. Эш урынында бит, оятсыз! – дип ярсыды Зинира телефонның теге очында.

Алимә, җыелыштан гафу үтенеп, коридорга чыкты да, ипле тавыш белән: «Син ярсыма әле. Ибраһим килер ул синең яныңа. Минем өчен дә борчылма. Сөяркәм мине кабинетларда яратмый, ул минем өчен аерым квартира тота», – дип, сөйләшүгә нокта куйды. Зинира зур хата җибәрде. Балаларга кагылды. Балаларын якларга дигәндә, Алимә – ана арыслан!

Өенә кайткач, Алимә бу юлы тыныч кала алмады, тик ярсымады да. Сүзне җайлап кына башлады: «Багалмам, кит син сөяркәң янына. Бергә яшәгез. Тик төнгә өйгә кайтып куна торган бул. Балалар әтиләрен күреп торсыннар. Әтисез бала бик боек була ул. Син бит үзең дә педагог булган кеше. Алар исәя төшкәч, бөтенләй китәрсең. Аннан сиңа тагын бер үтенечем бар. Ул хатыннан мине теләсә ничек яманлат, бер сүзем юк, тик балалар хакында начар сүз әйттермә. Ул синең улың белән кызыңны – синең белән минем мәхәббәттән туган балаларны ахмак дип атады. Ә бит кызың быел шахмат ярышында җиңеп кайтты. Улың да олимпиадаларда йөри. Безнең алар белән горурланыр көннәребез алда әле. Уйла син, уйла».

Ибраһим Зинирага китмәде. Гомумән, аның белән арасын өзде. Әмма хатынын үлеп көнли башлады. «Кемнәрдер фатир тотып ярата торган» хатын аның үзенә кирәк булды. Алимәнең дә багалмасының озак елларга сузылган гыйшыклык исереклеген фәкать дәвамлы чир зәхмәте итеп кенә кабул итәргә акылы җитте. «Акты ташып кар өстендә калган эзләр...»

Зинирага соңгы мораль һөҗүмне Алимәнең шоферы ясаган булып чыкты. Йомыш белән нәкъ шул хатын янына борыласын кем белгән бит. Җибәрмәгән дә булыр иде шоферын. Ә теге хатын, кем шоферы килгәнен белгәч, теленә салынган: «Ире һаман да шуның белән торамы? Тапкан инде бер адәм тәганәсен...» Шофер җавапны кыска тоткан: «Алимә Шакировнаның алабае булырга да риза булыр идем мин!»

...Ибраһимның хатынын тәрәзәдән карап озатып кала торган гадәте бар. Бу юлы да, чыршы тәпиләре белән сурәтләнгән тәрәзә бозын эретеп, урамга карады. Карады да әсәренеп калды. Ул тиз-тиз генә киенде, ишегалдына чыгып, Алимә язган язуга яңа сүзләр өстәде: СИН МИНЕМ САГЫШЛАРЫМ, СИН – ГОМЕР АГЫШЛАРЫМ!



МӨХӘММӘТОВА Рузилә

Казан дәүләт университеты

Бер кыз үстерә

Карьера: «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы

Тормыш шигаре: «Укырга, укырга һәм укырга!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Кызымның – үз юлы!


Социаль челтәрдәге битемдә кызым Сәлимә әйткән сүзләрне язып барырга яратам. Әйтик, «Мин синең яшеңдә...» – дип үзен үртәп торган танылган фотограф Рәмис Нәҗмиевкә ул: «Кырык бишкә җитеп, үзең нәрсәгә ирешә алдың соң? Мин бәлки ул яшеңдә дөнья белән идарә итәрмен инде», – дип җавап бирде... Аның берьюлы өч җирдә – музыка, сәнгать мәктәпләрендә һәм гимназиядә укуы белән горурланам. Фантастик китаплар, шигырьләр яза. Әмма... минем һөнәремне яратмый. «Беркайчан журналист та, матбугат үзәге җитәкчесе дә булмаячакмын», – ди. Булмасын! Үз юлын тапсын! Сәлимә архитектор булырга хыяллана. Шул хыялына омтыла.


Безнекеләр – җиңүчеләр арасында!


Быел «Яңа татар пьесасы» драматургия бәйгесендә «Татар-информ»ның ике хезмәткәре җиңеп чыкты! Аның берсе – дустым Айсылу Хафизова. Шактый киносценарийлар авторы, талантлы Айсылуның яңадан республикабыз өчен иҗат итә башлавы күпләр өчен сөенечтер. Заманча драматургия проблемасы күптән бар. Миңа калса, монда проблема драматургларның яза белмәвендә генә түгел, режиссерларның алар белән эшләргә теләмәвендә дә. Ике шәхес – режиссер белән драматург тандемы булмау. Бәлки быелгы авторлардан үзләренең «җандашларын» табар режиссерлар?

Заман белән бер адымда

Берничә гасыр элек нигез салынган Ватикан музейлары тарихында күрелмәгән хәл – директор итеп тиздән хатынкыз куелачак. Моның белән алар концепцияләренә язылган «музей – борынгы тузаннарны саклау урыны түгел» дигән сүзне тагын бер кат раслады. Барбара Яттага 54 яшь, ул Рим шәһәрендә туып-үскән. Ватикан комплексында 1996 елдан бирле эшли. Ватикан музейлары дөньяда иң күп каралган музейлар исемлегенә керә. Ел саен алар 5 миллионнан артык туристны кабул итә! Бу музейларда картина һәм скульптуралардан тыш корал, гобелен, мозаика, антик керамика һәм башкалар да тупланган. Иң зур байлыкларының берсе – Микеланджело картиналары.








сөендерде / көендерде

Күңелдә – икеләнүләр...

ТР Мәдәният министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе булып эшләгәннән соң, кабат журналистикага кайттым. Сөенәм, чөнки көн саен язам. (Яңарак кына Гүзәл Яхинадан интервью алдым. Теләсә нәрсә әйтсеннәр – ошады ул!) Көенәм дә: татар матбугатының укучысы көннән-көн азая, татар журналистына акча һаман да азрак түләнә. Мин журналистикага килгән чакта да җиңел түгел иде. Катлаулы туксанынчы еллар иде. Әмма ул чакта нәшрият бөек шәхесләр белән тулып тора иде. Шагыйрь Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиевлар белән исәнләшеп үтү дә бәхет иде. Ә хәзер... Белмим, үземне яңадан таба алырмынмы татар журналистикасында, әллә...

Кайберәүләрнең нәфесенә шаккатам...

Казанда рәссам Константин Коровин күргәзмәсе бара. Билет бәясе – 100 сум. Көзен бер банк үзенең юбилее хөрмәтенә сынлы сәнгать музейларына бушлай керү акциясен башлап җибәрде. Андый көннәрдә музей янында урам чатына кадәр чират тезелә иде. Халыкның чират торып матурлык күрергә ашкынуы яхшы, әлбәттә. Тик ул чиратта... бай кешеләр күбрәк булуын белгәч бик аптырадым. Затлы туннарын эләргә махсус элгеч сораганнар, машина куярга бушлай парковка таләп иткәннәр... Алар өчен йөз сум акчамыни?! Күргәзмәгә бушлай керү мөмкинлеген бер хезмәт хакын тартып-сузып яшәүчеләргә калдырсалар да була иде бит!


Урыннары җәннәттә булсын...

Яңа ел алдыннан гына Сүриягә очучы хәрби самолетның Кара диңгез өстенә төшүе һәм Александров исемендәге бөтен бер хәрби хорның юкка чыгуы коточкыч вакыйга булды... Һәлакәттән соң, шушы ансамбльдә эшләгән татар егете Евгений-Җәфәр Насыйбуллин турында, туганнары белән сөйләшеп, миңа мәкалә язарга туры килде. Җәфәр – Нижгар татары, тамырлары Сафаҗай авылыннан булган Мәскәү егете. Заманында бик популяр булган «Любэ» төркеменең элеккеге бэк-вокалисты. Кайгылары бик зур булса да, Җәфәрнең Сафаҗайдагы һәм Мәскәүдәге туганнары аралашудан баш тартмадылар, аның турында ничек тә күбрәк мәгълүмат бирергә тырыштылар.

PRESSA.RU



ТАУЛАР ИЛЕНДӘ



Фәнис ҖИҺАНША

СТУДЕНТ ЧАГЫНДА, МӘГЪДӘН СУЛАРЫ БЕЛӘН ДӘВАЛАНЫРГА ДИП, МИНЕ КАВКАЗГА ҖИБӘРГӘННӘР ИДЕ.

Железноводскиның томан сарган таулары, көнаралаш сибәләп торган яңгыры онытылмаслык булып истә калды. Көннең беренче яртысы ләмгә сыланып, су эчеп узса, икенчесе өч кенә вагонлы дизель поездына утырып, йә Ессентуки, йә Пятигорск калаларына сәяхәттә үтте. Күңелгә иң кереп калганы Кисловодск булды! Дөньялар тыныч торса, һичшиксез, монда тагын киләм әле, дип, күңелемә беркетеп тә куйдым.



■ Болытлардан өстә – 3700 метр биеклектә. Минем артта – Эльбрус, ә аста – Җылы Су нарзан чишмәләре үзәнлеге.



Әул вакытта... СССР дигән бөек империянең таралып яткан мәле. Ялга, дәваланырга килүчеләрнең бар сөйләшкәне – шул хакта. Кыргыз, белорус, украин, әрмәннәр – зур илнең төрле почмакларыннан җыелган халык көн дә парк буйлап тау астыннан чыккан суларны эчәргә бара һәм телевизордан күргәннәрен уртаклашып, салмак кына кире кайта. Миңа – яшь кешегә, әлбәттә, болай йөрү кызык түгел: таулар артында тагын ниләр барын беләсем килә. Домбай тавына экскурсия җыялар дигән игъланны күргәч, ике дә уйлап тормыйча язылдым. Иртәнге дүрттә юлга кузгалдык. «Акча алдыгызмы?» – дип сораганнары истә. Нишләп шунда җылы киемнәрне дә алырга кушмаганнардыр, анысын белмим. Чөнки аста – таулар итәгендә сентябрьнең чалт аяз кояшы озатып калса, өстә безне карлы салкын кышкы көн көтә иде. Акча турында юкка сүз кузгатмаганнар икән: тау өстендә безгә җылы киемнәр алырга тәкъдим иттеләр. Шәкертнең свитербияләй сатып алырлык маясы кайдан булсын?! Бер җиремне дәваларга килеп, икенче җиремә салкын тидереп кайтмасам ярар иде, дип кот чыккан иде...

Ике дистә ел эчендә дөньялар үзгәрде: тараласы таралды, кушыласы кушылып, ниндидер яңа дәүләт барлыкка килде. Ә минем күңелдәге: «Тагын бер барам әле!» – дигән хыял һаман яшәде дә яшәде. Һәм, ниһаять, егерме елдан соң җай чыкты бит менә!

«Минеральные воды» аэропортына көндезге берләрдә килеп төштем. Такси өстәленнән белештем: Кисловодскига хәтле машинага 1200 сум сорыйлар икән. Кыйммәт! Минем әле башланмаган ярты көнем бар: үз җаем белән дә барып җитә алам дип, урамга атладым. Тукталышта мине моннан 20 ел элек озатып калган автобус каршы алды. Бәлки ул да түгелдер, башкадыр, әмма яшенә карасаң – бик охшаган... Билет бәясе 15 сум, багажың булса тагын 15 сум түлисең. Рюкзаклар аскан, тауларга сәяхәткә дип килгән Мәскәү кызы, ирле-хатынлы пар, алдагы урындыкларда «местный»лар һәм Ессентукида туып-үскән бер абзый белән мин – барлык булган пассажир шушы. 15 минут эчендә шәһәргә килеп җиттек: тимер юл вокзалына ук килеп туктадык. Кисловодскига электричкалар сәгать саен йөреп тора икән. Билет бәясе – 160 сум. Җәмгысы 200 сум була, димәк. Ә таксига 1200 сум сораганнар иде... Кешегә күп кирәкме – кәеф күтәрелеп китте. Шатлыгымнан перронда ук чәйләп алдым.

Кисловодск яңгырлары белән каршы алды. Әллә шуңа, әллә атна ахыры булганга, вокзалда дежур торучы полицейскийдан башка беркем юк. Урамнар да буш. Мин килгән «Солнечный» санаторие шәһәр читендә үк урнашкан икән. Тау битеннән агучы шарлавыклар арасында үскән агачларга, роза куакларына күмелеп утыра. «Нарзан», «Ессентуки», «Славянская» сулары агып тора.

Массажны да минераль су белән ясыйлар!

Икенче кичне үк электричкадагы юлдашым сөйләгән термаль Суворов чыганакларына барырга булдым. Алар Ставрополь краенда: шифаханәнең үзеннән үк көн саен кичке аштан соң микроавтобуслар йөреп тора. Нибары 40 минутлык юл. Бәясе 400 сум. Моңа термаль суларның шифасы, тау халыкларының риваятьләрен сөйләүче экскурсовод хезмәте һәм шул чыганакларда коену бәясе кергән. Өч зур бассейн: шуның беренчесе – бина эчендә (анда суның җылылыгы 47 градус), калган икесе урамда (аларында суның җылылыгы 28 һәм 35 градус тирәсе). Әмма минераль матдәләргә бик бай булган ул суларда 15-20 минуттан артык ятарга ярамый. Бигрәк тә йөрәк чирле кешеләргә сак булырга кирәк. Мин үзем дә авыраеп, йокыларым килеп коенып чыктым. Икенче көнне иртәнге ашка да тормыйча баһадир йокылары белән йоклаганмын! Бик каты ишек шакыган тавышка уяндым: җыештыручы икән. Керде дә сөлгеләремне алыштыра башлады. Алар минем алтау. «Икесенә генә сөртенергә өлгердем, калганнары

PRESSA.RU



■ Лермонтов исеме белән бәйле истәлекле урыннарны тамаша кылыр өчен халык дөньяның барлык почмакларыннан агыла монда.



шул килеш», – дип әйтүемә исе дә китмичә, тәза сөлгеләр куеп чыгып китте. Тора-бара әлеге җыештыручы белән шактый дуслаштык без. Алтмышларны узган Василина исемле бу апа Белоруссиядән. Лукашенконы бик мактады. Очсызга гына фатир сатып алган, Минск каласында чәчтарашханәдә эшләүче кызын да бирегә китертмәкче була. Сүз уңаеннан, Кисловодскида фатирлар, чыннан да, бик арзан.

Грозныйда кайчандыр коточкыч сугышлар барганын күз алдына китереп тә булмый.

Калада эш юк (мондагы 50 гә якын шифаханә, ял йортында берьюлы 20 меңләп кеше дәвалана һәм ял итә ала. Чынлыкта, дәваланырга килүчеләр 2 меңгә җыела микән? Мин үзем дә ике кешелек бүлмәдә, ахырга хәтле берьялгызым яшәдем). Шуңа күрә, фатирларын сатып, читкә китүчеләр күп. Фатир бәяләре 500 меңнән (!) башлана. 2 миллион ярымга менә дигәннәрен алырга була... Василина түти ярдәме белән Белоруссия белән Россия арасындагы хезмәттәшлекне, халык язмышын чагылдырырлык роман язарлык мәгълүмат туплагач, мин ишек тоткасына «DO NOT DISTURB» дигән язуны элеп куя башладым.

А. Пушкин, М. Лермонтов, Л. Толстой, Д. Мамин-Сибиряк... Кемнәр генә ял итмәгән, сәламәтлеген ныгытмаган бу якларда. Һәм аларның һәрберсе калдырган эз кадерләп саклана. Бүген минем экскурсияләр маршрутыма бөек рус язучысы Михаил Лермонтов исеме өстәлде.

Иң популяр урын – Пятигорск каласында шагыйрь яшәгән йорт. Пятигорск җирле халык телендә Биш Тау дигәнне аңлата. Герб һәм әләмнәрендә дә тау очына кунган бөркет сурәтләнгән. Чынлап та, кала биш тау ышыгында утыра. Урыны искиткеч гүзәл! Тик шәһәр үзе бик пычрак, җыештырылмаган...

Камыш түбәле «Лермонтов йорты», шагыйрьгә Россиядә беренче куелган һәйкәл (1889 ел), 1831 елда ачылган Лермонтов мәгарәсе, Машук тау итәгендә Н. Мартынов белән дуэль булган урын... Боларның барысын да берьюлы күрәсегез килсә, асылмалы канат юлы белән 993 метр биеклеккә, Машук тавына менәргә киңәш итәм. Ул 1971 елда төзелгән. 20-25 кеше сыярлык ике вагон маятник системасы буенча эшли: өстәге станциядән берсе кузгалганда, икенчесе астан күтәрелә башлый. Алар нәкъ урта бер җирдә очрашалар. Моннан инде искиткеч гүзәллек: урманлы таулар, шау чәчәктә утыручы кыр-болыннар, Бештау каласы, бормаланып агып ятучы Подкумок елгасы уч төбендәге кебек күренә... Кавказның символы – еланны ботарлаучы бөркет һәйкәле янында фотога төшә һәм үзегезнең сурәтегез белән магнит та эшләтеп ала аласыз. Шагыйрьнең гомерен өзгән дуэльнең чын сәбәбен язмыйм, анысын, үзегез баргач, экскурсоводлар авызыннан ишетерсез. Мин исә табиб кушкан суларны эчә-эчә, иртәгә автостоп белән Лермонтов соңгы төнен уздырган Железноводск каласына барырга ният кылып утырам...

Автостоп иң популяр юл йөрү чарасына әйләнеп бара. Мин дә шул ният белән өйләдән соң көнбатышка карап чыгып киттем. Ара ерак түгел, 40 километр чамасы гына. Кичкә әйләнеп кайтырга исәбем. Кисловодск каласын чыгуга, тау итәгендә урнашкан автовокзалны күреп алдым, туктале мин әйтәм, кыяфәтем автостоп белән йөрүче яшьләрнекенә охшамаган, юл биштәрем дә юк. Автобус йөрми микән, сорашып карыйм әле, дип, шунда юл тоттым. Автобус 15 минуттан китәргә тора. Кассадан билет алып, перронга чыктым. Автовокзал буш. Рейслар сирәк. Миңа, нишләптер, моңсу булып китте. Моңсулыкның башы гына булган... Железноводск каласындагы борынгы тимер юл вокзалы эшләми. Рельс шпалларын үлән каплап киткән. Кайчандыр мин шаккатып карап йөргән, балчык сылап дәваланган Бохар әмире махсус салдырган бина ябылган. Ишегалларында тез тиңентен чирәм. Шулай булса да, бер бина бүгенге көндә дәваланучыларны кабул итә. Мин шәкерт чакта анда ашарга йөргәндә Советлар Союзына



■ Ялтырап торган буш урамнар. Күз явын алырлык йортларны күзәтә-күзәтә Владимир Путин исемендәге төп проспекттан Кавказдагы иң бөек небоскреблар урнашкан районга – Сөнҗә елгасы буендагы Грозный-ситига килеп туктадык.

■ Бу сорауны безне озатып йөрүче чечен экскурсоводына да юлладым: «Шәһәр нигә буш?» «Сугыш безне төрле якка чәчте. Әле һаман җыелып бетә алмыйбыз. 1996 елларда Грозный каласының үзәге җир белән тигезләнде бит. Бер генә исән йорт та калмады. Менә бу – безне чорнап алган яңа төзелгән биналарның яртысы буш диярлек», – диде ул.



хәтле мәчет булгандыр дип уйлаган идем аны. Баксаң, ул Бохар ханы өчен 1912 елда махсус салынган бина икән. Төзелеш вакытында бер эшченең биектән егылып төшеп үлгәнен ишеткәч, ул биregә килеп тә тормый. Аннары ул ял йорты итеп үзгәртелә. Биредә Клара Цеткин, Надежда Крупская, Владимир Ульяновлар ял итәргә яраткан. Әлбәттә, биregә халык иң беренче чиратта дәваланырга килә. Тимер Тау итәгеннән җиде төрле минераль су агып чыга. «Смирновская», «Славянская», «Ессентуки-4», «Графский горный источник»... Юл буе безне яшенле яңгыр озата барды. Иртәгә дә мондый көн булса, Чечня башкаласы Грозныйга сәяхәтем өзеләчәк...

Иртәнге сәгать биш. Күк йөзе аяз – кичәге болытлардан берни калмаган. 45 кешедән торган төркемебез биш сәгатьлек юлга кузгалды. Кайчандыр нард халыклары яшәгән таулар арасыннан ике сәгать барганнан соң, экскурсовод безне осетин йортына иртәнге чәй эчәргә алып керде. Монда инде Төньяк Казказда киң таралган осетин бәлешләреннән авыз итәргә була иде. И-и, нинди-ләре генә юк! Ит, бәрәңге, сыр, төрле җимеш бәлешләре дисеңме...

Урамда инде температура 33 градуска кадәр күтәрелгән. Автобус эчедә кояш астындагы һавадан әллә ни аерылмый. Менә шулай, без әкияти бер калага килеп кердек. 200 сум түләп кереп, 2011 елда төзелгән 140 метрлы манараның иң өске катына мендек. Күзәтү мәйданына безнең белән ике хезмәткәр дә ияреп менде. Алар шунда ук көньякка күрсәтеп: «Менә бу якларны төшерергә ярамый!» – дип кисәтү ясадылар. Ни өчен төшерергә ярамау сәбәбен аска төшкәч кенә белдек. Ул күрсәткән якта Рамзан Кадыйровның резиденциясе икән.

Икенче тукталышыбыз исә Рәсәйдә генә түгел, Европада иң зурлардан саналган «Чечня йөрәге» дип аталган мәчет комплексы иде. Анда беренче тапкыр 2008 елда җомга намазы укыла. Ул да Владимир Путин проспектында урнашкан. Шулай ук 14 гектар җирдә Диния нәзарәте, Россия ислам университеты һәм гүзәл парк та бар. Ә мәчеттә исә берьюлы 10 мең кеше намаз укый ала.

Инде 39 градуска җиткән эсселек астында сәяхәтебезне дәвам итәбез. Алда безне Чечня Республикасының беренче Президенты булган Әхмәт хаҗи Кадыйровның музее көтә. Монда килеп керүгә купшылык, зиннәткә аптырап торасың хәтта. Салкын, рәхәт монда. Музейның бер катында төрле илбашлыклары җибәргән бүләкләр куелган.

Киләсе тукталышыбыз – Рамзан Кадыйровның әнисе исеменә атап салынган мәчет. Кайту юлында урнашкан Аргун каласында салынган ул. Төрек архитекторлары тарафыннан төзелгән бу мәчет 2014 елның маенда беренче намаз укучыларны кабул итә. Россия тарихына ул хайтек стилендә салынган беренче мәчет булып кереп кала. (Беренчелек – тагын чеченнарда!) Аның ярымай формасында эшләнгән түбәсе һава торышына карап төсен үзгәрә икән. Кичләрен ул аллы-гөлле төсләргә күмелә.

Намаз залында, мөнбәрнең ике ягына Пәйгамбәребезнең (с. г.) сакал һәм чәч бөртекләре дә куелган. Монысы да минем өчен зур яңалык булды!

«Үзегез белән корал алып керү тыела!» дигән игъланны укыгач, бу тынлыкның алдаучан булуын аңлыйсың.

Әлбәттә, монда килергә теләкләре булган кешеләр өчен мин иртә язны тәкъдим итәр идем. Чөнки яз аенда гына Грозный каласы, исеменнән бик нык аерылып, мөлаем бер шәһәргә әйләнә: шау чәчәк һәм яшеллеккә күмелә. Ә мин исә бу сәяхәтемнән төрле төсләргә күмелеп күкләргә ашкан йортлары белән балкып торучы башкаласын һәм намаз вакытында яңгыраган азан тавышларын салкын кышларда хатирә итеп саклар өчен үзем белән Татарстаныма алып кайтып киттем...




Язманың тулы варианты – сайтыбызда.

PRESSA.RU

16+

МИН АНЫ ГОМЕР БУЕ ЭЗЛӘГӘНМЕН...



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.

Ренат ИБРАҺИМОВ,
Россиянең һәм Татарстанның халык артисты;
гаилә стажы – 50 ел;
җиде бала атасы.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Гомернең төрле чорында бу сорауга төрлечә җавап бирергә буладыр. Мин бүгенге яшем югарылыгыннан торып кына фикер йөртә алам. Чөнки тормыш узган саен, бер үк нәрсәгә карата башкача караш, башкача фикер туа – кеше үзгәрә. Яшь чакта бу сорауны биргән булсагыз, миннән бөтенләй башка җавап ишетер идегез. Тормыш кыйммәтләрен кабул итү, әйткәнемчә, гомер буе бертөрле була алмый. Мин менә хәзер хатын-кызның күзләренә, күз карашына игътибар итәм. Чөнки күзләр – күңел көзгесе, барысы да шунда чагыла. Ә яшьрәк чакта, бәлки, күзгә нык ташлана торган нәрсәләргә, әйтик буй-сынына күбрәк игътибар иткән булганмындыр. Конфетның кәгазенә караган кебек. Тәмле конфетмы аның эчендә, түгелме – ул турыда уйламыйсың. Әһә, матур кәгазьле дисең дә үрелеп аласың. Бу – яшьлек ялгышы.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Рухи дәрт, күтәренкелек булмауны гафу итәргә була. Инь-янь диган төшенчә бар. Аның берсе – ир-атны, икенчесе хатын-кызны белдерә. Бу символларның хатын-кызны белдергәне бер үк вакытта җир символы да. Хатын-кыз үзе дә җир кешесе. Күтәренкелек булмау, җир-су белән яшәүне мин шуңа гафу итәм дә, чөнки бу аларга табигатьтән шулай бирелгән. Музыка белән бәйләп карасак, дирижерлар бит менә шундый күтәренке рухлы кешеләр. Ә алар арасында хатын-кызлар сирәк. Болытларда очарга, хыялланырга дисәң – ирләргә куш. Хатын-кызда исә, ни генә дисәң дә, практик як барыбер күбрәк.

Хатын-кыз бит еш үпкәли, үзенә игътибарны күбрәк таләп итә, диләр. Юк, мин аларның бу сыйфатларын кимчелеккә санамыйм. Бигрәк тә гафу итмәслек кимчелеккә. Минемчә, анысы вак-төяк кенә.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Нәрсә дип җавап бирергә дә белмим... Ә нәрсә өчен аны гафу итмәскә мөмкин? Юк, әйтә алмыйм. Мин гафу итәр идем. Барысы өчен дә. Гомумән, ачу сакламыйм.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Бу сорау дөрес куелмаган дип уйлыйм. Ашарга әзерләүче хатын-кыз илһамландыручы да була ала. Чөнки ашарга әзерләү дә иҗат эше дип уйлыйм мин. Хатын-кыз ашарга әзерләүне илһам, иҗат эше дип санамаса, пешергән ашы да тәмле булмый аның.

Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Һичшиксез! Кабатлап әйтәм, әлбәттә, дус булырга тиеш!

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Беренчесенәме? Беләсезме, мин беренчесен, икенчесен онытгым инде. Алары булмаган да кебек. Бәлки булмагандыр да... Светлана белән гомер буе яшәгән кебек тоела миңа. Ә менә тәкъдимне мин аңар танышканнан соң ярты ел узгач, менә шушы бүлмәдә, үземнең офисымда ясадым. Бу юлы мин никахыма бик җитди карадым. Әлеге адым минем өчен бик җаваплы адым иде, инде миңа һич тә ялгышырга ярамый иде. Яшь чакта гына барысын да уйлап тормыйсың шул... Ул ризалыгын биргүгә, шунда ук мулла чакырып, шушы ук бүлмәдә никах та укыттык.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Әйе, дөрес, нәкъ шулай. Минем хатыным әниемә бик охшаган. Элеккеләре турында сүз бармый, хәзергесен әйтәм. Бәлки мин, чынлап та, гомер буе

әниемә охшаган кызны эзләгәнмендер, көткәнмендер... Хатыным Светлананың әниемә чынлап та бик тә охшаганын, бергә яши башлагач, тагын да ныграк аңладым... Карагыз әле, сорауларыгыз бик кызык. Минем белән моңарчы мондый әңгәмә корганнары юк иде. Ошый миңа бу сораулар!

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Дөнья булгач, мондый хәлләр дә очрый. Ләкин алай булырга тиеш түгел. Ир кеше һәрвакытта да хатынына караганда малны күбрәк тапса, дөресрәк. Гаиләне кайгырту аның өстендә, аның җилкәсендә булсын. Хатын-кыз эшләмәсен димим, эшләсен. Ләкин өйгә килә торган акчаның зур өлешен ир-ат алып кайтсын. Әйткәнемчә, ул аның вазыйфасы. Ир кеше шушы вазыйфа белән туарга һәм яшәргә тиеш.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мин моңа бик уңай карыйм. Мәхәббәткә мәхәббәт белән җавап бирү кемгә дә җиңелрәк. Беренче адымны хатын-кыз атлавы, кайчакта ир кешенең хәлен күпкә җиңеләйтә дип уйлыйм. Ярата икән, яшермәсен, әйтсен, белгертсен моны хатын-кыз.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Әлбәттә, аның холкы, зыялылыгы, интеллекты дип уйлыйм.

Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Ирне ир иткән сыйфатларны бәяли белсен ул: намуслы булуын, гаделлеген, эш сөючәнлеген, дәрәҗәсен, абруен күрсен. Ә яратуын? Ә ир-атның яратуын ул бәяләргә түгел, көн саен тоярга, сизәргә тиеш.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Бу сорауга җавап биргәнче, тарихка күз салыйк әле. Чибәр, көчле хатын-кызлар аркасында ир-атның вәсвәсәгә бирелүе, шуның аркасында кирәкмәгән юлга кереп китүе, малыннан, дәрәҗәсеннән, абруеннан колак кагуы булмаган түгел – булган бит. Мисаллар шактый... Андый хатын-кызлар ир-атларның кайберләрен куркыта да торгандыр дип саныйм. Хатын-кыз – йомшак халык: синеке генә түгел, бер үк вакытта ул башканыкы да булырга мөмкин. Үтә чибәр хатыннарга якынлашмаска кирәк, минемчә. Әгәр дә инде, тәвәккәлләп, якынлашасың икән, һәрвакыт сак булырга киңәш итәр идем.

11 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, Сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Бу төшенчәләрдә аерма бик зур, минемчә. Мәсәлән, әгәр дә хатын-кыздан туктатып юл сорасаң, иманым камил, сиңа кирәк якның ул һәрвакыт киресен күрсәтәчәк. Ул моны махсус эшләми, ялганлыйм дип тә уйламый. Әмма ләкин кире якка юлны бик әйбәтләп өйрәтеп җибәрә – аның логикасы шундый, фикерләве гел башкача.

Логикалар арасындагы аерма хәтта ашарга әзерләгәндә дә күренә. Хатын-кыз барысын да төгәл рецепт буенча эшли: күпме кушканнар, шуның кадәр генә сала. Ә ир кеше чама белән башкара, һәм аныкы дөресрәк тә булып чыга. Ашчыларга гына карагыз – юкка гына аларның күбесе ир-ат түгел бит.

12 Хатын-кыз белән ир-атларның икесе ике Галәмнән икәнлеге билгеле. Күп вакытта аңлашылмаучанлык шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә менә нәкъ шулай эшләгәнен аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Мәсәлән, ремонт ясыйсыз, ди. Нинди төстәге обой, нинди плитка алырга? Хатын-кыз, беренче чиратта, практик якны кайгырта, ә ир-ат фантазиягә бирeләчәк – стандартлардан читкә китәчәк. Хатын-кызга исә ипле булсын, тормышчан булсын, ныклы булсын. Ир-ат, әйткәнемчә, башкаларда булмаганны эшләргә тырышачак. Үзем турында гына әйтмим, тормыштагы күзәтүләремнән чыгып әйтәм. Ә уртак фикергә омтылу исә файдасыз! Хатын-кыз бит үз сүзендә торачак, үзен һәрвакыт йөз процент хаклы дип санаячак. Бу очракта нишлимме? Юл куям, әлбәттә.

13 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Бу сорауга җавап бирдем кебек. Андый вазгыятьләр тормышта күп булганга, аның чишелешләре дә бертөрле генә түгел, әлбәттә. Мин үзем күп вакыт бәхәсләшмәү ягында.

14 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Мин үзем пешерәм андый вакытта. Хатын-кызның төрле чагы була бит аның: балалар борчуы, баш өянәге... Баш бик еш авырта бит сезнең. Кыскасы, бу табигый хәл. Моны үземә хөрмәт күрсәтмәү дип тә санамыйм. Берни дә булмаган, бүген бары шулай килеп чыккан... Кафега да бармыйм, пиццага заказ да бирмим: плитә янына басам да нәрсә булса да әзерлим. Мин гаиләмә ашарга пешерә алмаслык ирмени?!

15 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Бик еш күзәтелә торган хәл... Мин аның шулай буласын белгәнгә, чыгып китәсе вакытны гел бер сәгатькә алданрак дип әйтәм. Үзем дә тыныч, барасы җиребезгә дә өлгерәбез. Аңлашып яшәсәң, үзара хөрмәт, ярату булса, мондый гына проблемаларны хәл итеп була ул. Коръәндә «хатын-кыз ирләрнең кабыргасыннан яратылган» диелгән. Ә кабырга төз әйбер түгел, аны төзәтергә, турайтырга тырышсаң, сындыруың да бар. Шулай булгач, нигә хатын-кыз белән сүз көрәштерергә?! Файдасы барыбер булмаячак, ә ахыры начар тәмамланырга бик мөмкин.

16 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Бүләк биргән якын кешеңә: «Нигә мондый бүләк алдың?» – дип әйтергә ярыймыни?! Ул бит БҮЛӘК итә! Чын күңелдән бүләк итә! Менә шунысы мөһим аның.

PRESSA.RU



Республикада Баш мие кан тамырларын дәвалаучы 18 үзәк бар. Шуларның берсе – Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсендә. Бирегә 331 мең 513 өлкән кеше беркетелгән. Әлеге үзәкләрнең эшчәнлеген Төбәкара клиник-диагностика үзәге координацияли.

ЗАМАН ЧИРЕ



Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсе неврология бүлеге мөдире Әлфия Якуб кызы Нәҗипова, авыруларга мөнәсәбәтнең «ишектән – эңгәчә...» көйләнүен әйткәч, гаҗәпләнмәдем. Бу хакта Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш ангионевро-логы, профессор Динә Хәсәновадан ишеткәнем бар иде инде. Ә хәзер менә моның ни икәнен үз күзләрем белән күрергә дә насыйп булды. Хастаханә ишеген ачып кергән авыру, ятасы палатасына кереп җиткәнче, бөтен тикшеренүләрне узып, хәл-торышына билгеле бер бәя алырга өлгерә. Бүлектә чит илләрдә белемен күтәреп кайткан тәҗрибәле белгечләр эшли. Гомере кыл өстендә торган каты авырулар янында узган табиб-җитәкчене күп нәрсә борчый: бүген үлем-китемнәрнең 48 проценты церебраль инсульт аркасында булуын әйтү генә дә җитә. Бу чиргә юлыгучыларның нибары 8 проценты гына тулысынча дәвалана, элеккеге тормышына кайта. Инсульттан соң исән калучыларның 20 процентына даими игътибар кирәк була.

Кан тамырларының кысылуы – бүгенге көндә киң таралган чирләрнең берсе. Кан йөреше үзгәргән орган бик тиз эштән чыга, кешене үлем хәленә җиткерә. Хастаханәгә китерелгән авырулар диагноз куелганнан соң, шундук нейрореанимация бүлегенә күчерелә. Кризис кичергән пациентларның 70 проценты исән кала, дип әйтәләр икән, бу инде сәламәтлекне тернәкләндерү шартларының тиешенчә булуы турында сөйли. Бу очракта белгечләрнең төп максаты – аларны хастаханәдән көнкүрештә якыннарыннан мөмкин булганча бәйсез, мөстәкыйль яшәргә өйрәтеп чыгару. Һәм алар моңа ирешә дә. Табибның әйтүенә караганда, бу чирдән котылуның иң нәтиҗәле чарасы: баш миендәге кан йөреше үзгәрешләрен башлангыч чорында ук ачыклау. Кан басымы югары, шикәр диабеты, йөрәк ишемиясе булган, ревматизм белән җәфаланган авыруларга кагыла бу.

Без бүген пациентларны бер табибтан икенчесенә чабарга мәҗбүр иткән күп йөзле, билгеләре күптөрле булган чир турында да сөйләмәкче. Кан тамырлары әйбәт, сәламәт, ә менә баш мие юк-юк та «киреләнеп» ала. Вегетатив нерв системасы функцияләре бозылудан килеп чыккан кан тамырлары дистониясе (вегетативно-сосудистая дистония) хәзер яшьләрне дә бөтереп алды. Бу чир белән бәйле сорауларга абруйлы белгеч, медицина фәннәре кандидаты Әлфия НӘҖИПОВА җавап бирә.

– Вегетатив үзгәрешләр балачактан ук башлана. Әни кеше йөккә калганда яисә тудырганда балага кислород җитмәү, үзәк нерв системасындагы тайпылышлар, тумыштан имгәнүләр, үзәк нерв системасы эшчәнлегендәге үзгәрешләр... болар барысы да вегетатив нерв системасын какшатуга китерә. Мондый балалар еш авырый, бөркү-эссене начар кичерә, һава алышынулар вакытында баш авыртудан зарлана. Кайберәүләрдә, өлкәнәя башлагач та, бу чирләр үзләрен бик сиздерми дә. Ә кайчак, бала балигълык яшенә җиткәндә, баш авыртуга, баш әйләнүгә зарлана, тиз арый, шомлана, елакка әйләнә, бик тиз кызып китә. Мондый очракта белгечкә күренергә киңәш итәр идем. Шунысын искәртергә тиешмен: бу чир кеше олыгая башлагач та килеп чыгарга мөмкин. Сәбәпләре:

- чирнең нәселдән килүе;
- эмоциональ кичерешләр;
- организмдагы төрле инфекцияләр;
- баш мие имгәнүе;
- спиртлы эчемлекләрне күп куллану;
- тәмәке тартулар;
- кофе эчү;
- гормональ тайпылышлар;
- муен остеохондрозы;
- эчке органнардагы башка чирләр.

Билгеләре

– Бу чирнең билгеләре күптөрле. Шунлыктан пациентларның кайсы гастроэнтерологка, кайсы тире авырулары табибына, кайсы кардиологка, йә булмаса, эндокринологка, иммунологка, психиатрга йөри башлый. Ә нәтиҗәсе... күренми. Еллар буена ашказаны бизләре ялкынсынуыннан зарланып – гастроэнтерологка; тахикардия дип, кардиологка йөрүегез дә бернинди файда бирмәячәк. Чөнки еш кына вегетатив кан тамырлары дистониясе үзенең йөзен төрле чирләр рәвешендә күрсәтә. Әле бер, әле икенче битлеген кия дип әйтимме... Ул йөзгә кырлана. Шуңа да аны танып белү гади эш түгел. Күп вакыт дөрес диагноз кую өчен берничә табибның киңәше кирәк була. Әгәр дә билгеле бер вакыт дәвамында баш әйләнү; бер-сәбәпсез шомлану һәм паникага бирелү; йокысызлык; баш авыртулар; кул яисә бөтен тән калтырау, хәлсезләнү сизелә; башка төрле уйлар килә; йөрәк тибеше әле ешая, әле әкренәя; кул-аяклар ойый; сулыш алуы кыенлаша; биткә кан йөгерә; косасы килү, аң югалту күзәтелә икән, сезгә һичшиксез табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шулай да төрле кешедә ул төрлечә чагылырга мөмкин: әйтик, кемдәдер ул пульсның ешаюы, кан басымының күтәрелүе, аяк өшү, агарыну, йөрәк чәнчү, температура күтәрелү белән дәвам итә. Ә кемнеңдер, киресенчә, пульсы төшеп китә, тирләп, йөз кызарып чыга, кан басымы төшә. Баш әйләнә, тын кысыла, хәлсезләнә башлый.

Кайвакыт авыруда аның катнаш билгеләре дә күзәтелә. Мондый вакытта бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк: бу чир тормышка куркыныч янамый. Өянәк вакытында күп кенә пациентлар паникага бирелә, куркуга төшә. Куркырга кирәкми. Бу – бары тик диагноз, хөкем карары түгел. Ул аллергия сыман. Әйе, ул бар, әмма моңарчы әле бу чирдән берәүнең дә үлгәне юк.

Диагностика

– Бу чиргә диагнозны терапевт, невропатолог һәм кардиолог куя. Һәм, әлбәттә инде, моның өчен табиблар киңәш иткән барлык тикшеренүләрне дә узарга кирәк. Мисалга, неврология өлкәсендә киң кулланыш тапкан электроэнцефалография үтү (баш мие эшчәнлеген чагылдыра), магнитлы атом-төш резонансы (иң төгәл ысулларның берсе) ярдәмендә эчке органнарны тикшерү, электрокардиография узу һәм башка шуның ише кирәкле анализлар ярдәмендә генә пациентның хәлен бәя биреп була.

Дәвалау

– Баланда вегетатив тайпылышлар барлыгын белә торып та дәваламасаң, ул соңыннан төрле авыруларга китерергә мөмкин. Табибка вакытында мөрәҗәгать иткән очракта пациентларның 80 проценты уңышлы дәвалана. Чирне дәвалауда төрле ысуллар кулланыла:

- ачык һавада йөрү;
- йөзү;
- чаңгыда шуу;
- туризм белән шөгыльләнү;
- организмны чыныктыра торган процедуралар.

Ә минә тренажерларда күнегүләр ясарга киңәш итмәс идем. Башны күкрәктән түбән тотканда, йөрәк кан тамырлары системасына авырлык килә.

Иң яхшысы:

- спортның канәгатьлек китерә торган уен төрләре белән мавыгу;
- эштә һәм өйдә үзегезне тыныч тотарга тырышыгыз, эмоциональ кичерешләр сезгә бер дә кирәкми, ул зыянга гына;
- музыка тыңлагыз, матур фильмнар карагыз;
- эш белән ялны чиратлаштырыгыз;
- тәмәке тарту, аракы эчү, шаушулы компанияләрдә утыру да файдага булмас.

Аеруча ашауга игътибар итегез:

- кан басымы күтәрелүчән кешегә фасоль, эремчек, шпинат ише ризык тәкъдим итәр идем. Кофе, куе чәй, спиртлы эчемлекләрне онытыгыз!
- кан басымы түбән булучыларга чәй дә, кофе да, кефир белән сөт тә бик ярап куя. Бу продуктлар кан тамырлары эшчәнлеген яхшырта.

Аннары организмга кальций, магний һәм калий кирәклеген истән чыгармагыз! Монысы да бик мөһим. Бу әйберләр борчакта, йөземдә, күрәгәдә, кара җимештә, гөлҗимештә, кишердә, чикләвектә, карабодай һәм солы боткасында да бар.

Һәм, әлбәттә инде, шундый диагноз куелган икән, дәвалау физкультурасы белән шөгыльләнегез, витамин эчегез. Табиб биргән дарулардан дөрес файдаланыгыз. Бу чиргә каршы көрәштә ихтыяр көче бик зур роль уйнавын онытмагыз!

PRESSA.RU



«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

Яңа – 2017 елгы «Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Татарстанның атказанган артисты, җырчы, композитор Ләйсән МӘХМҮТОВА ачып җибәрә. «Сөембикә» журналы укучыларына үзе тәмле, үзе җиңел бер салат ясап күрсәтмәкче ул. «Мин бу салатның ничек аталганын да белмим. Исемен улларым Сөләйман белән Йосыф кушты. Безнекеләр балыклы салат яратмый, ничектер илһамым килеп, шушы салатны ясап караган идем, барыбызга да бик ошады. Бәйрәмнәргә хәзер гел шуны әзерләргә тырышам», – дип, аш-су өлкәсендәге серләре белән уртаклашты «Зө-Ләй-Лә» төркеме кызларының берсе булган Ләйсән Мәхмүтова.



«АЛЬТЕРНАТИВА» САЛАТЫ



Кирәк:

- 200-250 г пешкән ит (сыер ите дә ярый, тавыкныкы да);
- 3 бәрәңге;
- 200 г шампиньон гөмбәсе;
- 1-2 кишер;
- 4 йомырка;
- 150 г сыр;
- 1 чөгендер;
- майонез;
- бизәү өчен гранат төшләре һәм кара виноград.

Эш барышы:

■ яшелчәләрне пешереп суытабыз, кабыгын әрчибез. Гөмбәне телемләп турап, майлы табада әзер булганчы кыздырып алабыз.

■ Итне вак итеп турыйбыз да зур тәлинкә төбенә тигезләп салабыз. Тәлинкә урынына һәркемгә аерым савытка ясарга да була. Алай оригиналь дә килеп чыга әле. Без исә кечкенә пыяла савытлар кулландык. Пыяла аркылы салатның һәр каты матур булып күренеп тора.

■ Ит өстенә эре угычтан уылган бәрәңге түшәп, өстенә майонез ягабыз. (Без майонезны артык күп итеп якмадык.)

■ Чиратта – гөмбә, аннары эре угычта уылган кишер. Кишер өстенә дә майонез ягабыз.

■ Йомырканы вак угычтан уып, кишер өстенә тигезләп салабыз да аның өстенә уылган сыр сибәбез.

■ Сыр өстенә эре угычтан уылган чөгендер салып, өстеннән майонез ягабыз.

■ Салатның өстен кара төстәге виноград һәм гранат төшләре белән бизәп, табынга куябыз. Бу салатны бер-ике сәгать алдан ясап куйсаң яхшы, ул чакта ризыкларның тәме бер-берсенә сеңеп, салат сусылрак һәм тәмлерәк булачак.

Ашларыгыз тәмле булсын!



PRESSA.RU

Әгәр дә сезнең кайчандыр яратып киеп тә, хәзер инде модасы чыккан мех бүрекләрегез яки җиң очлары кыршылган туныгыз булса, аларны һич тә чыгарып ташлый күрмәгез. Болардан өр-яңа киемнәр «бәйләп» була. Әйе-әйе, сез дөрес укыдыгыз, нәкъ менә бәйләп... Ә бу эшкә безне алтын куллы остабыз, «Сөембикә» укучыларының күптәнге танышы Зөлфия СӘЛИМҖАНОВА өйрәтәчәк. Ул безне сокландырудан туктамый, яңадан-яңа идеяләре белән гел илһамландырып кына тора. Менә бу юлы да безгә иске мех бүрекне сүтеп, шуннан башлык «бәйләргә» тәкъдим итә.
Күз – куркыр, кул эшләр, диләр, тәвәккәлләп, тотынабызмы?



МЕХТАН «БӘЙЛӘНГӘН» БАШЛЫК



Кирәк:

- кулланыштан чыккан мех бүрек (чәшке, төлке, кара төлке мехларыннан матур килеп чыга);
- башлык бәйләр өчен калынрак бәйләм җебе. Җепнең төсе мех төсе белән туры килергә тиеш;
- баулы бәйләм энәләре (башлык әйләнә буенча бәйләнә);
- мехны кисү өчен үткен пычак (моның өчен кибетләрдә махсус эш коралы да сатыла. Без исә кәгазь кисә торган пычак – канцелярский нож кулландык. Лезвие дә кулланырга була);
- мех төсенә туры килә торган тегү җебе һәм тегү энәсе;
- җеп астында басылып калган мех бөртекләрен тартып чыгарыр өчен нечкә ыргак;
- булавка.



Эш тәртибе:

■ башлыкның нигезе мех төсенә туры килә торган бәйләм җебеннән бәйләнә. Стандарт үлчәмле башлык өчен 72 күзәнәк җыеп, 1 уң, 1 сул белән бәйли башлыйбыз. Башлык әйләнә буенча бәйләнә. 20 см бәйләгәч, һәр ике күз саен икешәр күзне бергә бәйләп алып, бәйләмдәге күзләр санын киметә башлыйбыз. Икенче рәттә инде күзләр саны берәр күз саен киметелә. Әнәдә калган күзләр аша бәйләм җебен уздырып, күзләрне җыябыз, җеп очын бәйләм эченә бәйләп яшерәбез.

■ Мех бүрекнең эчен сүтеп алабыз, анысы безгә кирәкми. Безгә фәкать мех кына кирәк. Мехны селкеп, тузаннан, чүп-чардан арындырабыз да, үткен пычак белән 0,5-0,6 см тасмаларга теләбез. Мех аркылыга түгел, буй юнәлештә теленә. Тасмалар озын булмасын, 35-40 см булса, бик җиткән. Кыскарак булса да, зыян юк, эш барышында аларны энә-җеп белән тегеп, бер-берсенә ялгап җибәрергә була.

■ Мехны тасмаларга телүнең үз сере бар: беренчедән, тасмага телә башлаганчы, мехның читеннән кайчы белән 2-3 мм чамасы гына кисеп җибәрәбез. Аннары калган өлеш пычак белән, мехны кулда тоткан килеш кенә киселә. Тактага салып кисәргә уйласагыз, мехны әрәм генә итәчәксез.

■ Мех тасмаларны бәйләм башлыкка беркеткәндә йон бөртекләренең аска карап торуларына игътибар итегез. Тасма башлыкка уң күзләр аша, астан өскә таба беркетелә. Моның өчен тасманың очын башлыкның аскы читенә белендерми генә тегеп куябыз. Икенче очына булавка кадап, булавканы һәр бишенче-алтынчы рәт аша уң күзләрдән тыгып алабыз. Рәсемдә бу ачык күренә. Мех тасманы шул рәвешчә өскә кадәр башлыкка беркетә-беркетә менеп, тасма очын эчке якка чыгарып, башлыкка тегеп куябыз.

■ Икенче тасма беренчесеннән 2-3 күз ара калдырып беркетелә. Әгәр дә мех тасмагыз чәшке ише, йон бөртеге кыскарак мехтан икән, ул очракта араны якынайтабыз. Мех тасмалар арасында бәйләм җебе күренеп тормасын. Гәрчә, әгәр дә фантазия белән эш итсәң, тасма араларын ерагайтып, бер рәт мех, бер рәт бәйләм бизәк, бер рәт мех итеп, төрлечә кыландырып карарга да мөмкин. Хәтта ике төрле мехны да чиратлаштырырга була.

■ Безнең 72 күздән бәйләнгән башлыкка кара төлке мехыннан теленгән 18 тасма китте. Ыргак ярдәмендә мехның бәйләм җебе астында басылып калган бөртекләрен тартып чыгарабыз. Тасмаларны беркетеп бетергәннән соң, башлыкны сирәк тешле тарак белән тарап, бераз пар өстендә тотып алабыз. Пар өстендә тотканда бөгәрләнгән йон бөртекләре языла, турая.

■ Шкафта урын биләп кенә яткан, чыгарып ташларга да кызганыч булган мех бүрек, яка, туннарга әнә шулай итеп яңа сулыш өрергә мөмкин. Мех тасмалардан башлык кына түгел, жилет, бишмәт кебек зуррак киемнәр дә бәйләргә була.

■ Мех белән «бәйләү»нең төрле ысуллары бар. Безнең очракта мех тасмаларны бәйләм аша уздыру техникасы кулланылды. Әле тагын мех тасмаларны бөтереп (моны электрга көйләнгән шөреп боргычы белән эшләү уңай), җеп ясарга һәм шуны гадәти бәйләм җебе урынына кулланырга була. Тагын бер ысул – ыргак белән бәйләү. Бәйләмнең нигезе итеп гадәти бәйләм җебе алына, мех тасмалар рәтләрне үргән вакытта ук бәйләмнең уң ягына элмәк белән бәйләнеп, беркетелеп барыла.

■ Бәйләгән киемнәрнең матурлыгы мехның сыйфатына бәйле. Шуңа күрә мехның артык «пеләшләнгән», төсе бик нык уңган өлешләрен кулланырга киңәш итмәс идек.

PRESSA.RU



АЙНЫҢ КӨҢЕ ЕЛ ТУЙДЫРА

Үсемлекләр	февраль	март	апрель	май	июнь
Баклажан	12, 14, 23, 28	3, 4, 12, 14, 16, 20, 25, 30, 31	9, 18, 22, 26-28	3, 4, 14, 15, 19, 24, 31	1, 2, 11, 16, 20
Баллы борыч	14, 16, 23	3, 4, 12, 14, 20, 30, 31	9, 11, 18, 26	8, 14, 15	2, 11, 20
Башлы суган		17, 26, 31	22, 28	7, 8, 9, 19, 20, 24	
Батун суган			19, 22, 23, 26, 27, 28	3, 4, 9, 10	27-30
Бәрәңге				4, 7, 8, 9, 19, 24, 31	1, 6, 7, 15, 16
Борчак, фасоль			22, 28	3, 4, 9, 10, 15, 19, 24, 25, 31	1, 2, 7
Кабак, ташкабак, патиссон			9, 18, 26, 27, 28	3, 4, 14, 15, 24, 31	1, 2, 11, 20
Карбыз, кавын			22, 26, 27, 28	3, 4, 15, 19, 24, 25, 31	1, 2, 11, 16
Кәбестә, чәчәк кәбестә		20, 25, 26, 30, 31	9, 12, 13, 18, 22, 26, 27, 28	4, 15, 19, 24, 25, 31	1, 2, 11, 16, 20
Кишер, чөгендер, шалкан, редис, дайкон			16, 17, 18, 23, 28	4, 9, 14, 15, 19, 24, 31	1, 6, 7, 10, 11, 15, 16, 20, 28, 30
Кыяр	1, 5, 12, 14		9, 18, 22, 26, 27, 28	4, 15, 19, 24, 25, 31	1, 2, 11, 16, 20
Тамыразык петрушка, тамыразык сельдерей	19-24	20-24	16, 18, 23, 28	4, 9	
Томат	14, 16, 18, 24, 26, 27, 28	3, 4, 10, 12, 20, 25, 30, 31	8, 12, 13, 22, 26, 27, 28	9, 15, 19, 24, 25	2, 7, 11, 16
Сарымсак			19, 22, 23	7, 8, 9	
Укроп, петрушка, кыяк суган, салат	5, 12, 14, 23-28	10-15, 17	18, 20, 23, 26-28	4, 15, 17, 20, 24, 25, 31	2, 11, 16, 20, 27-30
Декоратив агач-куаклар			12, 13, 22, 26, 28	1, 2, 3, 9, 10	
Берьеллык чәчәкләр	1, 4, 5, 10, 12, 18, 27, 28	3, 4, 10, 12, 20, 28, 30, 31	4,5, 9, 18, 21-23, 26-28	1-4, 15, 24, 25, 28-31	1, 2, 11, 16
Ике еллык һәм күпьеллык чәчәкләр	**Орлыктан үстерү:** 4, 5, 10, 12, 18, 27, 28	**Орлыктан үстерү:** 3, 4, 10, 17, 25, 30, 31	**Орлыктан үстерү:** 4, 5, 6, 12, 22, 23, 26-28	**Орлыктан үстерү:** 1-4, 10, 19, 24, 28-31 **Тамырларын бүлеп утырту:** 9, 10, 19	**Орлыктан үстерү:** 6, 16, 20, 25-28 **Тамырларын бүлеп утырту:** 6, 7, 15, 16
Суганчалы чәчәкләр			5, 8, 9, 12, 13, 16-18, 28	2, 9, 14, 15, 19, 29	2, 6, 7, 10, 11, 15


Кучкар. Тормышыгызда күңелле һәм күптән көтелгән үзгәрешләр булыр. Кыю ниятләр кору өчен шулкадәр яхшы вакыт. Тормыштан күбрәкне теләргә курыкмагыз. Һәртөрле киртәләрне җиңел генә кичәрлек көчкуәтегез барлыгын тоярсыз.


Үгезбозау. Тормышыгызда зур яңалыклар булуы ихтимал, алар исә фикерегезне дә, тирә-юньгә булган карашыгызны да бик нык үзгәртер. Үзегездә әллә нинди көч тоярсыз, гомердә дә хыялланмаган эшләрне эшләп карыйсыгыз килер.


Игезәкләр. Күңелле вакыйгалар бөтереп алыр, тормышыгызны яхшы якка үзгәртү форсаты килеп чыгар. Тотынырга да куркып торган әллә нинди катлаулы эшләрне бик җиңел генә башкарып чыга алырсыз.


Кысла. Тормышыгызның һәр өлкәсендә үзгәрешләр көтелә. Көнкүрешегез тагын да яхшырачак; бу исә яңа эшләргә, яңа уңышларга этәрәчәк. Күңел күтәренкелеге, бәхет дигән нәрсә озак көттермәс.


Арыслан. Ямансулап, күңелсезләнеп утырырга туры килмәс. Ял итү, сәламәтлекне ныгыту форсаты килеп чыгар. Мөһим эшләр, катлаулы мәсьәләләрне чишәр өчен дә кулай вакыт. Башкаларны үзегезгә карата алу сәләтегез көчәер.


Сөмбелә. Зур һәм кечкенә җиңүләр, күңелле вакыйгалар көтелә. Бөтен акылыгызны эшкә җигеп, тормышның текә борылышларыннан исән-имин чыгарсыз. Кечкенә генә низаглардан да сакланыгыз. Шәхси тормышыгызны җайлар өчен бик шәп вакыт.


Бизмән. Тормышыгыз оттырышсыз лотереяны хәтерләтер. Үзегездә көчле азарт тоярсыз, бу исә һәр ниятне тормышка ашырырга ярдәм итәр, уңышка юл ачар. Нинди генә гамәл кылсагыз да, нәтиҗәсе сезнең өчен яхшы тәмамланачак.


Чаян. Көчле һәм актив булачаксыз. Һәрнәрсәдән ямь табарсыз. Күңелегезне биләп алган бәхет хисе сезне яңа эшкә, яңа үрләр яуларга әйдәр. Һәртөрле башлангычлар өчен яхшы вакыт, каршылыкларны җиңел генә атлап чыгарсыз.


Укчы. Уңышлы ай. Даһи идеяләр туар. Аларны тормышка ашырыр өчен мөмкинлеге дә чыгып тора. Әмма яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен кыюрак булырга кирәк.


Кәҗәмөгез. Соңгы вакытларда сарыф ителгән көчне тулыландыру җае чыгар. Башкаларның вазыйфаларын үзегезгә йөкләмәгез, әлегә яхшатлану кирәкмәс. Турысын әйтергә яратуыгыз эштә аяк чалырга мөмкин, иң яхшысы: ыгы-зыгыларга катнашмый гына, барысын да читтән күзәтү.


Сукояр. Максатчанлык күрсәтерсез, үз дигәнегездә нык торырсыз. Әллә инде шуның нәтиҗәсеме – ай башында ук уңышның сезнең яклы булуын тоярсыз. Бу айда башланган эшләр тиз һәм җиңел хәл ителә.


Балыклар. Бәхет диңгезендә коена, дигән сүзләр нәкъ менә сезнең турыда. Яшерен хыялларыгыз тормышка ашар, моның шатлыгы озакка барыр. Сәфәр чыгу яки зур җитәкче янына керү өчен кулай вакыт – уңыш сезнең якта.

гыйнвар *да кабынган йолдызлар*

Татарстан



Галия Нигъмәтуллина (2.01.1907–4.01.1990) – **ТАССРның халык артисты.**

Орск шәһәрендә, бай гаиләдә туа. Сәхнәгә беренче тапкыр 1923 елда, Орск шәһәре һәвәскәрләре куйган «Таһир-Зөһрә» (Ф. Бурнаш) спектаклендә Зөһрә роле белән чыга. Казан Татар театр училищесының беренче чыгарылыш студенты. Училищены 1926 елда тәмамлап, берара Әстерхан татар театрында эшләп ала. 1930 елдан Татар академия театрында эшли. Тәүге зур роле – «Беренче чәчәкләр» спектаклендәге (К. Тинчурин) Сара роле. Галия ханым драматик рольләрне дә, көлкелеләрен дә, хәтта тискәреләрен дә бик оста башкаручы артистка була. Ул күренекле татар артисты һәм режиссеры Хәким Сәлимҗановның тормыш юлдашы, режиссер Марсель Сәлимҗановның әнисе.

Россия



Рената Литвинова (12.01.1967) – **театр һәм кино артисты, сценарист, кинорежиссер. Россиянең атказанган артисты.**

Беренче тапкыр 1989 елда, Алла Суриковaның «Две стрелы. Детектив каменного века» дип аталган детектив комедиясендә күренә. Башкарган роле исә бер күренеш кенә була. 1994 елда украин режиссеры Кира Муратова аны үзенең «Увлеченья» драмасында төп рольне уйнарга чакыра. Шулай да Рената Литвинованы халыкка «Граница. Таежный роман» телесериалы таныта. Гомумән, Литвинова 33 фильмда уйнаган, 14 картинага сценарий язган, үзе дә алты фильм төшергән. Шуларның икесенең: «Богиня, как я полюбила» һәм «Последняя сказка Риты» фильмнарының сценариен үзе яза, үзе куя, хәтта үзе уйный да.

Чит илләр



Аманда Пит (11.01.1972) – **кино артисты.**

Нью-Йоркта туа, Колумбия университетында уку белән бергә театр студиясендә дә шөгыльләнә. Берничә тапкыр эпизодик рольләр башкара, рекламаларда күренә. Экраннарга чыккан беренче зур роле – «Джек и Джилл» сериалындагы Жаклин Барретт роле. Шулай да кино сөючеләр аны 2001 елда экранлаштырылган «Девять ярдов» фильмы аша таный башлый. 2005 елда актрисаны «Больше чем любовь» фильмында уйнарга чакыралар. Фильм искиткеч уңыш казанса да, кино тәнкыйтьчеләрнең каршылыклы фикерләренә дучар була. Уңышлы башкарган рольләре дип «Любовь по правилам и без», «Сириана» фильмнарын атарга мөмкин. 2010 елдан башлап «Квантовое путешествие: Космическая одиссея Кассини» дип аталган фәнни-танып белү проектында катнаша.

PRESSA.RU







КУРЧАКЛЫ УЙНАУЧЫ РӘССАМ

Татьяна Волкованың үзен күреп белмәсәләр дә, иманым камил, курчаклары күпләрнең хәтеренә уелып кала торгандыр. Аның кибетләр каршында сатып алучыларны урамнан ук мөлаем елмаеп «каршы алып утыручы» әби-бабайлары янында басып кемнәр генә фотога төшми калды икән Казанда?! Хәер, хәзер инде Казанда гына да түгелдер. Ни өчен дигәндә, останың милли киемнәр кигертеп ясалган ул хикмәтле курчаклары күргәзмәдән күргәзмәгә йөри торгач, күптән инде чикләрне узып, Франция, Германия, АКШ, Израильгә кадәр үк барып җиткән.

– Мин яшәгән Казанның Урман арты бистәсендә гомер итүче зирәк картлар кечкенәдән күңелемә якын. Әбиләр дә, кичен өйдәге эшләрен бетерүгә, ак яулыкларын, берсеннән-берсе матур чигүле алъяпкычларын ябып, бәйли башлаган оекбашларын тотып, капка төбенә чыгып утырырлар иде, – ди автор, милли курчаклар иҗат итүгә сәбәп булган балачак хатирәләрен яңартып.

Менә шуннан соң, ничек шушы кадәр дә нурлы йөзле итеп ясый ала икән ул бу татар әби-бабайларын, дип гаҗәпләнмисең инде. Күңелендәгесе белән әнә шулай юмарт бүлешә оста. Бабайларын мыек астыннан хәйләкәр елмайтуын гына күр... Ә күзләр?! Алардагы яшәү дәртен, очкынны, рәхәт канәгатьлекне күрсәтүнең бар әмәлен таба Татьяна Николаевна. Юкса күз урынына бөтенесендә бер төймә генә бит инде... Шулаен шулай, әмма аның «очкынлы» дигәннәре бөтенләй башка. Күз кырыйларына кырыкмасакырык сыр чыгартып, бәбәкләрен кыса төшә дә, җайлап кына ирен читләренә хәйләкәр елмаю кундыра оста.

– Кәефсез, дөнья мәшәкате баскан курчаклар ясау минем эш түгел. Моңа хәтта үземнең хокукым да юк дип саныйм, – ди автор бу уңайдан.

Курчак кына дисәк тә, биредә курчакчы өчен бер генә вак мәсьәлә дә юк. Бар да мөһим – пропорцияләр дә, килеш-килбәт тә, киемдәге һәр деталь дә. Шул ук вакытта милли традицияләрдән (бәби итәкле күлмәкләр, чигүле калфаклар, изү, камзул, түбәтәйләр, тамбур җөй һәм башкалар) тайпылыш булырга тиеш түгел, дигән фикердә оста.

Соңгы өч елда Татьяна бөтенләе белән диярлек 50 нче, 60 нчы елларда калган балачак иленә кире әйләнеп кайтты. «Крестьян балалары», «Кышкы әкият» шәкелләре бер-берсен кабатламаган 50-60 курчакны берләштерә. Аларның һәркайсы уч төбенә сыярлык кына булса да, шулар аша тулы бер дөньяны, дәверне сурәтли автор. Биредә аяк астындагы карның шыгырдавын гына түгел, чана белән таудан җилдереп төшкәндәге тизлекне дә, карның йомшаклыгын да, битләрне кызартканчы чеметтереп чыныктыручы суыкны да тойган кебек буласың. Иң мөһиме: салкын кышны да җылы итеп, назга төреп бирә белә.

Яңа техника, бөтенләй үзгә материалны ача ул бу эшләрдә үзе өчен. Сүз дә юк, сарык йоныннан эшләнүләре аларга үзенә бер җылылык өсти. Киез дә, табигый тукымасы да тәнгә генә түгел, җанга ук якын. Бу җылылык остаҗың тылсымлы куллары аша үтеп, тулысы белән курчакларга күчә.

Расиха ФАИЗОВА









ТАТЬЯНА ВОЛКОВА

PRESSA.RU



2017 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр
(мөселман ай календаре буенча 1438—1439 һиҗри еллар)

29 март – мөселман календарендa изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хажы кылына.

30 март – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең əти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

23 апрель – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына могҗизалы сәяхәт кылган көне. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

10 май – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәлләре һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

21 май – Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

27 май – изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн.

21 июнь – Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе.

25 июль – Гайдел-фитыр көннәре. Ураза гаете.

31 август – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

1 сентябрь – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә.

2, 3, 4 сентябрь – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус догалар укый.

21 сентябрь – 1439 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына. Бу көнне Аллаһы Тәгалә игелек кылган кешеләрнең гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

30 сентябрь – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626–680) җәзалап үтерелгән көнне изге вә хөрмәтле санап, ураза тоткан.

21 октябрь – Сәфәр ае башланган көн.

29 ноябрь – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Ул көнне мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, сәдака (зәкят) өләшенә.

Төзүче – хаҗи Абдулла ДУБИН.

Фото: Ксения Богданова.